BELEM.RU

*Альманах*

# БЕЛЕМ

*Альманахы*

№ 2

УДК 001.89
ББК 94.3
Г 24

Материалларның эчтәлеге һәм дөреслеге өчен
аларның авторлары җавап бирә

За содержание и достоверность материалов
отвечают их авторы

**Төзүчеләр:**
Гатауллин Р.М., «Белем.ру» ҖЧҖ директоры, КФУ Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының мәгълүмати системалар кафедрасы өлкән укытучысы;
Хисматова Л.К., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының фәнни-педагогик кадрлар әзерләү бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты.

**Составители:**
Гатауллин Р.М., директор ООО «Белем.ру», старший преподаватель кафедры информационных систем Института вычислительной математики и информационных технологий КФУ;
Хисматова Л.К., начальник отдела подготовки научно-педагогических кадров ГАОУ ДПО ИРО РТ, кандидат филологических наук.

**«Белем альманахы – Альманах Белем», № 2**, сборник авторских научно-методических материалов образовательного портала «Белем.ру». – Казань, 2023. – 144 с.

Җыентыкта татар һәм рус телләрендә педагогларның төрле предмет өлкәләрендә үз педагогик тәҗрибәләрен, идарә итү мәсьәләләрен, педагогик проблемаларны, белем бирү һәм тәрбия методикаларын үз эченә алган авторлык фәнни-методик хезмәтләре тәкъдим ителгән.

В сборнике представлены авторские научно-методические материалы педагогов на татарском и русском языках, содержащие описание педагогического опыта, вопросов управления, педагогических проблем, методики обучения и воспитания в различных предметных областях.

УДК 001.89
ББК 94.3

© ООО «Белем.ру», 2023
© НКО «Фонд развития Татнета», 2023

# ХӨРМӘТЛЕ БЕЛЕМ АЛЬМАНАХЫН УКУЧЫ!

Синең кулларыңда Белем альманахы – мәгариф, мәдәният, заманча методикалар һәм IT-технологияләр, белем һәм тәрбия бирү өлкәләрендә күп санлы хезмәтләрне үз эченә алган файдалы иркле җыентык.

Белем альманахы җыентык кына да түгел, ул – Белем.ру порталы һәм башка күп кенә файдалы проектларыбыз тирәсендә тупланган, проектларыбызда актив катнашкан һәм аларны ихтирам иткән белемле, ныклы рухлы, көчле, киләчәккә позитив карашлы һәм тырыш кулланучыларыбызның, укучыларыбызның, педагогларыбызның, шәхесләребезнең тәҗрибәләре белән уртаклашу мәйданчыгы да.

Әлеге альманах – инде 15 елдан артык эш алып барган «Белем.ру» компаниясенең (ooo.belem.ru) фәнни хезмәтләренең берсе.

«Белем.ру» компаниясенең төп юнәлешләренең берсе – мәгариф өлкәсендә, белем бирү өлкәсендә эшчәнлек. Компания укытучыларны, мәгариф хезмәткәрләрен үзенең эшчәнлеге белән һәрдаим онлайн һәм офлайн форматларда таныштырып тора, еш кына конференцияләрдә чыгышлар ясый, анда күргәзмәләр белән катнаша, татар мәгарифе өлкәсендә үзе дә конференцияләр оештыра. Шундый конференцияләрнең берсе – «Тел, җәмгыять һәм мәгълүмати технологияләр» – «Язык, общество и информационные технологии» II Россиякүләм фәнни-гамәли конференциясе – быел гыйнвар-февраль айларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасы, Татнетны үстерү фонды, Казан шәһәре Идел буе районының 16 нчы татар-инглиз гимназиясе белән берлектә икенче тапкыр үткәрелде, конференция материаллары быел да шактый калын һәм эчтәлекле җыентык булып дөнья күрде.

Белем альманахы исә 2022 елда нәшер ителә башлады. Альманахның беренче санында ук шактый файдалы, сыйфатлы, зур әһәмияткә ия булган материаллар урын алган иде.

Кулларыгыздагы альманахның әлеге икенче саны тагын да сыйфатлырак, эчтәлеклерәк материалларга бай булуы белән куандыра. Бу материаллар мәгариф хезмәткәрләре, педагоглар өчен генә түгел, ә белем һәм тәрбия бирү, заманча технологияләрне көндәлек тормышта куллану өчен киң катлам укучылар – ата-аналар һәм җәмәгать эшлеклеләре, студентлар һәм аспирантлар өчен дә шактый файдалы.

Белем альманахының нинди булуы һәм аның республикабыз мәгарифе үсешендә нинди роль уйнаячагы – сездән тора, хөрмәтле укучылар, әлеге җыентыкны үз кулларына алучылар! Альманахта киләчәктә дә бары тик иң файдалы, иң кирәкле, иң яхшы эшләр генә урын алсын иде, дигән теләктә калам.

**Раил Гатауллин**

# КОЯШ ҺӘМ АЙ, АГАЙ-ЭНЕ!..

*(Методик эшкәртмә)*

*Абдрахманова Гөлназ Мияссәр кызы,*
*югары категорияле тәрбияче,*
*Казан шәһәре Совет районының «3 нче катнаш төрдәге татар телендә тәрбия һәм белем бирү балалар бакчасы» МБМБУ*

Заманча педагогик тикшеренүләр күрсәткәнчә, мәктәпкәчә укытуның төп проблемасы булып – тереклекнең югалуы, танып белү процессына тартылмау тора. Бүгенгесе көндә мәктәпкә барырга теләмәгән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның саны арта, дәресләргә уңай караш кимеде, балаларның өлгерүчәнлеге төште. Әлеге хәлне ничек төзәтергә соң? Мәктәпкәчә яшьтәгеләр белән эшләүче хезмәткәрләр һәрбер баланы үзкыйммәтле шәхес буларак үстерүнең кирәклеген аңлыйлар.

Актуальлелекне ассызыклап, тәрбиячenең дә замана арбасыннан төшеп каласы килми. Мәшһүр Татарстаныбыз һәрвакыт бөек сынау алдында тора. Республикабыз башкаласында бар җиһанга бәян итеп бәйрәмнәр гөрли. Исемдә калганнарының берсе – Универсиада. Балаларыбыз Лондон каласында үткән Олимпиада уеннарында Россия вәкилләренең зур уңышка ирешүләреннән хәбәрдар. Шул елларда нәниләр зур кызыксыну белән, туган илебездән тыш, чит илләрнең дә булуын белеп, әлеге уенның символларын өйрәнә: эмблеманың зәңгәр түгәрәге Европаны, карасы – Африканы, сарысы – Азияне, кызылы – Американы һәм яшеле Океания белән Австралияне символлаштыруы белән танышлар. Шушы биш материк өстеннән бер булып кояш балкый – дуслык һәм тынычлык кояшы. Кабаттан, Борынгы Грециядәге сыман, Олимпия уеннары дәвамында сүнми янган утны кояш нуры балкыта. Тикмәдән генә эшемне кояшны сурәтләүдә башламадым мин, чөнки проект эшемнең нигезен, табигать күренешләре, йолдызлар тәшкил итәчәк.

Бала шәхес буларак үзенең йөзен проектлар эшчәнлегендә күрсәтә ала. Минем эш тәҗрибәмдә әлеге алым еш кулланыла. Мин үземнең дәресләремдә һәрдаим информацион технологиялардән актив файдаланам. Шушы проект эшчәнлегем презентация белән бергә үрелеп бара.

Чираттагы эшемнең темасын ачыклау өчен мин түбәндәге **бурычларны** куйдым:

– Укыту: әйләнә-тирә мохитне өйрәнү, танып белү күнекмәләрен, сөйләм телен үстерү, күзаллау тудыру;

– Үстерелешле: активлыкка өндәү, яңа технологияләр кулланып рәсем ясау осталыгына ирешү;

– Тәрбияви: дустанә мөнәсәбәтләр тудыру, уен кагыйдәләренә буйсыну, милли гореф-гадәтләрне яңарту, табигатьне саклау.

**Максат:** Балаларны майлы карандаш ярдәмендә буялган альбом битен акварель краска белән буяганнан соң килеп чыккан эффект белән таныштыру; балаларның пөхтә итеп, биткә тулысынча төс, тон бирергә өйрәнүне ныгыту; кешенең көндәлек тормышында кояш һәм айның даими янәшәдә булуына балаларның игътибарын җәлеп итү.

**Проектлаштыру технологиясен мин ике өлешкә бүлеп карыйм:**

1) һәрбер баланың иҗади сәләтен үстерү алымы;

2) социальләшү – бала эшчәнлегенең барлык төренең интеграциясе (берләшү).

Проект эшчәнлегем, түбәндәге белем бирү өлкәләренең интеграциясеннән гыйбарәт:

- дөньякүләм күзаллауның бербөтенлеге,
- танып белү – тикшеренү эшчәнлеге,
- хезмәт,
- коммуникацияләү,
- сәламәтлек,
- физик үсеш.

**Проект эшчәнлегем өч юнәлештә гамәлгә ашырыла**:

1. Балалар белән эш;
2. Балалар бакчасындагы педагоглар белән эш;
3. Әти-әниләр белән эш.

Проект эшчәнлеге – әлеге очракта рәсем ясау серләренә генә төшенү түгел, ә бик зур ихтыяр көче һәм сабырлык сорый торган хезмәт.

Беренче эш итеп, проектның практик өлешен өлешчә ничек тормышка ашырылуын күрсәтергә телим. Әлеге проект озак вакытлы.

Проектның исемен: «Кояш һәм ай, агай-эне!..» – дип алдым. Күңелемдә ай, кояш турында күп төрле ассоциацияләр (кичерешләр) туды. Шул ук вакытта балаларның фикерләре

дә исәпкә алынды. Кояш ул дөньяны яктырта, җылыта, назлый, тереклекне яшәтә. Нәкъ шул сәбәпләр аркасында, бүгенге тәҗрибә уртаклашуымны әлеге табигать күренешләре белән бәйлисем килде. Игътибар итсәк, балалар рәсем ясарга өйрәнгәндә һәрчак кояшны сурәтләргә тырышалар. Алар аны күкнең үзәгенә дә, читенә дә нурларын җибәреп, кызгылт сары төсләрне кулланып ясыйлар. Төрле ел фасылларында аның торышын күзәтәләр. Кыш көнне кояш түбән, без аның җылысын тоймыйбыз. Аннан соң яз килә, ул югарырак күтәрелә. Кояш карларны эретә, гөрләвекләр барлыкка килә. Җәй көнне кояш тагы да югарырак күтәрелә. Көннәр җылына. Көз тагын түбәнәя, җылылык кими, көннәр салкыная. Әмма елның теләсә кайсы чорында булса да кояш һәммәбезне активлыкка өнди, хәрәкәткә китерә. Ә ай, киресенчә, безне моңсуланырга, уйланырга мәҗбүр итә. Дөрес ул караңгы төнне яктырта, шулай да төнлә тынычлык хөкем сөрә. Кояшны ай алмаштыра. Көн төнне, төн көнне алыштыра. Бу хакта, балаларның да күңеленә хуш килгән, Габдулла Тукайның бик матур «Көн һәм төн» исемле шигъри юллары искә төшә (*мультфильмын карап үтәбез).*

Әйдәгез әле, төп эшебезгә керешкәнче, җәйне, балачакны искә төшерик, көннәр җылы, кәефләр күтәренке.

Кояш, чык, чык,
Майлы ботка бирермен,
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык сабы алтын,
Кирәкми безгә салкын.

**Ә хәзер проектның гамәли өлешенә рәхим итик.** Биредә без рәсем технологиясенең үзенчәлекле алымын кулланачакбыз. Кояш һәм айның асыл сыйфатларын билгеләүдә безгә акварель краскалар һәм карандашлар ярдәмгә киләчәк.

Кояш үзе дә рәссам – ни өчен агачлар яшел, ни өчен көзен яфраклар алтынсу, кызыл, сары төскә керә?

1. Майлы карандашлар алабыз һәм кояш рәсемен ясарбыз.
2. Иң элек, битне урталайга бөклибез һәм кире ачабыз.
3. Битнең яртысына кояш рәсемен ясыйбыз.

Менә һәрберебезнең йөзенә нурлар йөгерде, кояш кәефләребезне күтәреп җибәрде.

Ай булганда тынычлык хөкем сөрә. Ул караңгыда юлчыларны юллап җибәрә. Ай безнең татлы йокыбызны саклый.

4. Иҗат итүебезне дәвам итәбез: бөкләгән битнең икенче ягына ай һәм йолдызлар сурәтен төшерәбез.

5. Афәрин, булдырдыгыз, рәхмәт!

Ял иткән арада әңгәмә корыла:

– Әйдәгез, тагын бер кат искә төшерик әле, кояш чыкканда безнең күк йөзе нинди? Зәңгәр.
– Ай хөкем сөргәндә, безнең төн була, караңгы. Хәзер инде кирәкле төсне алабыз һәм рәсемнең ике ягын да өстеннән буйыйбыз.
– Ни гаҗәп, карагыз әле, без нинди осталыкка ирештек. Ясалган кояш һәм ай акварель эчендә калмады. Табигать күренешләре ай һәм кояш, нур сибеп,караңгылыкны җиңеп өскә калкып чыктылар.

Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә,
Торып чыга, көлеп җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне –
Менә шулай дустлык берлән нәүбәтләшә – диеп тәмамлый үзенең «Кояш һәм ай» әсәрен мәшһүр шагыйребез Г.Тукай.

Димәк, безнең киләчәгебез дә якты, бәхетле булырга ошаган.

Эштән соң, уйнарга ярый, дигән иде әдибебез, әйдәгез, хәзер ял итеп, уен уйнап алабыз.

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Санамыш (*эшемне санамышлардан башлыйм. Чөнки һәрбер баланың уенны алып барасы килә, каршылык килеп тумасын өчен, мин санамышлар кулланам. Алар сөйләм телен үстерүдә дә мөһим роль уйныйлар. Санамышлар бит бик күп. Мәсәлән иң гадие: «Әке-бәке, сынык сәке, син кал, син чык», «Бер тай, ике тай, өч тай, дүрт тай, монда торма, чыгып тай!»).* ярдәмендә уртага берәү чыга. Ул – «ябалак», түгәрәктәгеләр кошлар булалар. Ябалак «төн» дип кычкырса, кошлар куллар белән кош очкандагы хәрәкәтләр ясыйлар, ә «көн» дисә, барсы да катып калалар. Әгәр шулвакыт берәрсе селкенсә, ул уеннан чыгарыла. Уен шул рәвешчә, түгәрәктә бер генә кош калганчы уйнала. Ул җиңүче була.

Нәтиҗә ясар алдыннан, әлеге сорауларга җавап табасы килә – проект эшчәнлегендә без нинди сыйфатлар булдырдык соң, нәрсәләргә ирештек?

***Проект эшчәнлегендә катнашучы балалар турында сөйләгәндә, алар:***

- әйләнә-тирә мохитне танып белүдә һәм нәтиҗәле эшчәнлектә иҗади активлык күрсәтәләр;
- карарлар кабул иткәндә мөстәкыйль һәм сыгылмалылык күренә (гибкость);
- практик мәсьәләләр чишкәндә аңлы рәвештә тоемлыйлар;
- үзләрен аңлаучы субьект буларак тоялар (нәрсә билгеле, нәрсә юк, ни рәвешле белергә була);
- бердәмләшеп хәрәкәт итү планы хакында сөйләшкәндә балалар коллективында аралаша алу осталыгы үсә;
- табигать дөньясын утилитар күзлектән чыгып кабул итеп кенә калмыйлар, шулай ук аның матурлыгын, уникальлеген дә тоялар.

Автор буларак, мин иҗади эзләнүчән эшчәнлегемдә проект методын кулланганда, түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:

- бөтен тәрбияви белем бирү процессын мөстәкыйль иҗади планлаштыру;
- балаларның теләкләрен һәм кызыксынучанлыкларын исәпкә алып башкарырга сәләтлелек;
- педагогик эшчәнлектә эзләнүчәнлекне, үземнең иҗади мөмкинлекләремне тормышка ашырам (рәсем сәнгате, әдәбият, музыка эшчәнлегендә).

Ата-аналар белән берлектә, бер ук баланың тәрбиячеләре буларак, сабыйларның нәфис ак күңелендә якты матур эзләр калдырырлык итеп, бердәм эшлибез.

***Проект эшчәнлегендә катнашучы ата-аналар:***

1. Үзләренең балалары белән генә түгел, ә ата-аналар коллективы һәм төркемдәге балалар белән дә тыгыз элемтә булдырдылар;
2. Балалар бакчасында балаларының ни белән шөгыльләнүен белеп кенә калмыйча, төркем тормышында актив катнашучылар булдылар;
3. Үзләренең иҗади сәләтләрен тормышка ашыра алдылар.

Минем төп принцибым – төркемдәге балалар, аларның әти-әниләре арасында уңай мөнәсәбәт, җылы атмосфера урнаштыру. Кояш һавада, ат-тауларда, егет яуда сынала, диләр. Ә без бүген балалар белән үз чиратыбызда танып белү эшчәнлегендә сынатмадык.

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Әхмәтҗанова Р.К. «Матурлык иленә юл» Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2001.

2. Габдулла Тукай. – Академик басма. 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913).

3. Нигматуллина Э.Т. «Рәсем ясарга өйрәнәбез», Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2010.

4. Нищева Н.В. Четыре времени года. Развитие эмоционального мира и речи старших дошкольников при рассмотрении пейзажной живописи. – СПб.: ДЕТСТВО-ПРЕСС, 2007.

5. Интернет чыганаклар.

## ЗАКРЕПЛЕНИЕ ЗНАНИЙ О ЦИФРЕ 5 И ГЕОМЕТРИЧЕСКИХ ФИГУР

*(Конспект ООД по теме)*

*Ахметова Алина Ильдаровна,*
*Шувалиева Эльвира Равильевна,*
*Мухтарова Резеда Амирзяновна,*
*воспитатели,*
*МБДОУ «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития воспитанников № 131 «Лучики» г.Набережные Челны*

**Цель:** Развивать математические способности детей в счете до 5, закреплять знания геометрических фигур

**Задачи:** Образовательные: закреплять умение считать в пределах 5; учить соотносить цифру с количеством предметов; видеть геометрические фигуры в контурах окружающих предметов; ориентироваться на листе бумаге (верхний правый угол, верхний левый угол, нижний правый угол, нижний левый угол, середина. Развивающие: развивать внимание, логику, память. Воспитательные: воспитывать доброжелательность, вызвать желание заниматься математикой

**Материалы и оборудование:** игрушка (картинка) Чебурашки, на каждого ребенка бумажные цифры, на каждого ребенка

цифры (счетный материал), карточки с разным количеством предметов (1-5), счетные палочки на каждого ребенка, картинки с геометрическими фигурами для физкультминутки, геометрические фигуры на А4, цифры на А4, половина альбомного листа для каждого ребенка, геометрические фигуры для каждого ребенка (счетный материал).

**Ход занятия:**

– Ребята, сегодня к нам пришли гости, давайте с ними поздороваемся: «Здравствуйте!» и подарим им свою улыбку!

– Я хочу, чтобы у вас сегодня весь день было хорошее настроение.

В круг широкий вижу я,
Встали все мои друзья.
Мы сейчас пойдём направо,
А теперь пойдём налево,
В центре круга соберёмся,
И на место все вернёмся.
Улыбнёмся, подмигнём,
И занятие начнём.

– Ребята, посмотрите, кто же это к нам пришел сегодня в гости. Это же Чебурашка. Но почему же он грустный? Он мне тихонько сказал, что хочет научиться считать, узнавать и называть геометрические фигуры так же, как и вы. Поможем ему в этом?

– Чебурашка принес вам мешочек. Что же в нем лежит? Это цифры. Сейчас каждый из вас берет 1 бумажку. За стол садятся те ребята у кого цифра 3, 1, 4, 2, 5. Положите свои листочки на край стола.

– Сейчас нам понадобятся цифры (счетный материал), которые лежат на столе. Я буду показывать картинки с разным количеством предметов, а вы – поднимать нужные цифры.

– Ребята, листочки вы взяли из мешочка не просто так, они нам сейчас пригодятся. Послушайте задание внимательно: положите на стол столько счетных палочек, сколько обозначает цифра на ваших листочках.

– Молодцы справились с заданием. Встаем со стульчиков, идем на палас, выполним с вами математическую физкультминутку.

– Все готовы?

– Внимательно повторяйте за мной. И отвечайте на мои вопросы.

«Один, два, три, четыре, пять» упражнение будем выполнять.

– Сколько точек будет в круге (три), столько раз поднимем руки (три).

– Сколько раз ударю в бубен (пять), столько раз дрова разрубим (пять).

– Сколько треугольников зеленых (три), столько выполним наклонов (три).

– Приседаем столько раз, сколько квадратов у нас (четыре).

– А сейчас давайте поиграем с вами в игру, я буду показывать геометрическую фигуру, а вы найдете в группе предмет, который похож нам эту геометрическую фигуру.

(Круг, квадрат, прямоугольник, треугольник, овал).

– Ребята, Чебурашка приготовил нам сюрприз, но, чтобы его получить, нам нужно выполнить одно тяжелое задание. Давайте попробуем. Садимся на свои места.

– Перед вами на столе лежит листок, на нем мы будем выполнять задание с помощью геометрических фигур. Слушайте внимательно:

В правый верхний угол положите круг.

В левый нижний угол положите квадрат.

Посередине положите овал.

В правый нижний угол положите прямоугольник.

В левый верхний угол положите треугольник.

– Молодцы, ребята вы справились со всеми заданиями. Посмотрите ребята, а наш Чебурашка улыбается, потому что Чебурашка вместе с нами научился считать, узнавать и называть геометрические фигуры так же, как и вы.

– Давайте, посмотрим какой подарок, принес нам чебурашка. Конечно, это наклейки.

– Ребята, давайте вспомним, что мы сегодня делали на занятии? О чем говорили? Что вам больше всего понравилось?

**Список источников:**

1. Колесникова Е.В. Математика для детей 4-5 лет: Учеб. – метод. пособие «Я считаю до пяти». – 4-е изд., перераб. и доп. – М., 2017. (Математические ступеньки).

# АЕРГЫЧ

*(Дәрес конспекты)*

*Әхмәтова Зөлфия Назыйф кызы,*
*югары квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Актаныш муниципаль районы*
*«Аккүз төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ*

**Дәрес тибы:** яңа материалны өйрәнү.

**Максатлар: Фәнни максат:** аергычка билгеләмә бирә белү; аны аңлау өчен шартлар тудыру.

**Фикерләрне, күнекмәләрне үстерү максаты:** «Табигать» темасына нигезләнеп, укучыларның бәйләнешле сөйләм һәм иҗади эшчәнлекләрен арттыру, ныклы күнекмәләр формалаштыру;

**Тәрбияви максат:** Табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре:**

Рухи-әхлакый үсешне күрсәтә торган: укучыларда дуслык, бердәмлек, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.

**Регулятив:** үз алдыңа максат куя белү, максатка ирешү, күзаллау, фаразлау, чишү юлларын табу.

**Танып белү:** дөрес җавапны таба белү, проблеманы чишү.

**Коммуникатив:** фикерне аңлата, биремне укый һәм кабул итә, иптәшләреңне тыңлап үзара килешеп эшли һәм сөйләүченең ялгышын табып төзәтә белү.

**Бурычлар:** аергычларны аера һәм кирәкле урында куллана белү, сәнгатьле уку, укыган текстка үз мөнәсәбәтен белдерү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

**Метапредмет:** укыган текст эчтәлегенә үз мөнәсәбәтеңне белдерә белүе, үз-үзенә билге куярга өйрәнү.

**Предмет:** татар теленең «аергыч» җөмлә кисәген аера белү.

Рухи-әхлакый үсешне күрсәтә торган: табигатькә карата сакчыллык, соклану хисләренең үсүе.

**Укыту-методик комплект, җиһазлау:**

1. Хасаншина Р.Г. Татар теле 5 сыйныф: татартелендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. – К: Татарстан китап нәшрияты, 2015.

2. Ноутбук, проектор, презентация: «Аергыч», карточкалар, музыка.

**Дәреснең этаплары:**

– Укытучы эшчәнлеге.

– Укучыларның эшчәнлеге.

– Универсаль уку гамәлләре.

**I. Оештыру моменты.**

Исәнләшү, танышу, уңай психологик халәт тудыру.

– Исәнмесез, укучылар, хәерле иртә! Хәерле иртә, балалар!

– Кәефләрегез әйбәтме? Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр, – диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк.

Укучылар теләкләр тели:

– Яңа көн тынычлык алып килсен!

– Яңа көндә яңа «5» леләр алыйк!

– Әти-әниебезгә, дусларга ягымлы булыйк!

– Яңа көндә барыбыз да яхшы эшләр генә кылыйк!

Без бүген төркемнәрдә эшләрбез. Алларыбызда кейслар ята. Биремнәр шунда. Төркемегез өчен һәрберегез үз өлешегезне кертерсез. Алдыгыздагы үзбәя кәгазьләренә һәр эшне башкарганнан соң билге куеп барырсыз. Дәрес азагында гомуми билге чыгарып, көндәлекләргә куярбыз. Һәр төркем үзенең модераторын билгеләп куя.

Дәрескә әзерләнүне тәмамлыйлар.

Дәресебезнең эпиграфы итеп, Фәнис Яруллинның шигырь юлларын алыйк әле.

Табигать ул – тиңсез хәзинә,
Шаулы урман, челтер чишмә дә.
Яшел болын да ул, зәңгәр күк тә,
Сакла аны, аңа син тимә!

*Фәнис Яруллин.*

**II. Белемне актуальләштерү.**

1. Өй эшләрен тикшерү.

Үткән дәрестә өйрәнелгән теоретик материал «әйе» һәм «юк» моделе буенча тикшерелә. Бирелгән гыйбарәне я раслыйбыз, я кире кагабыз.

*Үзбәя.* а) дәреслектән файдаланып, җавап бирә алса - «3»;

б) өч сорауга җавап бирә алса – «4»;

в) әлеге сорауларга төгәл җавап бирә алса – «5».

**III. Уңыш ситуациясен тудыру.**

**Уку мәсьәләсен кую.**

Ап-ак карлар ява. Җөмләне укыгыз һәм җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерегез. Калын хәрефләр белән бирелгән сүз җөмләдә нинди кисәк була? Без бүген нәрсә турында сөйләшербез?

*К.җ.:* Калын хәрефләр белән бирелгән сүз җөмләдә аергыч була. Димәк, без бүген аергыч турында сөйләшербез.

*Үзбәя.*

Бүген без сезнең белән «Аергыч»ны өйрәнербез.

– Нәрсә ул аергыч? Аңа нинди билгеләр хас?

– Бу мәсьәләне ничек чишә аласыз? Уйлагыз, фикер алышыгыз.

– *К.җ.:*

– Искә төшерә алабыз.

– Күнегүдән карый алабыз.

– Дәреслектән өйрәнә алабыз.

Дәрескә без нинди максатлар куябыз, нинди бурычлар?

*(Аергычларны өйрәнербез, күнегүләр эшләрбез, яхшы белгеләр алырбыз).*

Дәфтәрләрне ачып, бугенге числоны һәм теманы язып куйыйк.

**IV. Укучылар эшчәнлеген мотивлаштыру.**

1. **Кейсның 1 нче кисәсендә.**

Теманы аңлату өчен күнегү эшләнелә.

**Җөмләләрне күчереп языгыз. Аергычларның астына сызыгыз.**

Өебез урман янында. Төз наратлар, баһадир имәннәр, бал исле юкәләр, шаулашып, урман әкияте сөйләп алгалый. Зифа каеннар йөгереп чыкканнар, яшел шәлләрен ян тәрәзәгә җилфердәтәләр.

Агачларда чык балы күренде. Җәй ахырында гына булганча, яфракларын ябышкак сулар каплады. Димәк, күңелле җәй инде үтә дә башлады. Бу уйны дөресләп, юкәләрдә беренче сары яфраклар күзгә чалынды. Урманның матурлыгы авылдагы халыкны таң калдырды.

*Көтелгән җавап:*

Төз наратлар, баһадир имәннәр, бал исле юкәләр, зифа каеннар, яшел шәлләрен, ян тәрәзәгә, ябышкак сулар, күңелле җәй, бу уйны, беренче сары яфраклар, урманның матурлыгы, авылдагы халыкны.

*Үзбәя.*

Укучылар, аергыч нинди сүз төркеменә ияреп килә? (исем)

– Әлеге сүзтезмәләрдә аергыч нинди сорауларга җавап булып килде? (нинди? кайсы? ничәнче? нәрсәнең? кайдагы?)

***(<u>Нәтиҗә ясала</u>)*** **Димәк, аергычлар исемне ачыклап киләләр һәм Нинди? Кайсы? Ничәнче? Кайдагы? Ничә? Кемнең? Нәрсәнең? дигән сорауларга җавап бирәләр.**

*Үзбәя.*

2. **Кейсның 2 нче кесәсендә.**

Дәреслек белән эш.

259 нчы күнегү. Модель төзиләр.

*К.җ.:*

***Аергыч.***

– җөмләнең иярчен кисәге,

– исем сүз төркемен ачыклап килә,

– сораулары: Нинди? Кайсы? Кайдагы?

Кайчангы? Ничәнче? Кемнең?

*Үзбәя.*

Аны яклыйлар.

*Үзбәя.*

3. **Кейсның 3 нче кесәсендә.**

Ял моменты.

4. **Кейсның 4 нче кесәсендә.**

**Карточка белән эш.**

Табигать темасына, терәк сүзләрне кулланып, җөмләләр төзергә.

**1 нче төркем.**

**2 нче төркем.**

1. Ямь-яшел. 1. Икенче

2. Җәйнең. 2. Көзгедәй

Көтелгән җавап:

1. Алмагачлар ямь-яшел яфрак ярды, чәчәк атты.
2. Җәйнең күңелле, матур вакыты җитте.
3. Икенче август та җиткән.
4. Көзгедәй су өстенә өянкеләр тезелгән.

*Үзбәя.*

а) 1 җөмләне дөрес язса – «4»;

б) барлык бирем төгәл үтәлсә – «5».

5. **Кейсның 5 нче кесәсендә.**

**Тест биреме.**

**Укучылар бер-берсенә билге куялар.**

**8 нче кесә – Өй эше.**

*Гомуми билгеләр чыгарыла.*

– Укучылар, дәрестә нинди уку материалы тикшердек? Димәк, без дәрес башында куйган максатыбызга ирештекме?

Куелган бурычларны үтәдекме?

Табигать ул – тиңсез хәзинә,
Шаулы урман, челтер чишмә дә.
Яшел болын да ул, зәңгәр күк тә,
Сакла аны, аңа син тимә! (*Фәнис Яруллин).*

## ШӘВӘЛИ БЕЗДӘ КУНАКТА

*(Мәктәпкәчә кече яшьтәге балаларга татар халык уены өйрәтү буенча эшчәнлек конспекты)*

*Вәлиева Гөлшат Шәһит кызы, тәрбияче,*
*Әлмәт шәһәре «53-нче катнаш балалар бакчасы «Светофорик» МББМБУ*

**Максат.** Халык авыз иҗаты – уеннар аша кече яшьтәге балаларга милли тәрбия бирү.

**Бурычлар**:

Тәрбия бурычы: халык авыз иҗатына кызыксыну уяту, дуслык хисе тәрбияләү, бергәләшеп уйнау теләге тудыру.

Үстерү бурычы: балаларның игътибарын, хәтерен, төрле юнәлештә йөгерү активлыгын үстерү;

Белем бирү бурычы: «Җиләк җыям, как коям» татар халык уены аша балаларның актив сүзлеген арттыру, җыр сүзләренә тәңгәл рәвештә хәрәкәт итәргә өйрәтү.

**Төп белем бирү өлкәсе**: физик үсеш.

**Интеграль белем бирү өлкәләре**: танып белү үсеше, сөйләм үсеше, социаль аралашу үсеше.

**Методик алымнар һәм чаралар**: әңгәмә, кабатлау, уен.

**Җиһазлар**: аю, бүре ярымбитлекләре.

**Сүзлек эше**: җиләк җыям, как коям.

**Алдан үткәрелгән эш**: санамышлар өйрәнү, ел фасыллары, урман җәнлекләре турында кабатлау, татар халык киемнәрен өйрәнү.

**Структура.**

I. Кереш өлеш: балаларның игътибарын җәлеп итү – кунакка Шәвәли килә.

II. Төп өлеш. 1) Шәвәли белән әңгәмә.

2) Яңа уенның кагыйдәләрен аңлату.

3) Бергәләшеп « Җиләк җыям, как коям» уенын уйнау, берике тапкыр кабатлау.

III. Йомгаклау.

**Эшчәнлек барышы**.

**Тәрбияче.** Балалар, минем яныма килегез әле! Әйтегез әле, сез уйнарга яратасызмы?

**Балалар.** Әйе.

**Тәрбияче.** Ә ничек уйнарга яратасыз?

**Балалар.** Курчак белән, машина, туп, кубиклар белән...

**Тәрбияче.** Әйе, без сезнең белән бик күп уеннар беләбез. Ә бүген минем сезгә яңа уен өйрәтәсем килә.

*(Шулвакыт ишектән, шакымыйча, Шәвәли атлы малай килеп керә, кулында аю һәм бүре ярыммаскалары).*

**Шәвәли.** Исәннәрмесез! Мин – Шәвәли, шук малай, уйнарга бик яратам! Сезнең белән дуслашырга һәм бергәләп уйнарга телим! Син кем? *(Берничә баладан исемен сорый)* Менә дуслаштык та!

**Тәрбияче.** Карагыз әле балалар, Шәвәлинен киеме нинди матур! Ул Сары кулмәк, яшел жилет кигән, ә башында нәрсә, кем белә?

**Балалар.** Түбәтәй кигән.

**Тәрбияче.** Ә син, Шәвәли, нинди уен уйнарга телисең соң?

**Шәвәли.** Мин йөгереп уйнарга яратам. Сезгә дә бер шундый уен өйрәтәсем килә. «Җиләк җыям, как коям» дип атала ул.

**Тәрбияче.** Җиләкне хәзер җыймыйлар бит?! Арслан, җиләкне кайчан җыялар?

**Бала.** Җәй көне җыялар.

**Тәрбияче.** Эмилия, җиләк кайда үсә?

**Бала.** Урманда үсә

**Тәрбияче.** Әйе, җиләк урманда үсә. Ә урманда нәрсәләр яши?

**Балалар.** Куян, аю, бүре...

**Шәвәли.** Бу бит уен гына. Менә безнең әби-бабаларыбыз да кайчандыр сезнең сыман кечкенә булганнар, алар, җәен әниләренә

ияреп, урманга җиләккә, гөмбәгә йөргәннәр, ә ял вакытларында шул кечерешләрне уенга салганнар. Өйрәнәбезме?

**Балалар.** Әйе.

**Шәвәли.** Бу уенда санамыш белән аю, бүре сайларга кирәк. Сез санамышлар беләсезме?

**Тәрбияче.** Балалар, без нинди санамыш беләбез әле?

**Балалар.** Әлеш-мәлеш,

Мичтә бәлеш.

Казанда ит,

Аша да кит.

**Шәвәли.** Менә бит нинди матур санамыш!

Әйдәгез, саныйк әле. *(Беренче кат санаганда аю тәрбияче булырлык итеп саныйлар).*

**Шәвәли.** Менә, тәрбияче апабыз аю була, ул урманда яши *(Битлек киеп, бүлмәнең икенче башына китеп баса).* Ә без сезнең белән җырлап җиләк җыя-җыя урманга барабыз. Әлегә сүзләрен өйрәник.

Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә,
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән!

Әйдәгез, кабатлап карыйк әле!

Уенны өйрәнгәнче, миңа ияреп җырларбыз, ә аннары тәрбияче апагыз белән сүзләрен яхшылап өйрәнерсез, ярыймы? Урманга барып җиткәч, безне аю куа башлый, ә без тоттырмаска тырышып, өебезгә – урындыкларга таба чабабыз, аңлашылдымы? *(Уен).*

**Тәрбияче.** Балалар, сезнең дә аю-бүре буласыгыз киләме? Әйдәгез, тагын бер кат санап аюны да, бүрене дә сайлыйбыз.

*(Уен бер-ике тапкыр кабатлана).*

**Тәрбияче.** Балалар, сезгә бу уен ошадымы?

**Шәвәли.** Безне урманда кем куды?

**Тәрбияче.** Балалар, Шәвәлинең кулмәге нинди төстә?

**Шәвәли.** Сезнең белән дуслашуыма мин бик шат! Менә бу битлекләрне мин сезгә бүләк итеп калдырам, тагын уйнарсыз! Ә мин яңа дуслар эзләп китим әле, сау булыгыз!

**Балалар.** Сау бул, Шәвәли!

**Тәрбияче.** Без бу уенны әле тагын физкультура шөгылендә дә, саф һавада да уйнарбыз, шулай бит балалар?!

# УКУ-УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ МӘГЪЛҮМАТИ-КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

*Галәвиева Фәридә Ринад кызы,*
*югары квалификацион категорияле биология укытучысы,*
*Гомәрова Галина Александр кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Казан шәһәре Совет районының*
*«171 нче гомуми урта белем бирү һәм*
*аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе» ГББМБУ*

Гасырлар алышынганда кешелек узганга нәтиҗә ясый, киләчәккә планнар кора. Бу традиция белем бирү сферасын да читләтеп узмый. Бүген үк инде белем бирү системасын камилләштерү, белем сыйфатын үстерүнең төрле юллары эзләнелә.

Җәмгыятькә талантлы, иҗади фикерли, аралаша белүче, инициативалы гражданнар сорала. Укып алган диплом гына тормышта үз урыныңны табуга гарантия була алмый. Мәктәп бусагасын атлап чыгучы кешенең җаваплылык хисе, дисциплина, белем күтәрүгә омтылыш, эзләнүчәнлек кебек сыйфатларга ия булырга тиешлеген бөтенебез беләбез. Мәктәпләрдә шундый шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәм итә.

Бүгенге көндә илебездә дөнья мәгариф тирәлегенә керүгә юнәлтелгән мәгариф системасы урнаша бара. Бу эш укыту-тәрбия процессына зур үзгәрешләр кертүне таләп итә. Белем бирү программалары үзгәртелә, белем эчтәлеге яңа күнекмәләр белән баетыла, мәгълүмат туплауның гадәти ысуллары – телдән һәм язма сөйләм компьютер чаралары белән алмаштырыла. Яңа технологияләр ярдәмендә белем бирү укучыны тагын да активлаштыра, анда мөстәкыйльлек тәрбияли. Ә инде компьютер технологияләрен куллану фәнне югары дәрәҗәдә үзләштерү, максатка омтылучанлык, информацион технологияләр дөньясындагы яңалыклар белән кызыксыну теләге уята.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Мәктәптә белем бирүче мөгаллимнәр алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, белем һәм тәрбия бирү бурычы булса, икенчедән, фәнне

өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы тора. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә. Бүгенге көн укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Тәҗрибә педагогик эшчәнлекнең нигезе булса, яңалыкка омтылу үсеш-үзгәрешне тәэмин итә. Заманча технологияләр файдаланып белем бирү түбәндәге мөһим бурычларны үтәргә ярдәм итә: укучыда фәнгә кызыксыну уята; аның танып белү активлыгын үстерә; укучыларның иҗади мөмкинлекләрен камилләштерә; белемнәрне тирәнәйтә.

Яңа мәгълүмати технологияләр куллану кызыксынучанлыкны арттыра, белем сыйфатына, уку-укыту нәтиҗәлелегенә, укучының шәхес булып тәрбияләнүенә йогынты ясый. Бу җәһәттән, яңа мәгълүмати технологияләр үзләре үк танып белү, белем туплау коралына әверелә, гомумиләштерү, эзләнү, үстерү, дәртләндерү, тәрбияви һәм контрольгә алу, төзәтмәләр кертү функцияләрен үти. Әмма әлеге яңа мәгълүмати технологияләр телне үзләштерүне тулысынча алыштыра алмый, ә бары тик дәрескә файдалы өстәмә, укучылар һәм укытучылар өчен үзлектән белем алуда үтемле чара булып тора ала.

Мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне дәресләрдә уңышлы куллану өчен кирәкле җиһазлар, компьютерда эшли белү осталыгы, электрон өйрәтү материаллары һәм Интернеттан алынган материалларның булуы кирәк. Дәрестә укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыклырак итә. Бүгенге көндә мәктәпләрдә мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Без бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшебездә кулланырга тырышабыз. Әмма һәрбер дәресне дә мәгълүмати технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт та таләп итә.

Дәресләрдә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп. Бу метод укучыларны компьютер белән эшли белергә, текст процессоры ярдәмендә төрле документлар,

график программалар, иллюстрацияләр әзерләргә, гади программалар төзергә, электрон почтадан һәм интернеттан дөрес файдаланырга өйрәтә.

Дәресләрдә басма күрсәтмә материаллар күп булмаганда, укучылар интернет челтәренә чыгып, сайтлардан төрле кызыклы материаллар бастырып алалар. Белемнәрне тикшерү дәресләрендә файдалану өчен төрле программада тестлар әзерләүдә дә укучылар ярдәм күрсәтәләр. Тестны эшләп бетергәч, компьютер нәтиҗә ясап, билге куя.

Дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. Power Paint программасында төрле иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратып та бирергә була. Бу эшләрне дә укучылар бик теләп башкара. Укучылар мөстәкыйль презентацияләр эшлиләр. Шулай ук видеотехниканы куллану да отышлы. Түбән сыйныф укучылары мультфильмнар карарга бик яраталар. Компьютер презентацияләреннән файдалану күрсәтмә материалны куллануны үстерә, предметара элемтәне ныгыта, дәреснең җитештерүчәнлеген арттыра, укытучы һәм укучы мөнәсәбәте ныгый. Мәгълүмати технологияләрне катнаш дәрестә, дәрес-лекциядә, проект яклаганда, семинар-дәрестә дә кулланырга була.

Шуны да әйтергә кирәк, дәрестә компьютер куллану белән артык мавыгырга да ярамый, чөнки ул укытучы белән укучының үзара аңлашуын, аралашуын алыштыра алмый. Компьютер соңгы елларда уку процессында актив кертелгән яңа һәм иң мөһим чараларның берсе булып тора. Аны куллану яңа мәгълүмати технологияләр барлыкка килүгә ярдәм итә. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинлекләрен файдаланып, өйрәнүчегә мәгълүматны әзерләү һәм тапшыру процессы ул.

Алда әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә ярдәм итә торган технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез.

Барыннан да элек алар – шәхескә юнәлтелгән ныклы һәм вариатив. Төрле технологияләр, компьютер, мультмедиа технологияләре күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Заман таләбе буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, дәресләрендә компьютер технологияләрен куллану бик отышлы дип саныйм мин. Мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп: дәрес материалы югары күрсәтмәле дәрәҗәдә була, укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар, төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Дәресләрендә мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләр куллану укучыларда фәнне тагын да ныграк өйрәнүгә кызыксыну уята һәм мәгълүмати җәмгыятьтә яшәргә әзерлек булып тора.

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Морозов К.А. Информационно-коммуникативные технологии и их применение в педагогический деятельности // Личность, семья и общество: вопросы педагогики и психологии: сб. ст. по матер. XXX междунар. науч.-практ. конф. – Новосибирск: СибАК, 2013.

2. Лехтина Л.П. Педагогика буенча информацион коммуникатив технология модельләре [электрон ресурс].

## БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЙЛАРЫ

*(Хәзерге татар әдәбиятында волонтерлык юнәлешенең чагылыш табуы)*

*Галиева Лилия Альберт кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары,*
*Татарстан Республикасы Минзәлә ш. «Гимназия» ГББМБУ*

Кешеләргә без яхшылык эшлик!
Эшләмәсәк – гарьлек.
Тик яхшылык эшләү җиңел түгел,
Ул – зур фидакарьлек.
***Роберт Миңнуллин***

«Ярдәм күрсәтүнең исемен үзгәртеп кенә асылы үзгәрми, – ди «Волонтер» Төбәкара яшьләр җәмгыятенең координаторы Роберт Халиков. – Тимурчылык дип атасак та, волонтерлар дисәк тә – иң мөһиме, яхшылык эшләргә омтылу. Аермасы юк, бары тик эш алымнары гына заманчарак» [4, 14 б.].

Рус әдәбиятында 40 елларда А. Гайдарның «Тимур и его команда» дигән әсәре басылып чыга. Әлеге әсәр җәмгыятьтә зур шау-шу уята. Кемнәр соң ул тимуровчылар? Рус теленең аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать итсәк, «тимурчылар» – патриотик рухлы балалар төркеме [5, 732 б.]. Алар – сугыш гаиләләренә, ятим калган балаларга, картларга ярдәм итеп йөрүче яшь егетләр-кызлар. 80 елларда бу термин телдән төшеп кала. Аның урынына «волонтерлар» сүзе кулланыла башлый. Волонтерлар дип мәрхәмәт, шәфкатьлелек йөзеннән ярдәм итеп йөргән яшьләрне атыйлар.

Хәзерге вакытта «волонтерлар» терминының аңлатмасы киңәйде. Волонтерларсыз бүген бер генә чара да узмый. Бүгенге көндә без аларны дөньякүләм спорт ярышлары, авыруларга ярдәм, югалган кешеләрне эзләү, төрле акцияләрдә күрә алабыз.

Рус әдәбиятындагы кебек татар әдәбиятында да бу юнәлешкә мөрәҗәгать итүчеләр бар. Хәзерге заман әдәбиятына игътибар итсәк, Ләбибә Ихсанова, Роберт Миңнуллин, Айдар Гыймадиев, Айсылу Галиева, Сирень Якупова, Ркаил Зәйдулла кебек язучыларны атый алабыз. Аларның шигырь, хикәя, повестьларында – бүгенге тормыш, мәктәп, гаилә һәм тынгысыз үсмерләр. Проблемалар тормыштагыча кайнар, хәвефле һәм катлаулы, аларда һәркайсыбызны борчыган актуаль мәсьәләләр куела. Психологик тирәнлеге, чынлыгы белен ышандыра алар сурәтләгән тормыш.

Ләбибә Ихсанова – А. Гайдар һәм А. Алиш традицияләрен дәвам итүче язучыларның берсе. Ул үсмерләр турында белеп һәм яратып, кайгыртып яза. «Саралан малайлары», «Космонавтлар урамы» әсәрләрендә балаларның зурларга ярдәм итүләре, маҗаралы уеннары, үзара дуслыклары турында сөйли.

– Шәймәрдән бабай, бир әле, бу алны үзем чабып чыгыйм, – дип, Шамил аның чалгысына үрелде, – син ял итеп тор. [3, 156 б.]

– Нияз, әйдә әле, – диде Шамил һәм сыңар аяклы өстәлгә күрсәтеп, – менә шуны рәтләп куйыйк әле. [3, 163 б.]

– Уйлап торасы юк, – диде аңа каршы Фатыйма. – Көне-төне эшли бит, арый торгандыр. Бакча каравылларга булышырга кирәк аңар. [3, 190 б.]

Айдар Гыймадиевның иҗатында «Телефонлы кәҗә», «Изге эшләр дәфтәре», «Разведчиклар» кебек әсәрләренә игътибар иттек. Гомумән, Алмаз Гыймадиев озын әсәрләр белән мавыкмый, аның иҗатында балаларның мавыктыргыч тормышын чагылдырган кыска-кыска әсәрләр урын ала. Ул көн дә булып торган хәлләрне йомшак юмор, урыны белән чәнечкеле юллар аша сурәтли. Нинди дә булса бер хикмәт ясап куйган бу балаларның көлкегә калуын автор ышандырырлык итеп бирә.

«Изге эшләр дәфтәре» әсәрен генә алыйк. Төп герой – бишенче сыйныфка күчкән Динар. Укытучы Мөэминә апалары аларга «Изге эшләр» дәфтәре башларга куша. Өстәвенә, бу изге гамәлләр көненә өчтән ким булмаска тиеш, ди. Ягъни, сыерчыкларга оя ясау, күрше әбинең утынын ярып бирү, иптәшеңә укуда булышу һ.б., дип аңлата укытучы апалары.

Автор вакыйгаларны берникадәр юмор-сатира аша сурәтләп, чынбарлыкта булган проблемаларны күрсәтергә тели. Тормышта хәзер дә ярдәмгә мохтаҗ кешеләр байтак: балалары читкә китеп, ялгыз калган әби-бабайлар, ризык эзләүче кош-кортлар, ташландык көчекләр...

Динар да ул көнне изге эшләр башкара. Тик ул аларны дәфтәргә язып куяр өчен генә эшли, шул сәбәпле нәтиҗәсе дә кызганыч була. «...башында «гениальный» план формалашкан иде. Ул хәзер сыерчык оясы ясаячак! Дөрес, сыерчыклар, бәлки, китеп тә беткәндер... Стоп! Чоланда агач тартмалар күп, ясап торасы да юк, тишек кенә тишәсе...» Шулай ул әнисенең дөге ярмасы белән тозын берләштерә, эш коралларын тапмау сәбәпле, тишекне «штыковой» көрәк белән тишә. Динарда тизрәк эшләп бетереп, уйнарга чыгу теләге зуррак, шуңа күрә «чүбекле дәфтәренә бер көндә теркәлгән дүрт изге эше» аның «бәйрәмски кәефен» төшерүгә сәбәп була. Тагын бер мисал.

– Соң, бабай, неужели аңламыйсың, менә шушындый дәфтәр башлаттырдылар... ие... әби-бабайларның утынын ярырга куштылар...

– Ә-ә-ә... сез теге кемнәр мәллә, тимерчеләр...тимурчылар мәллә? – дип җанланып китте Сәхәбетдин карт, эшнең асылын аңлап алгач. – Утыным ярылган бит минем, улым. Мунчага берике бидон су алып кайтсаң ярар иде үзе...

– Бабай, безгә мунча турында бер сүз дә әйтмәделәр.

– Алайса, утының ярылган булгач, Динар ярды, дип, менә бу төшкә кулыңны гына куй инде, җәмә [2,66 б.].

Динарның башка эшләгән «яхшылыклары» да үзенә киресе белән әйләнеп кайта. Ачык калган канализация чокыры капкачын, берәрсе төшеп китмәсен дип, иптәшләрен дә чакырып ябып куйганда, анда сантехник Әбелбәкер абзый бар икәнен башына да китерми.

«Разведчиклар» әсәренә мөрәҗәгать итсәк, монда да тимурчылар хәрәкәтене тасвирлана. Әсәр хатирәләр формасында язылган. Төп герой – Мулланур бабай. Яшь чакта аларның отряды авыл читендәге Миңниса әбине шефлыкка алырга баралар. Малайлар кар көри, кызлар идәнен юалар. Бервакыт өч малай Сәйфелмөлек бабайның утынын кисәләр. Тимурчылар булып йөргәндә, тимер-томыр, өй борынча тотылган кәгазь җыеп йөрүләр дә нык истә калган. Их, пионер чакларның кабатланмас хатирәләре диген! Ул чаклардан инде бик күп вакытлар үтүгә карамастан, тимурчылар хәрәкәте дәвам итә. Менә хәзер аның үзенә дә ишек шакып тимурчылар килде.

– Тә-әк, бер сәгатьтән палас кагарга кызлар килеп җитәр. Ә безгә – дәлше! – диде тәреле малай һәм бик эшлекле кыяфәттә иптәшен ияртеп чыгып та китте.

Бүлмәдәге әйберләрнең исән-сау икәнлегенә сөенеп, Мулланур абый янә креслога чумды. «Ә шулай да яшьләр начар түгел хәзер», – дип уйлады ул, мыек астыннан гына көлемсерәп [2,34 б.].

Автор юкка гына тимурчылык хәрәкәтен ике буын вәкилләре үрнәгендә күрсәтми. Бүгенге көн балалары белән чагыштырганда, өлкән буын бу эшкә җаваплырак караган, пионер, комсомол исеменә дә тап төшерүдән курыкканнар. Хәзер тимурчылык күбрәк мәктәп, мөгаллимнәр таләп иткәнгә генә яшидер сыман. Тик ни генә булмасын, тәрбия чарасы буларак, тимурчылык хәрәкәтенең файдасы бәхәссез. Мәрхәмәтлелек, мохтаҗларга ярдәм итү, өлкәннәргә игътибарлы булу, кешеләргә яхшылык эшләү кебек изге төшенчәләрне балалар күңеленә сеңдерү өчен, бу хәрәкәт әле дә кирәк. Безнең заман геройларына карасак, чып-чын каһарманнар безнең арабызда да бар бит ул! Алар батырлык эшләгәннәре турында анда-монда сөйләп йөрми, тыныч кына яши бирә. Бүгенге көндә дә изгелек эшләүчеләр шактый күп. Бу урында, илебездә барган мөһим вакыйгаларга битараф калмыйча, үз өлешен керткән гимназия волонтерлары Вәлиева Ләйсән, Гыйләҗетдинова Лилия, Мөхәммәтдинова

Айсылу кебекләр турында да әйтеп китәсе. Ләйсән, мәсәлән, Кытайга барып, балаларга инглиз теле укыта; Лилия белән Айсылу Универсиадада волонтер хезмәтен башкаралар...

Сүзебезне йомгаклап, Габдерәхим Утыз Имәни сүзләрен китерәсебез килә:

Гаделлек кыл, лаек бул изгеләргә,
Тузан чаклы җәва кылма берәүгә.

**Чыганаклар исемлеге:**


1. Ганиева Ф.Ә. Әдәбият.10 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә.1 кисәк / Ф.Ә. Ганиева, Д.М. Абдуллина, Ч.Р. Рамазанова. – Казан: Татар. китап. нәшр., 2016. 239б.
2. Гыймадиев А.М. Ниязның рекордлар китабы: Хикәяләр / Алмаз Гыймадиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 79 б.
3. Ихсанова Л. Космонавтлар урамы. Повестьлар. Тат. Китап.нәшр., 1978. – 280 б.
4. Низамова Л. Яңа заман тимурчысы./ Низамова Л. //Гаилә һәм мәктәп – 2015. – № 8, 14-15 б.
5. Ожегов С.И. Словарь русского языка. Около 57 000 слов. Изд.10-е. Под ред. д-ра филол. наук проф. Н.Ю. Шведовой — М.: Советская энциклопедия, 1973. – 876 с.
6. Якупова С. Уран/ Якупова С. // Казан утлары. – 2017 – №9 – 123-127 б.


## НАРОДНЫЕ ТРАДИЦИИ, КАК СРЕДСТВО РАЗВИТИЯ ЛИЧНОСТИ ШКОЛЬНИКА В УРОЧНОЙ И ВО ВНЕУРОЧНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ


*Гаряпова Галия Накифовна,*
*учитель родного (татарского) языка и литературы*
*высшей квалификационной категории,*
*МБОУ «Никольская средняя общеобразовательная школа»*
*Спасского муниципального района РТ*



*Автор статьи, являясь учителем родного (татарского) языка и литературы и педагогом дополнительного образования, делится опытом работы по сохранению и укреплению народных традиций на уроках родного (татарского) языка и*

*в деятельности объединения дополнительного образования «Мирас». Данный материал может быть интересен и полезен учителям родного языка и специалистам дополнительного образования*

Урок и внеурочное занятие – это основные формы работы школы, позволяющие решать педагогические, воспитательные задачи.

Я 36 лет работаю в МБОУ «Никольская СОШ», в школе, где обучение ведется на русском языке. Преподаю русскоязычным учащимся и детям-татарам предметы «Родной (татарский) язык», «Родная (татарская) литература», «Государственный татарский язык в Республике Татарстан». И на своих уроках считаю очень важным формирование коммуникативных универсальных учебных действий, что обеспечивает правильное и умелое использование речи в различных жизненных ситуациях.

Личностные универсальные учебные действия также являются приоритетными. Положительное решение такой актуальной задачи как: осознание себя как гражданина, как представителя определенного народа, определенной культуры, гордиться историей своего народа, проявлять интерес и уважение к культуре других народов – во многом зависит и от нас, от учителей.

2023 год в Республике Татарстан объявлен  Годом национальных культур и традиций / Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы. Цель этого года: способствовать сохранению и укреплению духовных ценностей, возрождению исконных национальных традиций.


Какие задачи можно решать на уроках при изучении такой, казалось бы, на первый взгляд, узкой, но в то же время такой емкой темы, как «Татарские национальные блюда»? Эта тема изучается в каждом классе, названия разные: «Ашханәдә» («В столовой»), «Супермаркет», «Тәмле булсын!» («Приятного аппетита»), «Туган көндә» (В день рождения») и т.д.



При подготовке к уроку, связанного с темой «Татарские национальные блюда» стараюсь организовать выставку книг с рецептами различных блюд.




Использую цифровые образовательные ресурсы: «Сәлам», «Бала.РФ», «Открытая школа» и другие, где предлагается разнообразный аудио-видеоматериал.



Элементы устного народного творчества (фольклора) ввожу в фонетическую зарядку (песни, пословицы, считалки и др.).

При подведении к теме урока часто использую кроссворды, ребусы.


Например, знакомство с рассказом Р.Валеевой «Туган көндә» («На дне рождения») провожу с использованием материала мультимедийной библиотеки ресурса Бала.РФ.




После анализа произведения вместе с детьми приходим к выводу:

**Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.**

**Будешь почитать старших и сам будешь жить в почете.**




Стол, накрытый разными блюдами, выступает как символ, объединяющий семью.

В изучении национальной культуры для формирования толерантного мышления школьников, умения понимать и уважать культуру других народов большую роль играет дополнительное образование.



На базе своей школы от МБОУ «Дом детского творчества» Спасского района РТ веду кружок «Мирас». Цель кружка: формирование у учащихся положительного отношения к языку и культуре татарского народа. Содержание программы включает в себя темы по многим направлениям: музыка, танец, театр, архитектура и многое другое.






В октябре проводим традиционный праздник урожая (Праздник труда) «Сөмбелә» на двух государственных языках: татарском и русском.

21 марта интересно проводим праздник Навруз, праздник Нового года у восточных народов. 25 декабря знакомим детей с праздником Нардуган – праздник зимнего солнцестояния





Раздел «Особенности быта татар». Тема. Интерьер татарской избы»






В VK (Вконтакте) есть свое сообщество, которое ведем на двух языках: татарском и русском. Ссылка на наше сообщество: https://vk.com/sheptatar2.

Наша задача и в дальнейшем способствовать развитию способностей школьников к общению в многоконфессиональной и поликультурной среде на основе взаимного уважения и диалога во имя общественного мира и согласия.

**Список источников:**

1. Блинов Г.П. Роль национальных обычаев и традиций в сознательной регуляции поведения. – М., 2009.
2. Бәйрәм бүген!: сценарийлар, шигырьләр, бәйрәмнәр тарихы/ авт. – төз. Г.Р. Закирова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 183 б.

## БАЛАЛАРНЫҢ ИҖАТЛАРЫ АША ТУГАН ТЕЛНЕ ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ

*Гатауллин Раил Мәүлет улы,*
*коммерцияле булмаган «Татнетны үстерү фонды» оешмасының башкаручы директоры*

Телне саклау милләтне саклауның төп нигезе булып тора. Бу юнәлештә күп милләтле Россия Федерациясенең төп документында – 2025 елга кадәр Дәүләт милли сәясәте стратегиясендә Россия халыкларының этномәдәни күптөрлелеген саклау, милләтнең гражданлык үзаңын һәм рухи бер-

дәмлеген ныгыту каралган. Рәсми мәгълүматларга караганда, Россия Федерациясендә 193 милләт вәкиле яши, 277 тел һәм диалект кулланылышта. Шулар арасыннан, ЮНЕСКО тарафыннан 2010 елда нәшер ителгән «Югалу куркынычы янаган дөнья телләре атласы» мәгълүматларына караганда Россиядә 139 телгә якын киләчәктә югалу куркынычы яный.

Бу мәгълүматлар белән якыннан танышкач, әлеге мәсьәләнең бик мөһим проблема икәнен аңлыйсың һәм күп кенә сорауларга җавап эзли башлыйсың. «Үземнең туган телемне ничек сакларга?», «Киләчәктә татар теле саклансын өчен мин ни эшләргә тиеш һәм нинди эшләр башкара алам?» һ.б.

Сораулар катлаулы, әмма бу сорауларга җаваплар ачык күренеп тора. Сорауларга бер генә түгел, берничә җавап бирергә, әлеге җавапларны һәрдаим тулыландырып та торырга мөмкин.

Татар теле буларак туган телне саклау мәсьәләсе – республикабызның һәр гражданы бурычы. Телне саклау өчен – әлеге телдә сөйләшергә, аралашырга, язышырга һәм һәрдаим, әдәби әсәрләр, китаплар, татар телендә башка төр файдалы мәгълүматлар укып, телне баетып торырга кирәк. Әлеге мәсьәләдә Татнетны үстерү фондының Татарстан Язучылар берлеге белән берлектә оештырылган һәм Россия күләмендә югары бәя бирелгән #ӘдәбиМарафон проекты ярдәм итә. Монда һәр катнашучы, әдәби әсәрләр укып, тел байлыгын арттырып кына калмый, текст язганда орфографиягә игътибар итә, татар клавиатурасы кулланып язып текстның грамоталылыгына игътибар бирә, дөньяда сибелеп яшәгән бик күп фикердәш татарлар белән дуслаша һәм аралаша, рухын ныгыта, туган теленең һәм үзенең көчен тоя, социаль челтәрләрдә укыган әсәрләреннән кызыклы һәм файдалы өзекләр урнаштырып барып үзенең дусларын, туганнарын да татарча китаплар уку белән кызыксындырып җибәрә. Ә иң мөһиме – үзләренең балаларын, оныкларын да әти-әнисеннән, әби-бабасыннан үрнәк алып, татарча китаплар, әдәби әсәрләр укуга җәлеп итә.

Монда инде икенче сораугa – «Киләчәктә татар теле саклансын өчен мин ни эшләргә тиеш һәм нинди эшләр башкара алам?» дигән сораугa җавап башлана. Үзендә татар әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләп, ул әлеге мәхәббәтен балаларына да күчерә. Ә балалар – ул безнең киләчәгебез. Һәм балаларда туган телне саклап кына без киләчәктә татар телен саклап кала алабыз.

Татнетны үстерү фонды балаларның иҗатлары аша туган телне үстерүгә аерым әһәмият бирә. Әлбәттә, китап уку, әдәби әсәрләр уку – телне баетуның төп чарасы. Әмма теләсә кайсы тел вакыт узу белән үзгәрә, камилләшә, анда яңа төрле терминнар барлыкка килә һ.б. Бары тик телне үзебез формалаштырып, үзебез тулыландырып алып барганда гына анда алынма сүзләр кулланмаячак, татар теле яхшы якка үзгәреш кичерәчәк. Ә моның өчен яңаны булдырырга, иҗат итәргә кирәк.

Бу уңайдан Татнетны үстерү фонды #ӘдәбиМарафон проекты кысаларында һәр катнашучы өчен «Миллион татар» журналын нәшер итә башлады һәм, журналда төрле файдалы мәкаләләр урнаштыру белән беррәттән, әлеге журналда балаларның иҗатларына да зур урын бирелә.

Моннан тыш, Татнетны үстерү фондының Белем.ру порталы (Образовательно-просветительское сетевое издание «Белем.ру». Свидетельство о регистрации СМИ Эл №ФС77-83553 от 26 июля 2022 г.) белән берлектә оештырылган күп кенә иҗади чаралары, бәйгеләре, конкурслары бар. Мисал өчен, әле күптән түгел генә «Пиксель һәм нокта», «Күңел түреннән» иҗади бәйгеләре гөрләп үтте. IT-иҗат юнәлешендә «Яшь вебмастерлар», «Белем җәүһәрләре» кебек конкурслар үткәрелүен әйтеп китәргә кирәк (бу юнәлештә үткәрелә торган барлык чаралар белән https://belem.ru/konkurslar адресы буенча һәм Татнетны үстерү фондының рәсми сайтында https://tat-i.net/tt танышып барырга мөмкин). Яңарак кына «Моё перо – Минем каләмем» иҗади конкурсы игълан ителгән иде. Әлеге конкурс исә «Белем радиосы» базасында оештырыла.

«Белем радиосы» проектына аерым тукталып китәргә кирәктер. Әлеге проект Мәдәни инициативалар буенча Президент фонды гранты ярдәме белән Татнетны үстерү фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла. Радио 2022 елның 26 августында #ӘдәбиСабантуе чарасында тантаналы төстә ачылды. Бүгенге көндә әлеге билингваль (русча-татарча) интернет радиода өч дистәгә якын тапшыру һәм рубрика бар. Аларны, профессионаллар белән беррәттән мәктәп укучылары һәм студентлар әзерли. Әлеге иҗади эштә актив катнашып алар республикакүләм һәм россиякүләм бәйгеләрдә үзләре дә зур җиңүләр, гран-прилар, I, II, III урыннар яулыйлар.

Татнетны үстерү фонды мондый талантлы, ныклы рухлы, белемле, эрудицияле киләчәк буынны үстерү һәм формалаштыруны үзенең төп максатларының берсе итеп куйды. Әле

яңа гына «Белем радиосы» кастинг та игълан итте. Максатыбыз – әлеге радио мәктәбендә радиожурналист кына әзерләү түгел, ә республикабызда киң карашлы, эрудицияле, елгыр, уңышка ирешүне максат итеп куйган, ныклы рухлы, яхшы сөйләм телле киләчәк буынны үстерү. Тулырак мәгълүмат һәм кастингның нигезләмәсе белән «Белем радиосы»ның рәсми сайтында (https://radio.belem.ru), ВКонтакте берләшмәсендә (https://vk.com/radio_belem) һәм Telegram-каналда (https://t.me/radio_belem) танышырга мөмкин.

Татнетны үстерү фондының һәм «Белем.ру» компанияләренең балалар һәм яшүсмерләр өчен булдырылган проектлары һәм проектларда катнашучылар саны арта бара. Монда төп күрсәткеч – катнашучылар саны артуын гына түгел, ә катнашучыларның белем, эрудиция, туган телне белү дәрәҗәсе үсеше, шулай ук физик, рухи һәм иҗади яклардан үсеш булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Үз чиратында, әлеге максатларга ирешү гади катнашучыларның үсешләренә генә түгел, ә киләчәк буын татар җәмгыяте үсешенә үк китерә. Ә инде җәмгыятебезнең киләчәген һәм үсешен булдыру – һәр гражданның бурычы.

## ОСНОВЫ РОБОТОТЕХНИКИ В ШКОЛЕ НА УРОКАХ ТЕХНОЛОГИИ

*Гиматова Гульчачак Шайхиевна,*
*учитель технологии первой квалификационной категории,*
*МБОУ «Бурметьевская средняя общеобразовательная школа Нурлатского муниципального района Республики Татарстан»*

*С 1 сентября 2022 года в силу вступили обновлённые ФГОС, которые касаются каждой школьной учебной дисциплины. Предмет технологии построен по модульной системе новых стандартов. Робототехника является одним из модулей, включенных в изучение предмета технологии.*

Молодое поколение живет в эпоху активной информатизации, компьютеризации и роботостроения. Сегодня государство испытывает острую потребность в высококвалифицированных специалистах, обладающих высокими интеллектуальными возможностями. И начинать готовить будущих инженеров нужно не в вузах, а значительно раньше – в младшем школьном возрасте,

когда у детей особенно выражен интерес к техническому творчеству. Поэтому, робототехника приобретает все большую значимость и актуальность в настоящее время. Включает в себя предметы: математику, физику, информатику. Ее цель – это изучение конструирования, программирования и электроники. Задача педагога – развивать навыки конструирования и программирования.

Робототехника – создание роботов с помощью различных конструкторов, таких как:

LEGO MINDSTORMS, WEDO 2.0, VEX, TETRIX, ARDUINO, ТРИК. (смотри в приложении).

В начальной школе закладываются основы конструирования и программирования и работы всевозможных механизмов. Занимаясь конструированием роботов, у учащихся развивается ответственность, дисциплина, умение работать в команде, воображение и внимательность.

Давайте рассмотрим плюсы робототехники в школе: робототехника может стать стартовой площадкой для школьников, «горящих» техническими науками; хорошая учебная программа по робототехнике позволит развивать лидерские качества у учеников; робототехника может научить школьников, как работать на разных технологических и информационных платформах; робототехника учит работать в команде.

В нашей школе (МБОУ «Бурметьевской СОШ Нурлатского муниципального района РТ») познать азы конструирования и программирования маленьким исследователям позволяет набор конструктора MATATALAB http://matatalab.pro.

1 и 2 классы начинают заниматься на наборах Мататалаб. Программа устроена таким образом, что учащийся не пишет программу, а составляет ее из готовых блоков. В его распоряжении имеется набор, из которой он может брать готовые блоки, перетаскивать их на рабочее поле и встраивать их в цепочку программы. С помощью этой программы модели «оживают». Она ориентирована на развитие мелкой моторики; формирование алгоритмического мышления. Работая в этой программе, для учащихся можно проводить различные соревнования и конкурсы.

Учащиеся 3-5 классов начинают работать на более сложных конструкторах VEX. Обучающиеся не только собирают

собственного робота, но еще и программируют его. Занятия робототехникой могут стать отличной базой для будущей профессии ребенка.

На занятиях так же использую: видеоролики, презентации, загадки, проблемные ситуации, для закрепления материала использую онлайн тесты. https://onlinetestpad.com/.

Разработала различные задания, например:

**Задание 1.** Придумайте и нарисуйте собственного робота. Дайте роботу имя, придумайте, что он будет делать, какие команды он сможет выполнять.

**Задание 2.** Расмсотрите свой телефон, определите его марку. Найдите в интернете, на базе какого микропроцессара он разработан. Определите микропроцессоры, на базе которых разработаны телефоны ваших, родителей, телефоны близких друзей. Заполните таблицу «Микропроцессоры телефонов».

**Таблица. Микропроцессоры телефонов.**

| Марка и модель телефона | Страна производитель | Микропроцессор |
|---|---|---|
| | | |

Помимо основных занятий по робототехнике провожу различные внешкольные мероприятия, позволяющие привлечь интерес к данному направлению. Это круглые столы по робототехнике, мастер-классы по конструированию и программированию роботов, конкурсы, где юные таланты могут посоревноваться и поделиться собственным опытом.

В своей работе использую в качестве основного пособия для проведения занятий кружка «Введение в робототехнику» методическое пособие, прилагаемое к конструктору, включающее книгу для учителя и комплект заданий для учащихся.

**Проблемы робототехники.**

Главная проблема – отсутствие условий и оборудования во многих общеобразовательных школах для проведения занятий робототехника. Для активных занятий робототехникой

нужны специально оборудованные классы, компьютеры и конструкторы. Это главная проблема невозможности использовать эту технологию.

В заключении, учителя технологии должны работать в ногу со временем как бы нам ни хотелось.

**Список источников:**


1. Каширин Д.А. Основы робототехники VEX IQ / Д.А. Каширин, Н.Д. Фёдоров. – 4-е изд. – Москва: Экзамен технолаб, 2016. – 184 с. – Текст: непосредственный.
2. Тарапата В.В. Робототехника в школе: методика, программы, проекты / В.В. Тарапата, Н.Н. Самылкин. – 2-е изд. – Москва: Лаборатория знаний, 2021. – 112 с. – Текст: непосредственный.


Приложение

**QR-коды и ссылки на конструкторах, используемые в обучении робототехники**

| Названия | QR-код | Ссылки |
|---|---|---|
| VEX | | http://vexacademy.ru/vex-iq-info.html |
| LEGOMINDSTORMS | | https://www.exoforce.ru/lego-downloads |
| WEDO 2.0 | | https://education.lego.com/en-us/downloads/retiredproducts/wedo-2/software |
| TETRIX | | https://www.pitsco.com/Shop/TETRIX-Robotics |

| | | |
|---|---|---|
| ARDUINO | | https://www.arduino.cc |
| ТРИК | | https://trikset.com |
| MATATALAB | | http://matatalab.pro |

## РАЗВИТИЕ ИНФОРМАЦИОННОЙ ГРАМОТНОСТИ У УЧАЩИХСЯ

*Гиниятуллина Рамиля Ильдаровна,*
*учитель начальных классов,*
*МБОУ «Высокогорская средняя общеобразовательная школа № 1 Высокогорского муниципального района Республики Татарстан»*

*Современные учащиеся недостаточно владеют информационной грамотностью. Одной из самых важных проблем современного общества является развитие информационной грамотности (ИГ) у людей. На сегодняшний день одной из самых важных проблем современной школы является развитие информационной грамотности у учащихся.*

Наличие огромного информационного потока не может само по себе сформировать подготовленных пользователей без дополнительного набора необходимых знаний и навыков по эффективному использованию информации. Три главных способа решения проблемы: первый способ, современное образование должно быть направлено на то, чтобы дети могли оперировать потоками информации, т.е. осуществлять поиск, отбирать нужное и передавать эту информацию, выделять

время, отведенное для того, чтобы дети пересказывали своим одноклассникам прочитанное ими во внеурочное время литературное произведение или какие-либо интересные факты; устраивать дискуссии, дебаты между учащимися. Второй способ, должны быть информационно грамотные учителя (создать бесплатные курсы по формированию информационной грамотности для учителей при школе; контролировать уровень информационной грамотности учителя при приеме на работу). Третий способ, поощрять учителей и учащихся, которые стремятся повысить свою информационную грамотность (учителей – премией; учеников – грамотами или приятными подарками).

Второй способ эффективнее потому, что задача по развитию информационной грамотности у учащихся может быть решена только после того, как педагоги сами овладеют информационной культурой.

**Список источников:**

1. Азимов Э.Г. Информационно-коммуникационные технологии. / Э.Г. Азимов. – М.: Русский язык. Курсы, 2018. – 352 с.

## ИНТЕРНЕТ – ДУСМЫ, ДОШМАНМЫ?

*(Мастер-класс)*

*Гыйлмуллина Чулпан Зөлфәт кызы,*
*информатика укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы*
*«Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» ГББМБУ*

*Мастер класс Интернетның уңай, тискәре яклары турында сөйләшү өчен укытучылар яки югары сыйныф укучыларына кулланма була ала.*

– Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар! Мин сезнең барыгызны да бирегә чакырам. Бөтенебез бер түгәрәк ясап басыйк әле. Минем кулымда йомгак, аның бер очын үземдә калдырып, мин аны сезнең берегезгә тапшырам һәм әлеге сүзләрне әйтәм: «Исәнмесез! Минем исемем... Мин сезне бүгенге мастер класста күрүемә шатмын!». *Һәр кеше, җепнең бер очын үзендә калдырып, шул сүзләрне әйтеп йомгакны үзе теләгән кешегә тапшыра.*

*Йомгак алып баручыга әйләнеп кайта.*

– Ничек уйлыйсыз нәрсә турында сөйләшәчәкбез? Бу җепләр нәрсәгә охшаган? (Катнашучыларның җаваплары: челтәргә һ.б.). Нинди челтәр турында сөйләшербез? Безнең тормышыбызга киң үтеп кергән – Интернет челтәре, андагы куркынычсызлык кагыйдәләре турында сөйләшәчәкбез. Мастер класс ахырында һәрбер группа проектның үз өлешенә туры килгән өлешен яклаячак.

– Мин сезне үземнең кечкенә генә уңайлы кафема чакырам. Өстәлләргә төрле төстәге эскәтерләр җәелгән, сез үзегезгә нинди төс якын шул өстәл артына утыра аласыз.

Бүгенге көн белем бирү системасы заман белән бергә атлый. Җәмгыятькә иҗади фикерли белүче, аралашучан, талантлы кешеләр сорала. Мәктәпләрдә шундый һәр яктан килгән шәхесләр тәрбияләүгә укучы шәхесенә юнәлдерелгән яңа педагогик технологияләр куллану ярдәмгә килә.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану – яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Мин дәресләремдә инновацион технологияләрне уңышлы кулланам. Бүген проектлар технологиясе һәм аны тормышка ашыру чарасы буларак «Дөньяви кафе» (World cafe) технологиясен кулланырбыз. Беренчесе барыгызга да яхшы таныш булса, икенчесе белән кыскача гына якыннанрак таныштырып китәм.

Бүген группаларда эш ничек оештырылачак, аңлатып китәм.

1. Һәр группада сезнең теләкләр буенча өстәлнең «хуҗасы» билгеләнә, калган катнашучылар – кунаклар.
2. Өстәл хуҗасы башкаларны кәгазь стикерларда язылган биремнәр һәм сорауларның эчтәлеге белән таныштыра.
3. Өстәл хуҗасы җитәкчелегендә катнашучылар 7 минут эчендә бирелгән биремнәрне үтиләр, сорауларга җавапларны, үз идеяләрен өстәл өстендәге чиста кәгазь битләренә язалар.
4. Барлык биремнәрне үтәгәннән соң, алар икенче өстәлгә күчәләр һәм шул өстәлнең биремнәрен үтиләр, үз фикерләрен өстиләр.
5. Процедура кунаклар барлык өстәлләрне дә әйләнеп чыкканчы дәвам итә.
6. Кунаклар үз өстәлләренә әйләнеп кайтканнан соң, башкаларга бергәләп эшләнгән эш нәтиҗәләрен күрсәтеп чыгыш ясыйлар. Һәр өстәл проектның бер өлешен яклый.

Бүгенге безнең тема: «Интернет – дусмы, дошманмы?». Әгәр сезгә алдыгызда торган бурычлар һәм проблема аңлашыла икән, эшкә керешәбез!

Һәрбер өстәлнең уртасына алар чишәргә тиешле проблема, сораулар язып куелган. Бөтен эшчәнлек вакытында кунаклар үз фикерләрен, идеяләрен шунда язалар, рәсемнәр ясыйлар, диаграммалар, интеллект карта да төзергә мөмкин.

| **Өстәлләр өчен темалар** | **Фикерләшү өчен сораулар** |
|---|---|
| 1. «Интернет – могҗизалар иле, бер сәгатькә керсәң… бер көнгә югаласың!» | Интернетның уңай якларын санагыз. Интернет нинди файдалы мөмкинлекләр ача? |
| 2. «Интернетның сәламәтлеккә һәм үсешкә зыяны» | Интернетка бәйлелек сәламәтлеккә ничек тәэсир итә? Интернет безгә ничек тәэсир итә? |
| 3. «Интернетта куркынычсызлык өчен киңәшләр» | Интернет челтәрен кулланучыларга нинди киңәшләр бирер идегез? Интернет кулланучыларны нинди куркынычлар көтәргә мөмкин? |
| 4. «Интернетта яшәмә, реаль тормышта яшә!» | Интернетны ничек һәм нәрсә белән алыштырыга була? (Уеннар, хобби, кызыксынулар һ.б.) |

Соңгы этапта барысы да үз өстәлләренә әйләнеп кайта. Проекның үз өлешен башкалар алдында яклый. Нәтиҗәдә зур бер проект «Интернет – дусмы, дошманмы?» темасына «кәгазь эскәтерләрдән вернисаж» барлыкка килә.

– Интернет ул мөмкинлекме, әллә куркынычмы? Беренчесе дә, икенчесе дә. Кешеләрне үз-үзләренә кул салу дәрәҗәсенә китергән сайтлар бар. Шул ук вакытта төрле яктан үсәргә дә мөмкин. Без Интернетта нишлибез? Укыйбыз, кызыклы, файдалы мәгълүматлар алабыз, аралашабыз... Әмма бервакытта да шуны онытмаска кирәк, монда да һәр тарафта куркыныч – төрле вируслар, чит мәгълүматларны урлау, финанс караклары сагалап тора. Бу очракта теләсә кем җиңел генә мишень булырга

мөмкин. Үзеңне Интернеттагы хәвеф-хәтәрләрдән саклау өчен ни эшләргә кирәклеге турында сезнең бик матур киңәшләрегезне тыңладык.

Бүген интернет тормышыбызга шулкадәр нык итеп килеп керде, хәтта аннан башка тормышны күз алдына китерү дә авыр. Үзебезне Интернет кулланганда дөрес тотып, укучыларны да шуңа өйрәтеп бу тормышта сәламәт булып яшик!

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Электрон ресурс. https://translated.turbopages.org/proxy_u/en-ru.ru.122f142a-6426be68-8b4929e5-4722d776562/

2. Википедия https/en.wikipedia.org/wiki/World_caf%C3%A9_(conversation)

## ҮЗ ТЕЛЕНДӘ САЙРЫЙ КОШЛАР ДА...

*(Татар теле язмышы турында кайбер уйлануларым…)*

*Гыйльметдинова Энҗе Рамазан кызы,*
*татар теле тәрбиячесе,*
*Казан шәһәре Авиатөзелеш районының*
*«26 нчы катнаш төрдәге балалар бакчасы» МББМУ*

Ярату, шатлану, моңлану... Әлеге хисләрне һәркем үз телендә аңлата. Һәр милләтнең үзенә генә хас көе, моңы, гореф-гадәте, теле бар. Шул телне саклап, яклап, кадерләп, киләсе буыннарга тапшырып яшәргә иде.

Ана телебез хакында куп сөйләшәбез. Соңгы арада татар теленә карата мөнәсәбәт тә үзгәрде. Янәсе, русча сөйләшмәсә, кеше югалып калачак. Шәһәрдә кыен булачак. Укырга керә алмаячак, дуслар тапмаячак. Болар – сәбәп кенә! Телне ярату, аңа мәхәббәт йөрәктә булырга тиеш! Үз телеңне бозу, башкалар теленә күчеп сөйләшүне мин хыянәткә тиңләр идем. Ватанга, нәселеңә, үзеңә.

Никадәр күп фикер булса да, мин телне саклауда зур рольне бары тик гаилә генә уйный дип саныйм. Ана сөте белән кергән, чыкмаска тиеш дип уйлыйм! Әмма монда бер сорау туа – ана сөтең нинди? Ул ниләр белән сугарылган. Ул сөттә тел тәме, җыр тәме, ярату тәме бармы соң? Менә без кайда ялгыштык. Карынында сабый йөрткән, шул сабыйны күкрәк сөте белән ашаткан хатын-кызлар күңеленә үтеп керәсе иде. Әллә инде

хәзер ана сөтен катнашма алыштырган кебек, телебезгә дә мәхәббәтне уята алымыйбызмы? Уйландыра бу хәлләр.

Ни генә булмасын, бала бар нәрсәгә гаиләдә өйрәнеп үсә. Беренче авазларын шунда әйтә. Тәпи китә, сөйләшә башлый. Заманага ияреп, шунда хата кылабыз. Тырышып әннә дигән баланы, «мама», «папа» дип кабатлаткан булабыз. Өйрәнмәс әле русчага! Кешедән ким булмасын, янәсе! Русча белсен. Шулай итеп, биш яшендәге авылда яшәүче бала, бер сүз татарча сөйләшмәскә мөмкин. Мондый мисаллар күп. Әниләреннән сорасаң, телевизор, интернет галәмәте диләр. Ә син бу вакытта кайда булдың соң? Әни бит син. Телгә мәхәббәтне әти дә түгел, әни уята. Аның бишек җырлары белән тибрәтеп йоклатуы ук күңелгә хис кертергә тиеш. Ватанпәрвәрлек бишектән үк тәрбияләнә башлый. Ә бу сүзгә күп нәрсә сыйган. Әти-әни, туган җир, туган як, Ватан. Алар янәшәсендә синең телең дә бар.

Без күбебез инде гореф-гадәтләрне дә җиргә салып таптап барабыз. Ирендерә. Чиләк-көянтә тотып суга бару бетте. Димәк, кыз балага су юлын күрсәтү булмаячак. Сөлге чигеп утырмыйлар. Кирәк булса, сатып алырбыз, диләр. Димәк, кыз бала кул эшләрен белми үсә. Шул бизәкләрдә безнең татарлыгыбыз ялтырап ята. Үзебезнең орнаментлар, бизәкләр аша да без балада туган телгә карата ярату тәрбияли алыр идек. Бишек! Анысы да юк бит инде хәзер. Шул җырларын тыңлап үскән булсаң...

Инде килеп әби-бабай тәрбиясенә күчик! Алар юк хәзер. Миңа үпкәли күрмәсеннәр. Әмма заман киленнәре һәм әбиләре башка хәзер. Берәүнең дә каенана белән яшисе килми. Каенаналар да хәзер иртә әби булырга ашыкмый. Шулай итеп, оныклар зыян күрә. Яшь әбиләр бу сабыйга берни бирә алмый. Киресенчә, оныкка ияреп вата-җимерә русча сөйләшеп йөри. Заман таләбе, янәсе. Әкиятләр сөйләү, гореф-гадәтләрне искә алулар да юк. Әти-әни тормыш көтә, акча эшли. Бала интернетта. Әби-бабайлар хәзер яулык ябып, кәләпүш киеп олыгаерга ашыкмый. Алар йә паркта ял итә, йә су коена, йә инде фитнеска йөри. Кешедән калышасылары килмичә, көне-төне интернетта утыралар. Сабый менә шул арада үз-үзен тәрбияләргә мәҗбүр. Бар да аның кулында. Нәрсәне кирәк дип таба, шуны ала да инде. Ә без яшьләрне сүккән булабыз. Юкка. Нидер таләп иткәнче, вакытын кызганмыйча тәрбия бирергә иде. Балага бары тик җиде яшенә кадәр генә нинди дер орлык салып була.

Милләтебезне саклар өчен, без иң элек телне югалтмаска тиеш. Яраклашмыйк әле заманага. Күңелдә татарлык яшәсен. Милләт өчен янып йөрүче егет-кызлар да җитәрлек. Әнә шулардан үрнәк алып, иярик үзләренә. Татар бакчаларына биреп тәрбияләтик, татар мәктәпләре укытсын. Әле берәүнең дә татарча укып югалганы юк. Уйлап карагыз әле. Безнең рәис тә, министрларның күбесе дә авыл егетләре. Заманында агачтан салынган, утын ягып җылытыла торган мәктәпләрдә белем алып та үзен югалтмаган кешеләр. Дөрес, үзеңне югалтмау кирәк. Алайса без хәзер БДИдан куркып, тизрәк рус теленә күчә башладык. Янәсе, татарча укыса, бирә алмаячак. Юк, бу дөрес түгел! Кукмара районының Ядегәр авылында саф татарча белем алган малай өч фәннән дә БДИны 100 баллга биргәне истә калган. БДИга да сылтарга кирәкми икән. Әгәр кешенең белеме булса, ул аны төрле телдә аңлатып бирә алачак.

Югалту һәм югалу тиз ул. Узган елгы җанисәп тә татарларның шактыйга кимүен күрсәтте. Без үлмәдек. Без битарафлыгыбыз аркасында саныбызны югалттык. Вакытында мин татар дип тавыш бирмәдек. Өйгә килгән кешеләрне кертмәдек. Ә бит шушы саннарда – милләт язмышы. Бу безнең милләткә кирәк. Аны сакларга, шуның белән телне югалтмас өчен кирәк. Без әлегә телнең кадерен белмибез. Моның өчен читкә китеп карау җитә. Андагы милләттәшләрнең тел өчен ничек өзгәләнүен күргәнегез бармы? Алар тырышып татарчасын да сөйләшә, гореф-гадәтләрне дә сакларга тырыша. Ә без. Без булганның кадерен белмибез.

Бер газетадан Балтач районының Смәел авылында туып үскән, Австралиядә яшәүче татар егетенә кияүгә чыккан Финзия Газизова белән әңгәмә укыган идем. Ул анда туган якны, миллилекне сагынуын сөйләгән. Читкә киткәч ул бар нәрсәнең кадерен аңлаган. Өйләрендә ике баласы белән бары тик татар телендә генә аралашуын, кичләрен бергәләп татар китаплар укуын җиткергән. Ә бит сабыйлары русча да, инглизчә дә белә икән. Тел кадерен белү өчен бөтен кешене дә читкә җибәреп булмый, әмма үзеңне туган яктан еракта, бер ятим итеп хис итеп алырга кирәктер. Бәлки, шуннан соң татар телебезгә яратуны югалтмас идек.

Телне саклар өчен театрга, концертларга йөрергә кирәк! Милли киемле кешеләрне күрү йөрәгегезгә сары май булып ятмыймы? Ятырга тиеш. Шул бизәкләр, камзул, калфак,

читекләрдә дә татар язмышы. Минемчә, бизәкләрдә сөйләшә кебек. Алар әле дә телне, миллилекне саклауны сорый кебек. Ә милли көй... Аны бер тыңлау да җитә. Ул бөтен күңелне айкый. Тәннәр чемерди. Татар бит мин горурланып куясың!

Җәйге көн һәм печән базары. Адашкан җаннарга миллилекне әле шуннан эзләп табарга була. Тел исә һәрчак синең белән. Ниндиендә сөйләшүне үзең хәл итәсең. Йөрәгеңдә әби-бабайларга карата бер тамчы ярату булса да, син үз телеңдә аралашырга тиеш. Кошлар кебек. Алар да сайрый үз телендә. Үрнәк алыйк!

## ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ АША СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАРНЫ БАРЛАУ

*Җәләева Әнисә Мөхәммәт кызы,*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Сафиуллина Гөлназ Нәҗип кызы,*
*югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*«Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган*
*В.Ф. Ежков исемендәге*
*Арча 1 нче урта гомуми белем мәктәбе» ГБББМУ*

Укучыларга югары сыйфатлы белем бирү – иң мөһим бурычларның берсе. Җәмгыятькә иҗади фикерли белүче, аралашучан, талантлы кешеләр сорала. Заман таләбе – баланың табигать тарафыннан бирелгән сәләтен үстереп, аны иҗади шәхес итеп тәрбияләү. Һәр бала үзенчә сәләтле була. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз. Бүгенге балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Менә шушы заманча технологияләр заманында татар теленә, татар мәдәниятына, татар әдәбиятына ничек кызыксыну уятырга?

Башлангыч сыйныфлардан ук татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынган балаларны күреп алырга кирәк. «Мәгариф» дәүләт проектында «Сәләтле балаларга ярдәм итү» мәсьәләләре аерым урын алып тора. Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итә торган технологияләр шактый.

Татар теле һәм әдәбиятын укытуда кулланылган инновацион технологияләр арасында проектлар методы әһәмиятле урын алып тора. Проект эшчәнлегенең нигезе – эзләнү-тикшеренү эше.

Проект эшчәнлеген башлангыч сыйныфларда ук башлау дөрес булыр, нәкъ укучы өчен кирәк булган иҗади сәләт, логик фикерләү башлангыч сыйныфта салына бит. Башлангыч класстан ук укучы үз фикерен курыкмыйча әйтергә, коллектив каршында каушамыйча чыгыш ясарга, коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә. Проект эшчәнлеге укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес оештырылуына бәйле.

Башлангыч сыйныфларда укытучы – киңәшче, юнәлеш бирүче, төзәтмәләр кертүче. Укучы-эзләнүче, мәгълүмат җыючы, фикерләүче, проектны яклаучы, нәтиҗә ясаучы. Башлангыч сыйныфларда проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, чөнки ата-ана бала тормышында актив катнаша. Алар кирәкле мәгълүматны табарга ярдәм итүче, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, бала белән көндәлек аралашучы ролен үти. Проект эшчәнлеге укытучы һәм укучыдан зур түземлек, сабырлык, күп вакыт сарыф итүне сорый. Тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән, интернет аша күп мәгълүмат тупларга, иҗади фикер йөртергә кирәк.

Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә. Шуннан чыгып, проектны әзерләү планы тәгъдим ителә.

1. Тәкъдим ителгән бер проектны сайла яки үз проектыңны уйла.
2. Хәл ит: үзең генә эшлисеңме, әллә партадашың беләнме?
3. Эш этапларын уйла, кемнең нәрсә өчен җавап бирәчәген хәл ит.
4. Нинди китаплар, материаллар кирәк булачагын, ярдәм сорап кемгә мөрәҗәгать итәчәгеңне билгелә.

Түбәндәге эшчәнлек этаплары белән таныштырыла.

1. Сораулар язылган карточканы сайлап ал.
2. Сорауларга җавап табарга ярдәм итәрлек китапларны тап.

3. Телдән чыгыш яса. Өйдә сөйләп кара. Үз чыгышыңа иллюстрация сайла.

Башкарылган эшләрдән чыгып, проект эшенең нәтиҗәсе ясала.

Проект эшенең нәтиҗәсе булып, башлангыч сыйныфларда җаваплары рәсем белән бирелгән табышмаклар күргәзмәсе, китапчык һәм альбомнар, төрле конкурслар булырга мөмкин.




4 нче сыйныф укучыларына иҗади проект эшләргә «Тукай иҗатында кош образлары» дигән тема бирелде. Башта бергәләшеп максатны билгеләдек, проектны әзерләү планын төзедек. Проектны эшләү өчен сыйныф укучылары төркемнәргә бүленделәр. Укучыларга түбәндәге сораулар бирелде: Габдулла Тукайның нинди шигырьләрен беләсез? Кайсы шигырь сезгә күбрәк ошады? Шигырьләрдә нинди кошлар белән таныштыгыз? Бу шигырьгә карата үзегезнең мөнәсәбәтегезне белдерегез. Ярдәм сорап кемгә мөрәҗәгать итәсегезне билгеләгез. Һәр төркемгә үзләре теләгән, үзләренә ошаган темага мөстәкыйль эшләргә мөмкинлек бирелде.

Беренче тема: «Г. Тукай әсәрләрендә кош образы». Балалар шигырьләр укып, аларга анализ ясыйлар һәм үзләренең эш нәтиҗәләрен реклама рәвешендә тәкъдим итәләр. Алар төрле формада: стенгазета, презентация, буктрейлер булырга мөмкин.

Икенче тема буенча Габдулла Тукай әсәрләрендә еш кулланылган кошлар турында Лэтбук эшләү. Бу бирем рус мәктәбендә укучы балаларның кошлар исемен белмәүләрен дә исәпкә алып тәкъдим ителде. Китапчыкларда балалар кошлар турында мәгълүмат тупларга, аларның рәсемнәрен урнаштырырга, рус теленә тәрҗемә итәргә һәм бүгенге көндә табигатьтә тоткан урынын билгеләргә тиешләр. Әлеге эш нәтиҗәсендә әйләнәтирәне яратучы, кызыксынучы шәхес тәрбияләнә. Мисал өчен, Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырендә бирелгән сандугач образын китерәсебез килә.

Сандугачлар яки былбыл кош-чыпчыксыманнар тәртибенә керә торган кошлар. Иң билгеле төре – гади сандугач; тән

озынлыгы 17 см, кара күзле, соры каурыйлы, кызыл койрыклы. Сандугач караңгы кызгылт (каштан) төсендә,түше һәм муены ак төстә, ә койрыгы караңгы кызыл. Чуар каурыйлары юк, бик гади. Сандугач гәүдәгә бик гади күренсә дә, аның тавышы гаҗәеп матур. Көндезләрен сандугач сайрамый. Сентябрь башларында сандугачлар җылы Африка якларына кыш чыгарга китәләр. Алар урманнарда өлгергән җиләк-җимешләрне ашыйлар.

Өченче тема: «Г. Тукай иҗатында очраган кош исемнәре кергән татар халык мәкальләре» туплау, Әлеге тема буенча буклетлар эшләнә. Эш барышында төрле алымнар кулланырга мөмкин: рәсемнәр ясау, кисеп ябыштыру, оригами һәм башкалар.

Габдулла Тукай шигырьләрен укыгач, балалар кешенең табигать белән ныклы бәйләнешен ачык итеп тоялар. Кешенең эчке кичерешләрен сурәтләгәндә кош образларын кулланырга мөмкин икәнлеген дә аңлыйлар. Шул рәвешле, кайгыртучанлык, шәфкатьлелек, киң күңеллелек кебек сыйфатларны оста һәм тәэсирле итеп биреп була дигән нәтиҗәгә киләләр.

Проектлар методы белән эшләү татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә предметара бәйләнешләрне тормышка ашырып, балаларның белемнәрен интеграцияли, танып белү эшчәнлеген арттыра, иҗади һәм тикшеренү күнекмәләрен үстерә. Гомумән, проект методы – баланың иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә нәтиҗәле алымнарның берсе булып тора дип уйлыйбыз.

Проект өстендә эшләгәндә, укучы ирексездән күп кенә әсәрләр, китаплар белән таныша. Үзе сайлаган тема буенча бай мәгълумат туплый, нәтиҗәләр ясый. Автор буларак чыгыш ясый, чыгышын нигезләп, дәлилләп бирә.

Йомгаклап шуны әйтәсебез килә, мәгълүмати технологияләр заманында яшәсәк тә, укучылар китап укымый дисәк тә, эшебезне тиешле юнәлештә алып барабыз икән, гаҗәеп дуслык – китап һәм укучы дуслыгын күзәтә алабыз.

# МИЛЛӘТЕМ ГОРУРЛЫГЫ – ГӘБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ

*(Технологик карта)*

*Зиннәтова Лилия Илфәр кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Әгерҗе шәһәренең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе Таҗи Гыйззәт исемендәге*
*3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе*

9 сыйныфның татар төркеме өчен әдәбият дәресенең технологик картасы. Дәрес методик яктан караганда, технологик карта стандартында фәнни нигездә төзелгән. Күренекле татар әдибе Габдерәхим Утыз Имәнинең күпкырлы эшчәнлеге, тормыш юлы белән таныштыру төрле биремнәр аша башкарыла.

| | |
|---|---|
| **Тема** | «Милләтем горурлыгы – Гәбдерәхим Утыз Имәни» |
| **Сыйныф** | 9 сыйныф (татар төркеме) |
| **Предмет** | Татар әдәбияты |
| **Дәреснең тибы** | Яңа материалны өйрәтү |
| **Максат** | 1. Күренекле татар әдибе Габдерәхим Утыз Имәнинең күпкырлы эшчәнлеге, тормыш юлы һәм хезмәтләре белән таныштыру;<br>2. Укучыларның фикерләү сәләтләрен камилләштерү;<br>3. Әдип иҗатына карата кызыксыну уяту; татар халкының бөек затларына ихтирам, милли үзаң, милли горурлык тәрбияләү. |
| **Бурыч** | Укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү;<br>Укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру. |

| | |
|---|---|
| **УУЭ** | Шәхескә кагылышлы УУГ:<br>– укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру.<br>– *Регулятив УУГ:*<br>– хәл ителгән һәм хәл ителергә тиешлене чагыштырып, уку бурычларын кую;<br>– максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану;<br>– бәяләү.<br>– *Танып белү УУГ:*<br>– тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;<br>– төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау.<br>– *Коммуникатив УУГ:*<br>– башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау;<br>– үз фикерләреңә ышандыра белү. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге |
|---|---|
| 1 этап. Оештыру өлеше, мотивация тудыру. | Исәнмесез, хәерле иртәләр, укучылар! «Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр», – диләр. Бер-беребез белән аралашу безгә шатлыклар гына китерсен, һәр туар таң сезгә белем өстәсен, мәгърифәтле булыйк! Дәрестә игътибарлы булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз. |
| 2 этап. Мотивация (эшкә кызыксыну) тудыру. | 1. Фронталь эш. Сөйләшү.<br>Укучылар, бүгенге көн безнең укуга кызыксынучан, тырыш булуыбызны таләп итә. Алдынгы карашлы шәхес булыр өчен нинди булырга тиешбез соң?<br>Әйе, дөрес әйтәсез, заман бездән нык белемле, мәгърифәтле, гыйлемле булуыбызны сорый, бары тик белемгә бай кызлар һәм егетләр генә үз иленең, үз милләтенең горур халкы булып яши ала.Тарихыбыз битләрендә һәр чорның күренекле әдипләре халкыбыз горурлыгы булып яшәде һәм яшиләр. Алар үзләренең тирән белемгә ия булулары белән аерылып торалар.<br>Шушы бөек шәхесләребезне, энциклопедик галимнәребезне искә төшереп үтик.<br>2. Видео карау. Видеода бөек шәхесләребез портретлары чыгып бара.<br>Без бүген өйрәнәчәк шәхесебез дә безнең тарихыбызда тирән эз калдырган кеше. Кем турында бүген сөйләшербез. |
| | 3. Шигырь уку.<br>Сабыр ит син, бәла килсә башыңа,<br>Шөкер ит тәңре биргән язмышыңа.<br>Күтәр син өстеңә килгән бәлане,<br>Чыда, беркемгә дә фаш итмә аны.<br>Сабыр иткән кеше табар камиллек,<br>Моны яздым итеп сезгә васыять,<br>Дәва булсын, укыгыз берничә кат.<br>Әгәр кушсаң «Рәхим»гә «Габде» сүзен,<br>Язучының белерсең исемен үзең. |

| Укучы эшчәнлеге | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|
| Укучылар көндәлдән генә бер-берсенә изге теләкләр телиләр. Бер-берсенә карап елмаялар. | Коммуникатив: Иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү гамәле. |
| Укучылар алдынгы карашлы кешегә хас, кирәкле булган сыйфатларны санайлар (тырыш, тәртипле, белемле, укымышлы, кызыксынучан, сабыр, максатчан, үткен, тапкыр). Дәреснең эпграфын укыйлар.<br>Укучылар видеобүләкне карыйлар. | Коммуникатив:<br>– бүтәннәрне сөйләвен тыңлау һәм аңлау;<br>– үз фикерләренә ышандыра белү. |
| Укучылар шигырьгә җавапны әйтәләр: Габдерәхим. | |

| | |
|---|---|
| | – Без бүген танышып үтәчәк шагыйрьнең исемен кем әйтә ала, укучылар?<br>4. Ребус чишү. Ребус чишеп, псевдонимын белербез.<br>Әйе, укучылар, бүгенге әдәбият дәресебезнең темасы: «Милләтем горурлыгы – Гәбдерәхим Утыз Имәни». |
| 3 этап. Уку мәсьәләсе кую.<br>Максат: дәрескә максат кую (белгәннәр нигезендә ачыклап бу дәрестә үзләштерелергә тиешле уку мәсьәләсе кую). | – Укучылар, безгә Габдерәхим Утыз Имәнине өйрәнер өчен, нәрсәләр белән танышырга кирәк була?<br>Әйе, укучылар, бүгенге әдәбият дәресебезне XVIII йөз әдәбиятының күренекле шагыйре Габдерәхим Утыз-Имәни тормыш юлына, иҗатына багышларбыз.<br>Габдерәхим Утыз Имәни дә үз чорының энциклопедик белемле кешесе булган. Ни өчен энциклопедик? Менә шул сорауга да җавап эзләрбез.<br>Дәресебезнең эпиграфына игътибар итик.<br>«Дөньяда мәңге яшисең килсә, укы, тырыш, белем ал, белем ул үзе тереклек суы. Галим кеше бай да, әхлаклы да, ай һәм йолдызлар кебек якты да; шул сыйфатларга ия булу өчен гыйлемеңне артыр».<br>Нинди булырга чакырган? Белемле булу темасы иҗатында беренче урында тора. |
| 4 этап.<br>Уку мәсьәләсен чишү. | 1 нче бирем: Дәреслек белән эш. 18 нче биттән уку.<br>2 нче бирем. Биографиясе буенча карточкаларда парлап анкета тутыру. Дәреслектәге текст белән эш.<br>Слайдттан карап тикшерү. Уку. Билге кую.<br>3 нче бирем: Слайдка игътибар итү. Болар кемнәр? Нигә алар бергә? (В. Ломоносов һәм Г. Утыз Имәни). |

| | |
|---|---|
| Псевдонимын да ребусны чишеп беләләр: Утыз Имәни<br>  <br>Габдерәхим Утыз Имәни | |
| Тормыш юлы, иҗат юлы белән танышырбыз. Әсәрләрендә күтәрелгән төп темаларны ачыкларбыз. Ни өчен милләтебез горурлыгы дигән сорауга җавап эзләрбез.<br><br>Укучы укый. Темасын ачыклыйлар: Белем темасы. Гыйлем зур хәзинә, тереклек суы, булып тора. | Метапредмет УУГ регулятив:<br>– дәреснең максатын билгеләү, аңа формулировка ясау;<br>– укытучы ярдәмендә дәрестә үз эшчәнлегеңне планлаштыру. |
| Укучылар чылбырлап әсәрне укып чыгалар.<br>Парларда эш.<br>Укучылар укыган тексттан мәгълүмат эзлиләр. Анкетага язалар. | Шәхси УУГ:<br>– укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру.<br>– парларда эшли белү. |

Утыз Имәни энциклопедик мирасы, күпкырлы эш-гамәлләре белән рус әдипләреннән В.М. Ломоносов эшчәнлеген хәтерләтә.

Ломоносов кем булган? Слайд белән эш итү.

Утыз Имәни кем булган? Кайсы өлкәләрдә эшләгән? Сүзлек белән эш итү һәм эшчәнлегенә аңлатма биреп бару.

Мәрсияче буларак аңлатма: Әнисе якты дөньядан китсә дә, әсәрдә Габденнасыйр аны олылап искә ала, күркәм холкын мактый.

Текстолог буларак аңлатма: ул, борынгы Болгар чоры (13 гасыр башы) әдәбияты саналган, мәгълүм «Йосыф вә Зөләйха» поэмасының берничә төрле кулъязмасыннан файдаланып, җыелма бер нөсхәсен төзеп калдырган.

Мәгърифәтче шагыйрь кешеләрдәге әхлаксызлык сыйфатларының сәбәпләрен эзли һәм аларны наданлыктан күрә. Шуңа күрә ул замандашларын гыйлемгә, мәгърифәткә өнди. Бәхетне гыйлемдә күрү – менә төп идеясенең асылы.

Беренче читатта, шагыйрь.

Сүзлек өстендә эш. Тактада яңа терминнар: Текстолог, теолог, мәгърифәтче, мәрсиче, энциклопедик галим Аларга аңлатма бирелә.

4 нчы бирем Әсәрләренең төп тематикасын ачыклау.

– Милләтебез горурлыгы – Утыз Имәнинең тарихта эз калдырган әдәби ядкарьләрендәге кайбер юлларны ятлап, муенга бөти итеп тагып йөртерлек.

Утыз-Имәнинең иҗат мирасы гаять зур һәм күпкырлы. 60 еллык иҗат дәверендә ул 202 исемдә хезмәт язып калдырган. Ләкин таланты поэзия жанрында ныграк ачылды. Шулар арасында түбәндәгеләр аеруча игътибарга лаек. (Исемлек күрсәтелә).

| | |
|---|---|
| Парлар карточкаларны алышалар, слайдтан карап тикшерәләр, укыйлар, билге куялар.<br>Көтелгән җаваплар:<br>– В. Ломоносов һәм Г. Утыз Имәни.<br>– Энциклопедик галимнәр.<br>Текстолог, теолог, мәгърифәтче, мәрсиче, энциклопедик галим сүзләренә аңлатманы тактадагы карточкалардан укыйлар.<br>Энциклопедик галим – белемнең бик күп өлкәләреннән хәбәрдар булган, күпкыры белемнәргә ия булган галим.<br>Текстолог – борынгы кульязмаларны, текстларны җыйган, өйрәнгән, җыелма бер нөсхәсен төзеп калдырган белгеч.<br>Теолог – дин тарихын, фәлсәфәсен өйрәнүче белгеч.<br>Мәрсияче – вафат булган кешеләрне, күренекле затларны мактап,олылап искә алу шигырьләрен иҗат итүче шагыйрь.<br>Мәгърифәтче – аң-белем таратучы; галим, гыйлем иясе.<br>Төркемнәрдә эш. Фикер алышалар.<br>Төп темалары: белемле, гыйлемле булу, сабыр булу.<br>Исемлек укыла.<br>«Замана укымышлылары»<br>Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр» | Регулятив УУГ:<br>– уку бурычларын кую;<br>– максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану.<br>Танып белү УУГ:<br>– тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;<br>– төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау.<br><br>Коммуникатив УУГ:<br>– башкаларның сөйләмен ишетеп һәм тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү;<br>– үз фикерләреңә ышандыра белү. |

| | |
|---|---|
| | Әсәрләренең исемнәре буенча нинди темаларга язган дип уйлыйсыз? Эпиграфка игътибар итәләр.<br>18 гасыр шагыйре Г. Утыз Имәни дә кешегә чын бәхетне гыйлемлелек кенә бирә, ди. Аның асыл сүзләре 21 гасыр укучысы өчен дә актуальлелеген югалтмый.<br>5 нче бирем. Утыз Имәнинең һәрбер шигъри юлын канатлы сүз итеп алып була. Үзегезгә девиз итеп алсагыз, сез максатыгызга ирешерсез.<br>Сезнең алда карточкалар.<br>Аларда Утыз-Имәни шигырьләреннән өзекләр һәм мәкальләр? Бу өзекләр нинди мәкальләргә аваздаш?<br>6 нчы бирем. Иҗади бирем. Кайсы мәкаль ошады? Ни өчен?<br>№1. «Кем гыйлемле, бел асылташ дип аны,<br>Һич җиңалмас угры яки дошманы.»<br>(Беләге юан берне җиңәр,<br>Белеме юан меңне җиңәр).<br>№2. «...Гыйлемлелек – яшерен хәзинә, кем таба,<br>Ике дөнья байлыгы булыр аңа...»<br>(Белем – иң яхшы байлык: янмый да, югалмый да.)<br>№3. «...Сиңа атса берәр адәм әгәр таш,<br>Ачу тотма, үзең ат син аңа аш...»<br>(Таш белән атканга, аш белән ат). |
| 5 этап. Рефлексия. | «Түгәрәк вакыты» уены.<br>Фикерләребезне гомумиләштерик: Дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек? Ниләр белдек?<br>– Бүген дәрестә ни эшләргә теләгән идек? |
| 6 этап.<br>Өй эше бирү | Өй эшен сайлау мөмкинлеге бар.<br>1. Белем турында 10 мәкаль язып килегез.<br>2. Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты буенча синквейн языгыз (үрнәге бирелә)<br>3. Утыз Имәни иҗаты буенча кроссворд төзегез. |

| | |
|---|---|
| «Фикерләрне пакъландыра торган игелекле үгетләр»<br>«Гыйлем һәм акылның өстенлеге турындагы бүлек»<br>«Заманның мөһим билгеләре»<br>Утыз-Имәни шигырьләреннән өзекләр һәм мәкальләрне тоташтыралар. Өзекләр мәкальләргә аваздаш. | |
| Укучылар түгәрәккә басалар. Утыз Имәни турында өйрәнгәннәрен, истә калганнарын чиратлашып әйтәләр.<br>Нәрсә ошады? | Коммуникатив:<br>– үз фикерләреңне тулы, төгәл, ачык һәм аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау |
| | Регулятив:<br>өй эшен сайлаганда дөрес карар кабул итү белү. |

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Гыймадиева Н.С., Билалова, Ә.Г. Әдәбият дәреслекләре буйлап. – Казан: «Яңалиф» нәшрияты, 2006.

2. Фәрдиева Х.Г., Хәбибуллина З.Н., Хисмәтова Л.К. Татар әдәбияты. 9 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) – Казан : Татарстан китап нәшрияты, 2017.

## БЕЛЕМНЕ ЦИФРЛАШТЫРУ КИРӘКМЕ?

*Имайкина Рушания Фәнис кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем мәктәбе*

*Әлеге хезмәт белем бирүне цифрлаштыруның тискәре һәм уңай якларына чагыштырмача анализ бирә. Бүгенге көндә актуаль булган бу тема белем бирү системасында эшләүче һөнәр ияләренә файдалы.*

Татарстанда 2022 ел – Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Бу инде үз чиратында күп сораулар тудырды: электронлаштыру өлкәсендә мәктәпләрне нинди яңалыклар көтә? Кара такталарга, акбурга урын калырмы? Укучылар электрон дәреслек кыстырып йөри башламасмы? Өй эшен тикшерүне кайчан компьютерга тапшырачаклар? Гомумән, цифрлаштыру тора-бара өйдә укуга китермәсме?

Белем бирүне санлаштыруга омтылу пандемиядән соң бигрәк тә сизелә башлады. Мәҗбүри дистант яңа технологияләрне үстерү кирәклеген күрсәтте. Ләкин санлаштыру белемне кысрыклауга китермәячәк. Мәктәптән баш тартып булмый. Укытучы белән укучылар арасындагы элемтәләрне берни дә алыштыра алмый. Дистант формасы кертелгәч, балалар укытучылары янына кайтуны зур түземсезлек белән көтте.

Цифрлаштыру – тормышның аерылгысыз өлеше, шуңа күрә аны күрмәмешкә салышып та булмый, заманга ияргә туры килә. Әлбәттә, һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш. Әгәр теләсә кайсы даруны күбрәк кулланса, ул агуга әйләнергә мөмкин. Санлаштыру белән дә шул ук хәл. Безгә гаҗәеп мөмкинлекләр биргән цифрлаштыруны файдалы итеп куллана белергә кирәк, Заманча технологияләрне бөтенләй файдаланмау урынсыз булыр иде. Дәресләрдә презентацияләр, видеороликлар күрсәтү, аудиокушымталар куллану – бу инде яңалык түгел.

Укучылар белән бергә  шагыйрьләрнең тавышын тыңлыйбыз, язучыларга кагылышлы видеоязмалары карый алабыз, теләсә кайсы интерактив музейда була алабыз һәм тагын без, татар теле укытучылары кулланып та карамаган бик күп җайланмалар бар. Ләкин моның өчен әле мәктәпләрдә җиһазлар һәм шартлар җитеп бетми. Хәтта гади генә булган электрон журналга керер өчен генә дә күпме проблемалар тууы беребезгә дә сер түгел. Кайбер мәктәпләрдә интерактив такталар да җитеп бетми. Дәресләрне заманча ысулларга нигезләнеп алып бару, әлбәттә, укучыларда кызыксыну уята. Интернетта да укуга бәйле платформалар бик күп, алар 30 га якын. Дөрес итеп куллана белергә генә кирәк.

Әлбәттә, укучыларны яңа технологияләрсез дә кызыксындырып була. Дәресне уен рәвешендә оештырып, теләсә кайсы укучыны җәлеп итәргә мөмкин. Укучыларга күңеллерәк тә булып китә әле. Алар да онлайн ресурслардан туеп киткәннәр, бер-берләренең күзенә карап аралашасы, дәрес материалларын тотып карыйсылары килә. Балалар акбур  тотып тактага язарга яраталар

Мультимедия чаралары кулланылмаган дәресләр сирәктер хәзер. Әзерләнү өчен шактый вакытны алса да, дәрестә үзен бик яхшы аклый: укучы укытучыны тыңлау белән бергә, күрү сәләтен дә эшкә җигә, әгәр шул биремнәрне үзе үтәсә, нәтиҗә тагын да арта. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнәләр, материаллар, рәсемнәр, схемалар, диаграммалар табалар, үзләре ясыйлар. Яңа мәгълүмати технологияләр проект эшчәнлеген киң җәелдерергә дә мөмкинлек бирә. Дәресләрдә эшләнергә мөмкин булган кечкенә проектлар да, презентация ясау белән төгәлләнүче зурлары да компьютер технологиясен куллануны күздә тота. Цифрлы мәктәп – безнең киләчәгебез. Цифрлы белем бирү ресурсларының максатларын билгеләп китик:

– мотивация булдыру;
– белемне күтәрү;
– карантин вакытларында мәктәпкә килмичә генә белем алу мөмкинлеге;
– вакытны экономияләү;
– эффектлылык;
– универсаль күнекмәләрне формалаштыру.

Цифрлы технологияләр биргән мөмкинлекләр:

– автоматик тикшерү;

– мультимедиялык;
– интерактивлык;
– төркемнең проект өстендә күмәк эшләве;
– хаталар статистикасы;
– төрлелек.

Татар теле дәресләрендә мондый цифрлы технологияләр һәм белем бирү ресурслары кулланырга мөмкин:

1. Сүзләр болыты төзү сервисы. Бу сервис «вордклуд.про» дип атала, сүзләрдән интерактив болытлар төзүне күздә тота.
2. Тагын «Тагул.ком» дигән сервис та шушы ук максатларда эшли.
3. «Ребус 1» – генераторлар ребусы дигән сервис ребуслар төзергә мөмкинлек бирә.
4. «Кроссвордлар фабрикасы» сервисында кроссводлар төзи алабыз.
5. «Кахут» викториналар, тестлар һәм башкаларны тиз төзергә ярдәм итә.

Тагын белем күтәрү институты тәкъдим иткән төрле ресурслар бар: Практическая фонетика татарского языка, Татарский язык, Шигърият.ру, Таткнигафонд.ру, Татарский сайт, Интернет образования на татарском языке, Габдулла Тукай, Электронная газета РТ, Адиплар.Народ.ру, Татарская электронная библиотека һәм башка бик күп цифрлы белем бирү ресурслары татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм йөзеннән булдырылган.

Ләкин төрле сайтлар, сервислар, платформалар булдырылса да, безгә – татар теле укытучыларына барыбер үзебезгә эзләнергә туры килә. Башка предмет укытучыларыннан аермалы буларак, безгә бер әйбер дә әзер килеш бирелми, күп әйбер әле азакка кадәр эшләнелмәгән. Киләчәктә, бәлки, безгә дә эшләргә шартлар булыр, дип ышанасы килә. Бүгенге көндә безнең алдыбызда зур максат – телебезне саклап калу бурычы тора. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуны, заманнан артта калмауны таләп итә.

# КОНСПЕКТ ВНЕКЛАССНОГО МЕРОПРИЯТИЯ: БОТАНИЧЕСКАЯ ВИКТОРИНА «ЛЮБЛЮ ТЕБЯ, МОЙ КРАЙ РОДНОЙ»

*Ихсанова Айгуль Ильдаровна,*
*учитель начальных классов,*
*МБОУ «Высокогорская средняя общеобразовательная школа № 1 Высокогорского муниципального района Республики Татарстан»*

Викторина проводится в форме КВН, для чего выбирается жюри пять-семь человек. Заседание КВН начинается с приветствия команд и разминки.

Вопросы для разминки:

1. Где раки зимуют?
2. У кого ухо на ноге?
3. Может ли пингвин назвать себя птицей?
4. Из какой рыбы была сварена Демьянова уха?
5. Назовите самую высокую траву?

**Первый конкурс**. Знаете ли вы кустарники и деревья?

Ведущий дает командам 1-2 букета из веток лесных деревьев и кустарников. Засекается время, в течении которого члены команд должны определить их виды.

**Второй конкурс «Эстафета».** В конкурсе участвуют по одному человеку от каждой команды. Шагая рядом с ведущим, один из них эстафеты называет другой, указав, когда оно рекомендуется к применению. Затем эстафета передается участнику и т.д. Можно организовать конкурс на перечисления других растений, например, медоносов. Выигрывает тот участник, который назовет больше растений, не сбиваясь.

**Третий конкурс «Музыкальная Разминка».** Каждая команда должна исполнить песню о природе, животных, растениях. Можно этот конкурс расширить до соревнования: в то время одна команда исполняет песню, другая – обдумывает свою, которая она подхватит первую. Побеждает команда, которая сумеет вспомнить и исполнить большее количество подходящих случаю песен.

**Четвертый конкурс «Веселые Художники».** Участвует по одному человеку от команды. С завязанными глазами они должны нарисовать названное им животное.

**Пятый конкурс «Кто быстрее».** Команды обмениваются кроссвордами на ботаническую тему, заранее составленными дома. Отводится определенное время, за которое команды должны решить эти кроссворды. Можно оценивать долями очков каждый правильный ответ.

**Список источников:**

1. Здоровье сберегающие технологии в общеобразовательной школе: методические рекомендации/ под ред. М.М. Безруких, В.Д. Сонькина. – М., 2002.

2. Бережков, В.Ф. Формирование здоровья школьников: научные основы. – М., 2001.

## ОЗНАКОМЛЕНИЕ С РОДНЫМ ГОРОДОМ, КАК СРЕДСТВО НРАВСТВЕННО-ПАТРИОТИЧЕСКОГО ВОСПИТАНИЯ

*Каюмова Гульсина Ильхамовна,*
*воспитатель,*
*МБОУ «Детский сад общеразвивающего вида № 9 «Рябинушка» г. Кукмор»*

Мудрость гласит: «Человек, не знающий своего прошлого, не знает ничего». Потому что без знания своих, традиций, культуры своего народа нельзя воспитать человека, любящего своих родителей, свой дом, свою страну, с уважением относящегося к другим народам. Не случайно и академик Д.С. Лихачев говорил: «Воспитание любви к родному краю, к родной культуре, к родному городу, к родной речи – задача первостепенной важности, и нет необходимости – это доказывать».

Воспитание любви дошкольников к малой Родине – это первый этап в воспитании патриотизма. Для наших детей это город Кукмор Знакомство дошкольников с родным городом оказалось не такой простой задачей, потому что маленькому ребенку трудно представить устройство большого города, историю его возникновения, достопримечательности.

Воспитывая у детей любовь к своему городу, мы старались подвести их к пониманию, что их город – частица Родины.

Данная работа была разбита на следующие блоки:

1. История возникновения города Кукмор.

2. Природа родного края, его природные богатства.

3. Промышленные объекты города, основные профессии людей на этих предприятиях.

4. Символика и достопримечательности Кукмора.

5. Знаменитые люди, прославившие наш город.

6. Культурное наследие родного города.

Каждый блок включает в себя как специально организованную образовательную деятельность, так и другие виды деятельности: беседы, чтение художественной литературы, дидактические игры и т.д. В годовом планировании темы всех блоков чередуются. Степень раскрытия темы и уровень ее рассмотрения с детьми определялись возрастом детей, конкретными особенностями их развития, возможностями взрослых, оснащённостью процесса.

В ходе работы дети испытывали огромный интерес к данной теме, с удовольствием слушали познавательные рассказы о прошлом и настоящем нашего города. Для реализации этой увлеченности был создан мини-уголок «Наш Кукмор». В нем собран материал о родном городе, включающий как сведения об историческом прошлом, так и о его современном культурном облике: иллюстрации, фотоматериалы, тематические папки на темы: «История возникновения города», «Промышленность города», «Образование и культура», «Знаменитые земляки», «В годы Великой Отечественной войны», «Достопримечательности», «Спорт», символика города (флаг, герб).

Проводила выездные и пешие экскурсии по городу. Дошкольники узнали о том, как жил и развивался наш город в прошлом с момента его рождения, о важных событиях, которые проходили в городе. Экскурсия в парк помогла увидеть красоту родного города. Беседа о правилах поведения в парке способствовала решению задач о бережном отношении к родному городу, природе, зарождению желанию сохранять, бережно относиться к созданию подобной красоте, ведь чем красивей город, тем больше мы его любим. Познакомила дошкольников с названием улиц, которые названы в честь героев и известных людей. Вызывала у ребят желание поддерживать чистоту на улицах города, чтобы он был всегда чистым и красивым. Дала детям понять, что они хоть и маленькие, но являются жителями Кукмора, это формирует у детей представление о родном городе, его устройстве,

достопримечательностях. Беседы на тему «Дом в котором я живу», «Любимый мой двор», «Улицы города» по своему содержанию помогали воспитывать у дошкольников активную гражданскую позицию. При ознакомлении с историей малой родиной была организована поисковая деятельность. Детям было предложено расспросить своих родителей, дедушек, бабушек об истории названия микрорайона, улицы на которой они живут на занятиях и в свободное от занятий время дети обменивались полученной информацией, предлагали свои версии об истории названии некоторых улиц. Проводились экскурсии в магазин, школу, библиотеку, пекарню т.д. Это помогает детям познакомиться с функциями и устройством различных учреждений, формирует у дошкольников представления о разнообразных потребностях людей, о том, как и кто, заботится о жителях города. В ходе образовательной деятельности дети познакомились с символикой города. С помощью наводящих вопросов дошкольники смогли разобраться в значении символов, изображенных на гербе Кукмора. Проведенные с детьми игры «Найди герб нашего города среди других», «Сложи герб по памяти» помогли закрепить знания дошкольников по данному разделу. На одном из занятий по формированию целостной картины мира детям была показана презентация «Любимый край», которая познакомила их с достопримечательностями города Кукмор, такими как: Дом культуры, спорткомплекс, различные памятники, Краеведческий музей, парк, парк «Победы», фонтан, здание администрации, музей, церковь, мечеть, река Нурминка. В презентации поселок был показан во все времена года, где дети лучше всего могли наблюдать признаки того или иного сезона.

Большая часть работы проходила вне занятий – это беседы, сюжетно-ролевые игры, чтение художественной литературы, рассматривание иллюстраций и репродукций с видами родного города. Закрепление знаний проходило на занятиях по изобразительной деятельности, конструированию, аппликации.

А совместно организованная с родителями фотовыставка «Папа, мама на работе» помогла закрепить содержание труда взрослых в родном городе: учитель, врач, швея, пекарь, строитель, милиционер, водитель. Дошкольники увидели важность и значимость труда их родителей.

Вся работа по патриотическому воспитанию проходила в тесном контакте с семьей. Родители были активными участниками всех праздников, помогали в оформлении фотовыставок о родном городе, о родном крае, участвовали в конкурсах рисунков, поделок. Организация совместных творческих домашних заданий – создание фотоальбома «Мой город, и я», выращивание комнатных цветов для группы объединило родителей и детей, обогатило общение между ними и доставило радость.

Проведенная для родителей консультация на тему: «Семейный маршрут выходного дня», родительское собрание в форме устного журнала на тему «Учим детей любить и беречь свой город» помогли родителям стать для своих детей примером отношения к своему городу, к месту, где живёшь.

Анализ проделанной работы по ознакомлению детей старшего дошкольного возраста с историей, культурой и природой родного края позволил убедиться в доступности для понимания детьми этой темы. Использование материалов об истории города, его людях и достопримечательностях в педагогическом процессе позволяет воспитать чувство гордости и уважения за свою страну и город. В ходе работы установлено, что эффективнее ознакомление с родным краем будет происходить при налаженной системе «воспитатель-ребёнок-родители».

**Список источников:**

1. Алешина Н.В. Патриотическое воспитание дошкольников. М.: ЦГЛ, 2005. 247 с.

2. Алешина Н.В. Знакомим дошкольников с родным городом. М.: ТЦ Сфера, 1999. 112 с.

3. Зеленова Н.Г. Мы живем в России. Гражданско-патриотическое воспитание дошкольников (Старшая группа) [Текст]: Пособие для воспитателей ДОУ / Н.Г. Зеленова.

5. Комратова Н.Г., Грибова, Л.Ф., Патриотическое воспитание детей 4-6 лет: Методическое пособие, М., 2007. – 224 с.

6. Комратова Н.Г., Грибова, Л.Ф. Патриотическое воспитание детей 4-6 лет. М.: ТЦ Сфера, 2007. 224 с.

7. Маханева М.Д. Нравственно-патриотическое воспитание дошкольников: Методические рекомендации [Электронный ресурс]. – Режим доступа:http://www.portal-slovo.ru.

## «КУРЧАК ЯСАУ»

*(Зурлар төркемендә тәрбияләнүче балалар өчен шөгыль)*

*Кәримова Чулпан Вәкил кызы, өлкән тәрбияче,*
*Җиһаншина Эльмира Ирек кызы, татар теле тәрбиячесе,*
*Казан шәһәре Киров районының*
*«252 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» МАМББУ*

**Максат.** Курчак белән таныштыру. Тасвирлап сөйләү күнекмәләрен ныгыту. Ашамлыклар турында сыйфатлау сүзләрен урынлы кулланып, әңгәмәдә катнашасы килү теләген үстерү.

**Шөгыль барышы**

**Тәрбияче:** Здравствуйте, ребята! Хәерле иртә, дуслар!

**Балалар:** Хәерле иртә, Надежда Витальевна!

**Тәрбияче:** Ребята, я вам что-то хочу показать! Хотите, посмотреть?

**Балалар:** Әйе, да.

**Тәрбияче:** Показывает куклу. Это моя самая любимая кукла. Мин – Гөлчәчәк.

Она моя лучшая подружка. Я все свои секреты, планы, обиды рассказывала. После этого мне всегда становилась легче. А вы хотите иметь такую любимую подружку куклу?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:** Мы сегодня сделаем своими руками эти куклы.

**Тәрбияче:** Что вы видите на столе?

**Балалар:** Салфетки, палочки, клей, нитки разные, фломастеры, ножницы.

(Ясыйлар).

**Тәрбияче:** Вот какие красивые куклы у нас получились. Вам нравится ваши куклы?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:** Балалар, а как у нас по-татарски будет кукла?

**Балалар:** Курчак.

**Тәрбияче:** Ралина, курчак нинди? (матур)

**Тәрбияче:** Әйдәгез, исем кушабыз. Гөлчәчәк хочет познакомиться.

**Балалар:** Мин – Рамиля. Мин – Лилия һ.б.

**Гөлчәчәк:** Кызлар, мин сезне чәйгә чакырам. Һәрберсен чакырып утырта.

Ай-яй, кызлар, сезнең өстәлегез шундый мул.

**Балалар:** Әйе, бу чәкчәк. Бу кәнфит. Бу вафли. Бу печенье. Бу алма (банан, ипи, чәй).

**Гөлчәчәк:** Әйдәгез, без үзебезнең яңа дусларны сыйлыйк.

**Балалар:** Һәрберсе нәрсәдер алып бирә.

**Гөлчәчәк:** Тәмлеме?

**Балалар:** Печенье баллы. Банан тәмле.

Безнен өстәл мул һәм зур.

Монда утыра – Алсу. Мин – Алсу.

Әйе, шул, әйе, шул. Безнең өстәл мул һәм зур.

Әйе, шул, әйе, шул. Без бик тату һәм матур.

**Тәрбияче:** Жырладык. Спели. Рәхмәт, дусларым. Минем Гөлчәчәк бүген үзенә күп дуслар тапты. Рәхмәт сезгә. Сау булыгыз!

Шөгыльне җыр җырлап бетерәләр.

Бар бездә бакча,
Анда балалар бик күп.
Алар бик матур, алар бик тату.
Алсу, Алсу кил әле,
Биеп биеп кит әле.
Әллә-әллә биеп кит әле.

## МИЛЛИ ЙОЛАЛАР

*Корбангалиева Рәхилә Вәлиҗан кызы, тәрбияче,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы*
*«29 нче санлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» МБМББУ*

Нәүрүз – борынгыдан килгән язгы бәйрәм. Бу бәйрәмне төрки һәм фарсы халыклары бәйрәм итә. Нәүрүз сүзе үзе дә фарсы теленнән кергән, «Яңа көн» дигән сүз.

Нәүрүз 21-22 мартта бәйрәм ителә. Ул бәйрәм яз килү, язгы кыр эшләренең башлануы белән бәйле. Шуңа күрә Нәүрүзне күбрәк көньяк халыклары бәйрәм итүе очраклы хәл түгел, чөнки ул якларда язгы кыр эшләре нәкь менә шул вакытта, март ахырларында башланып китә.

Нәүрүзне кайсы халык, ничек итеп бәйрәм итә соң? Иранда һәм Урта Азиядә яшәүче халыклар бу бәйрәмне аш-су белән, күтәренке күңел, котлау-тәбрикләү белән каршы алганнар.

Бәйрәмгә дип алдан үк төрле азыклар, йола ашамлыклары әзерләнгән. Өстәлгә, гадәттә, җиде төрле ашамлык куела торган булган. Нәүрүз көненә дип һәртөрле бөртекле ашлыкларны аерым савытларда уҗымлатып, ямь-яшел бизәкләр белән бизәп һәм яңарыш символы итеп өстәлгә куйганнар. Шуларның тишелешенә куелыгына яки сирәклегенә карап, киләсе елның уңышын юраганнар.

Ләкин Нәүрүз ул гел игенчелек бәйрәме генә түгел. Ул, гомумән, табигатьнең яңару чоры бәйрәме. Нәүрүз 21 мартта дип исәпләнсә дә, аны ел килешенә карап, көннәрен үзгәртеп тә бәйрәм иткәннәр.

Безнең борынгы бабаларыбызның Төньяк Кавказ белән тарихи бәйләнешләре булуын истә тотып, шул якта яшәүче халыклар: кумыклар, карачай-балкарларның Нәүрүз бәйрәмен ничек үткәрүләре турындагы мәгълүматларга берникадәр күз салып китик.

Кумыклар, Дагыстанда яшәүче төркиләр, тел ягыннан татарларга бик якын кардәш. Биредә Нәүрүз бәйрәме көнне балалар, яшьләр өйдән-өйгә кереп, Нәүрүз сәламе әйтеп:

Нәүрүз көнне казан тулса,
Бу елны ак (сөт) мул булыр.
Олы кешедән фатиха алсаң,
Шунда уңышлы ел булыр, – дип Нәүрүз белән котлап йөргәннәр.

Нәүрүз җитә – яз килә.
Бу өйләр – ару өйләр,
Эчендә алтын чөйләр.

Әссәләмегаләйкүм,
Алдагы көн яхшы булсын,
Нәүрүз көне мөбәрәк,
Нәүрүз көне мөбарәк!

Аргы өйдә он или,
Бирге өйдә тоз или.
Безгә күкәй бирмәсәң,
Сине шайтан түбәли.

Таң яхшы булсын, хуҗалар!
Нәүрүз итеп килгәнбез
Бу көнне бәйрәм итеп.
Шөкер булсын Ходайга,

Котылдык язгы җитеп.
Нәүрүз көне мөбарәк,
Нәүрүз көне мөбарәк!

Татар халкының үзенчәлекле этнографик төркемнәреннән саналган себер, әстерхан татарлары Нәүрүз бәйрәме үткәрелә торган көннәрне «әмәл, әмил» дип атыйлар (әмәл – фарсыча хәмәл март ае дигән сүз), шул вакытта «нәүрүз» сүзен дә беләләр. Әстерхан татарлары Әмил бәйрәме көнне кырга чыгып, сөтле боткалар пешереп теләкләр әйтәләр, башка авыллардагы туганнарын кунакка чакыралар.

«Нәүрүз җитә – яз килә, үрдәк белән каз килә», – дигән сүзләре дә олылардан калган.

Күргәнебезчә, Нәүрүз бәйрәменең тарихы шактый кызыклы, катлаулы. Безнең борынгы бабаларыбыз әле Ислам динен кабул иткәнче, ай-кояш календаре белән яшәгәннәр.

Кояш календаре буенча яңа елның беренче көне 21 мартка туры килә. Бу көнне кояш зодиакның хәмәл (кузы) йолдызлыгына кергәнгә; айның үзенә «Хәмәл ае» дигән исем биргәннәр, ә татарлар аны «Нәүрүз ае» дип тә йөрткәннәр. Март аенда Нәүрүз дип, Яңа ел дип бәйрәм итүне безнең борынгы бабаларыбыз белгән. Ә бит Нәүрүз бәйрәмен татарлар күп гасырлар элек бәйрәм иткәннәр. Татар халык иҗатында аңа карата такмаклар, әйтемнәр, гадәт-йолалар сакланган. «Нәүрүз мөбарәкбад!» Безнең бабаларыбыз һәм әбиләребез һәр елның 21 март көнендә бер-берсен шулай итеп сәламләгәннәр.

Борын үткән заманнан,
Болгар белән Казаннан,
Җаек белән Иделдән
Бу бәйрәм безгә килгән!

Мәгънә бардыр сүзләрдә,
Әйтми белең сезләр дә,
Бәйрәм килде безләргә
Нәүрүз мөбарәкбад!
Нәүрүз мөбарәкбад!

Бу көнне сугыш сөңгеләре дә кырыйга куелган, ачу-нәфрәтләр онтылган, уртак икмәк тулы тубал чыккан, җыр-бию, уен-көлке тынмаган, бары да Нәүрүзбикәне сәламләгән.

«Яңа елны ничек каршыласаң елың шулай үтәр», – дигән борынгылар.

Безнең бабаларыбыз аны ипи-тоз, якты йөз белән каршылаганнар.

Яз бәйрәме – Нәүрүз бәйрәме нык итеп тамырланып калган. Без татар халкы гына, аны соңгы вакытта, күп әйберләрне онытткан сыман, бераз онытып җибәргәнбез.

Без бит Яз бәйрәмен шат күңел белән «Урыс кышын озату» исеме астында, ә тагын төгәлрәк әйткәндә, «Масленница»ны җырлый-җырлый, бии-бии үткәрдек. Аннары, бәйрәм буларак, Сабан туе нәкь менә игенчеләрнең, авыл халкының көтеп алынган бәйрәменә әйләнгән. Әмма Нәүрүз – безнең халкыбызның ерак тарихлар белән, башка халыклар белән уртак бәйрәме. Нәүрүз эле дә яз хәбәрчесе, җир сулышы, игенчене кышкы йокысыннан уята, сабан-сукаларны, чәчү орлыкларын барларга вакыт җиткәнлеген искә төшерә. Әле күңелле итеп җырлап-биеп, күңел ачып алырга вакыт бар. Бүген без үзебезнең үсеп килүче буынга, мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балаларына, буыннан-буынга күчеп килүче бу бәйрәм, йололарны һәрдаим искә төшереп кенә түгел, ә күмәк бәйрәм тамаша итеп үткәрү мөмкинлекләрен дә күздә тотып, бергәбергә эшләргә, бәйрәмнәр үткәрергә тиешбез.

Шәһәр күләм мәйданчыкларында Нәүрүз бәйрәме үткәрелгәннән соң, бик тырышып, без дә үзебезнең балалар бакчасында, төрле әкият геройлары булып киенеп, балалар шигырь, җыр, бию такмаклар өйрәнеп зур бәйрәм чарасы уздырдык.

Бу бәйрәмгә эти-әни, әби-бабайлар да бик теләп катнаша, өйдә пешерелгән татар халык ашларыннан күргәзмәләр оештырдык, төрле ярмалардан ботка пешерел, һәм бәйрәм азагында, тәм томнардан тәмле чәй мәҗлесе үткәрдек.

Кыскасы, бәйрәм азагында, һәрберсе, бер-берсенә, Нәүрүз мөбәрәк булсын! – диеп бер-берсен чын күңелдән котладылар.

Һәркемнең күңеленә хуш килде бу Нәүрүз бәйрәме.

Милли йолалар онытылмасын.

Бәйрәмнәр дәвам итсен дигән теләктә каласы килә.

Нәүрүз мөбарәкбад!

# ПРОЕКТНЫЕ РАБОТЫ НА УРОКАХ ТЕХНОЛОГИИ, КАК ОСНОВА НРАВСТВЕННО-ПАТРИОТИЧЕСКОГО ВОСПИТАНИЯ ПОДРАСТАЮЩЕГО ПОКОЛЕНИЯ

*(Проектная деятельность, предмет «Технология»)*

*Кутузова Наталия Петровна,*
*учитель технологии высшей квалификационной категории,*
*МАОУ «Нурлатская гимназия им. М.Е. Сергеева», г.Нурлат*

*В современных условиях, когда происходят глубочайшие изменения в жизни общества, одним из ведущих направлений работы становится патриотическое воспитание. Чувство патриотизма многогранно: любовь к родным местам, гордость за свой народ, за его культуру. Статья ознакомит учителей и обучающихся с творческими проектами: «Тряпичная кукла как элемент русского народного творчества», «Новаторское осмысление культурных традиций в синтезе визуальных видов искусств».*

Ведущей формой учебной деятельности предмета «Технологии» является проектная деятельность. На протяжении нескольких лет работаю над методической темой: «Проектная деятельность на уроках технологии и во внеурочное время в условиях реализации ФГОС».

Разработала «Сборник методических рекомендаций по оформлению пояснительной записки творческого проекта предметного цикла «Технология» 5-11 классах». Опубликован на сайте «Инфоурок». В нем представлены конкретные рекомендации к оформлению и выполнению творческого проекта. Рекомендации предназначены для учителей и учащихся 5-11 классов. В нем рассмотрены научно-методические и нормативные основы организации проектной деятельности школьников, предложены методические рекомендации по оформлению пояснительной записки творческого проекта, его защиты. Ознакомиться с разработкой можно по QRC.

Проектная деятельность на уроке и внеурочное время позволяет создать атмосферу поиска, исследования, накопления информации, творческой самостоятельности, умению

планировать свои действия, тщательно взвешивать принимаемые решения, сотрудничать с учащимися и учителями.

В тематике проектов, выполненные моими ученицами, отражаются не только содержание изученного ими программного материала, но и индивидуальные интересы и возможности школьников. С самого начала они усваивают алгоритм проектирования: выбор и обоснование темы, разработку авторской концепции будущему изделию, проработку эскизов, маркетинговое и социологическое исследование, а также технологию последовательности изготовления, экономическое и экологическое обоснование готового проектного изделия, подготавливают защиту проекта.

Выполнить изделия во время урока, не всегда возможно. Поэтому целесообразно заниматься его изготовлением во внеурочное время. После уроков учащиеся выполняют свои изделия, обсуждают, что необходимо доработать, какие найти интересные решения для воплощения задуманной идеи. Это даёт возможность им раскрыть свой потенциал, у них возрастает интерес к предмету, т.к. они проявляют свои творческие возможности.

Проектная деятельность способствует творческой самостоятельности, развитию целеустремленности, инициативности, умению работать в команде, воспитание ответственности за свою деятельность, удовлетворенности, формированию самооценки, активной жизненной позиции.

В течение года, учащиеся выполняют проекты, с которыми принимают участие в конкурсах и олимпиадах. Приведу несколько проектов обучающихся по технологии обработки текстильных материалов, которые пробуждают любовь к Родине, развивают интерес к истокам народной культуры, обычаям и традициям:

**Проект «Тряпичная кукла как элемент русского народного творчества».**

В данном проекте представлены куклы, изготовленные в технике народной куклы «На Выхволку». В процессе работы над проектом нами был собран и изучен материал по истории куклы, выяснили, что в традиционно-бытовой культуре народа куклы являлись важной составной частью

календарных и семейных праздников, служили оберегами человека, дома, семьи. Они были игрушками, через которые дети знакомились с укладом жизни и получали необходимые бытовые и нравственные знания. Ознакомиться с проектной работой можно по QRC.

**Проект «Новаторское осмысление культурных традиций в синтезе визуальных видов искусств».**

Основная цель этой коллекции – перенести архитектурные памятники искусства городов нашей страны на одежду.

**Актуальность темы** – каждое государство стремится к сохранению культуры для последующих поколений. В своей коллекции передали богатство традиций в области национального и архитектурного искусства России, изобразив их на одежде. Ознакомиться с проектной работой можно по QR-коду.

**Вывод:** Проектная работа – это целенаправленная деятельность, которая дает возможность учащимся применить свои знания на деле, приобрести новые знания по теме проекта самостоятельно, пользоваться уже приобретенными знаниями для решения практических задач, познать самого себя. У учащихся появляется желание и возможность разработать, проанализировать, проверить и воплотить возникшие у них идеи в материале. Выполняя проектную работу, они становятся более инициативными и ответственными, повышается мотивация в достижении намеченных результатов. Проявляют уважение к прошлому своего народа труду предков, сохранивших для них этот мир и эту страну.

**Список источников:**


1. Пономарева Н.А. Технология. 5-11 классы. Проектная деятельность на уроках. Планирование, конспекты уроков. ФГОС / Н. А. Пономарева. – 3-е издание. – Волгоград: Учитель, 2020. – 107 с. – Текст: непосредственный.

2. ФГОС. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования. Стандарты третьего поколения [Текст]. Приказ Министерства образования и науки РФ от 17 от 31.05.2021 N 287 (ред. от 18.07.2022).

# «АЛТЫН КӨЗ» ТЕМАСЫ БУЕНЧА КРОССВОРД

*Локманова Алисә Өлфәт кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*«“Адымнар-Әлмәт” күптелле гимназиясе» МАГББУ*

Башлангыч сыйныф укучылары өчен төзелгән бу кроссвордның сораулары автор табышмаклары рәвешендә тәкъдим ителә. Аны татар теле, әдәби уку дәресләрендә «Көзге уңыш», «Алтын көз» кебек темаларны өйрәнгәндә кулланырга мөмкин. «Сөмбелә», «Уңыш бәйрәме» һ.б. мәктәптә көз көне үткәрелә торган дәрестән тыш чараларда да файдаланырга була.




***Сораулар:***

1. Көзге бакча яме ул,
Кызгылт-сары төстә ул.
Үзе түгел бер дә вак,
Исеме аның – ... *(кабак)*.

2. Балалар аны ярата,
Агачтан үрелеп ала.
Файдасы бик күп булганга,
Барысы да ашый ... *(алма)*.

3. Тышта салкын булмаса да,
Катлы-катлы киенә.
Кетер-кетер кетердәтеп
Бар да кимерә ... *(кәбестә)*.

4. Үзе тәмсез булса да,
Бар чирне дә җиңә ул.
Булса да үзе вак-вак,
Бик файдалы ... *(сарымсак).*

5. Күздән яшьләр чыгара,
Авызда тәме кала.
Коткара ул томаудан,
Ачы яшелчә – ... *(суган).*

6. Куян ашый кетер-кетер,
Исеме аның – ... *(кишер).*

7. Куе кызыл төстә,
Бик файдалы яшелчә.
Ашка матур төс бирер,
Исеме аның – ... *(чөгендер).*

8. Сусыл кызыл бу җиләк,
Үзе бардыр бер чиләк.
Тәмләп ашый малай, кыз,
Бик баллы шул ул ... *(карбыз).*

## ДӘРЕСТӘ ҺӘМ ДӘРЕСТӘН СОҢ ЭШЧӘНЛЕКТӘ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ

*(Эш тәҗрибәсеннән)*

*Лотфуллина Гөлия Гариф кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*«39 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ,*
*Яр Чаллы шәһәре*

Укучыларның белем сыйфатын күтәрүдә заманыбыз мөгаллимнәр алдына яңа бурычлар куя. Гомуми белем бирү системасында функциональ грамоталылыкны формалаштыру өстенлекле максатларның берсе булып тора. Белемле булу – бер хәл, ә менә эшчәнлекнең төрле өлкәсендә тормыш куйган бурычларны хәл итү, аралашуны, социаль мөнәсәбәтләрне җайлау максатында аннан файдалана белү – бөтенләй икенче нәрсә. Шуңа күрә бу эштә, төп юнәлешләрнең берсе итеп, укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру юнәлеше сайланган. Функциональ грамоталылыкның нигезендә

белем ала белү тора, шунлыктан мин үз эшемдә укучыларны, беренче чиратта, белем ала белү осталыкларына өйрәтәм. Ә бит моның өчен бала минем предметны яратырга, предмет белән шөгыльләнергә теләге, үз-үзенә ышанычы булырга, шул ук вакытта, җаваплылык та тоярга тиеш. Дәресләрне планлаштырганда, кызыксынуны арттыру өчен, төрле методлар кулланам. Һәр дәрестә компьютер технологиясен куллану, критик фикерләргә өйрәтү, укучының яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, талантлы укучылар белән эш, аларның лидерлык сыйфатлары исәпкә алу истә тотыла. Киләчәктә укучы нинди профессия сайлар, аның заманында уңышлы булу өчен нинди гамәли күнекмәләр кирәк булыр соң? Мин бу сорауларга ачык җавап бирә алмасам да, укучыларны функциональ грамоталылыкка өйрәтү, аларның киләчәк тормышларында үз позицияләрен ныгыту өчен зур роль уйнаячак икәненә иманым камил.

«Балалар матурлык, уен, әкият, музыка, рәсем, хыял һәм иҗат дөньясында яшәргә тиеш», – дигән В.А. Сухомлинский. Уенның уку процессындагы әһәмияте турында сөйләгәндә, иң башта аның бала тормышындагы ролен искәртеп китү мөһим. Уен аша бала дөньяны танып белә, акылын баета, уен ярдәмендә үсә. Уен шулай ук игътибарлылыкны, хәтерне үстерә, сүзлек запасын баетуга ярдәм итә.

Туган телгә кызыксыну тәрбияләү өчен дәрестән тыш эшчәнлек тә булу бик мөһим. Шул максаттан чыгып, мәктәптә «Курчак театры» оештырылды. Ул функциональ грамоталылыкны үстерүнең бөтен шартларына да җавап бирә. Әкият геройлары белән танышканда да, персонажның үзенчәлеген ачарга ярдәм итә торган музыканы сайлаганда да, һәр геройның үзенә генә хас булган характерын тавыш, кул, баш, гәүдә хәрәкәте белән тулыландырганда да укучы һәрвакыт фикерле, чагыштыра, анализ ясый. Театрның уңышлы килеп чыгуы аның дөрес оештырылуына, әкиятнең яшь үзенчәлекләрен истә тотып сайлануына, текстның тәрбияви максатларына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле. Укучылар һәм әти-әниләр белән тыгыз элемтә булганда гына тиешле нәтиҗәгә ирешеп була. Бала белән көндәлек аралашучы ата-ана, бала тормышында актив катнаша башлый, идеяләрне тулыландыручы, иҗади бала белән бергә кызыксынучы, үзе өстендә даими эш алып баруны контрольдә тотучы да, максатка

ирешүдә ярдәмче дә ул. Курчак театры кую укучының яхшы әзерлеген, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен, җаваплылык тоюны таләп итә. Укучылар әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел табып эшләргә, актерлык сәләтен үстерергә, халык алдында үзен тотарга, рольне истә калдырырга, шул ук вакытта, курчакны дөрес итеп хәрәкәткә китерергә өйрәнә. Укучы фикерли, эзләнә, үз эшенең нәтиҗәсен күрү өчен, башкаларны да күзәтә, ярдәм итә, юл куя. Фикерләү күнекмәсе укучыларга уку дәверендә генә түгел, алдагы тормышларында кирәк булачак (килеп туган мәсьәләне дөрес чишү юлларын табу, күпсанлы мәгълүмат белән эшләү, анализлау). Гомумән, курчак театры проекты – баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә, кызыксынучанлыгын арттыруда нәтиҗәле алымнарның берсе булып тора дип уйлыйм мин. Укучыларның төрле конкурсларда алган диплом-грамоталары аларның эшләренең күрсәткече булып тора бит инде. Әмма тамашачы белән турыдан-туры очрашу зур тәрбияви максатка ия. Балалар үзләренең беренче адымнарын мәктәптә ясадылар инде. Үз яшьтәшләренә эшләрен тәкъдим иттеләр, якындагы балалар бакчасын да кунакка чакырдылар. Бу эштә безгә шулай ук әниләр ярдәмгә килде. Оештыручы ролен алар үтәделәр. Театр беткәч, бакча балалары да курчакларны хәрәкәткә китереп карады. Роль башкаручы укучылар үзләрен чын профессионаллар кебек тотты. Бәләкәйләргә үзләренең төпле киңәшләрен бирде.

Йомгак итеп, шуны әйтәсе килә: әгәр дә укытучы дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә күргәзмәлекне җитәрлек дәрәҗәдә кулланса, төрле уен ситуацияләре, сөйләм күнегүләре, инновацион технология элементларыннан дөрес файдалана белсә, ул, һичшиксез, эшендә зур уңышларга ирешәчәк. Укучылар да туган телне яратып, теләп өйрәнә башлаячаклар!

**Чыганаклар исемлеге:**

1. «Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандарты». РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2010.

2. Татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә башлангыч сыйныф укучыларының функциональ грамоталылыкларын формалаштыру үзенчәлекләре: методик тәкъдимнәр / авт.-т.: Җамалетдинова З.И. – Казан: ТРМҮИ, 2021. – 48б.

## ХАЛКЫМ МИРАСЫ – ТҮБӘТӘЙ

*Мәүлиева Зәнфирә Ситдик кызы,*
*балаларга ана теле өйрәтүче югары категорияле тәрбияче,*
*«Батыр» 111 нче балалар бакчасы – баланың аң-белемен үстерү үзәге муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Яр Чаллы шәһәре*

*Балаларны татар халкының көнкүреш һәм гореф–гадәтләре, йолалары, уеннары белән таныштыру, зәвыкларын үстерү, халкыбызның рухи байлыгына ихтирам тәрбияләү. Түбәтәйнең тарихы, формалары, төрләре, бизәлеше белән таныштыру.*

Булган бит шундый заманалар: безнең татар ир-атларын түбәтәйсез күз алдына да китерә алмаганнар. Мөселман гадәте буенча чәчләре кырдырып алынган баш түбәсенә берсүзсез бәрхет яисә вельвет түбәтәй менеп «кунаклаган». Хәтта бүрек, эшләпә ише баш киемнәре кигән чакта да түбәтәй салынмаган, эчке баш киеме булып калган. Авыллардагы татар апалары яулык өстеннән дә ирләр түбәтәе кигәннәр. Түбәтәйләрнең ике төре бар: Казан артында аларны кәләпүш һәм такыя дип атыйлар. Формасы, тегелү рәвеше, кайсы заманнныкы булуы белән аерылып тора алар.

Такыя – гадәти бәйләм башлыкларга охшатып, ярым сфера рәвешендә дүрт өлгедән тегелә. Аның килеп чыгышы турында төрле фикерләр бар. Берәүләр аны урта гасырлар сугышчысының очлым (шлем) астыннан киелгән баш киеменнән килеп чыккан дип саный. «Түбәтәй» сүзе үзе дә «түбә», ягъни баш түбәсенә киелүче әйбер мәгънәсен аңлатып тора лабаса. «Такыя» исә чәчәкләрдән үрелгән таҗ буларак билгеле. Кәләш бирнәсенә дә күлмәк, аякчу кебек әйберләр белән бергә, такыя да кергән. Яшь кешене никахы белән котлаганда: «Такыяң котлы булсын», – дигәннәр. Такыя – ирләр түбәтәе генә түгел, кызларның баш киеме дә.

Түбәтәйнең икенче төре – кәләпүш, кулланылышка соңрак, XIX гасырның 60 нчы елларында гына килеп керә. Аның формасы да такыядан үзгәрәк: яссы түгәрәк түбәле һәм каты кырыйлы ул. Кәләпүш борынгырак заманда киелмәгәнгә күрә, галимнәр аны төрекләр кия торган фәстән килеп чыкмадымы икән, дип уйлый. «Кәләпүш» сүзе исә таҗик теленнән алынган: «кәллә» – баш, «пушидан» – каплау, кию мәгънәсендә. XIX гасыр ахырында кәләпүшләр бөтенләй үк түбәтәйләрне кысрыклап чыгара һәм татарларның төп баш киеменә әверелеп китә. Татар эшмәкәрләре һәм зыялылары аны аеруча яратып

кия. XX гасыр башында алынган иске фоторәсемнәрдә без еш кына зыялы-затлы татар ирләрен кара казакин һәм гади кара кәләпүшләрдән күрәбез. Бу баш киеме бүгенге көндә дә яшәп килә. Кәләпүш җитештереп сатучылар аларга үз яңалыкларын, өстәмә бизәкләрен куша.

Түбәтәй татарларда гына түгел, башка төрки халыкларда, мәсәлән, Урта Азия халыкларында да иң киң таралган баш киемнәреннән санала. Исемнәре дә шундый ук: такыя, тахья, түбәтәй, кәләпүш. Шулай итеп, түбәтәй безне борынгы тарих белән, барлык төрки халыкларның бербөтен булып, бер үк баш киемнәре кигән чаклары белән бәйләп тора.

Түбәтәйләр күбесенчә бәрхет һәм вельветтан, затлыраклары парчадан тегелгән. Аның өчен яшел, зәңгәр, шәмәхә, кызыл төсләрнең иң куе төсмерләре файдаланылган. Көндәлек түбәтәйләр гади булган, аларны чигеп тормаганнар. Чигүлеләрен, бизәклеләрен күбрәк яшьләр кигән. Алтын һәм көмеш җепләр, ефәк, ука, сәйлән белән чигелгән түбәтәйгә яшь егетләрнең күзе ничек кызмасын, ди? Бизәкләре, вакытына карап, үзгәреп торса да, алар нигездә үсемлек-чәчәк дөньясын тасвирлаган. Иң еш очраган бизәк – үзәктә чәчәк бәйләме, тәлгәшләре, чит-читендә бордюр тасмасы. Элекке заманда һәр этник төркемдә, һәр халыкта түбәтәйнең үз формасы, төсе, бизәге булган. Димәк, ул аны кигән кешенең чыгышын да ачык күрсәтеп торган. Хәзерге вакытта түбәтәй – менә дигән бүләк тә, безне борынгы тарихыбыз, бай традицияләребез белән бәйләп торучы үзенчәлекле символ да.

Элегрәк баш киемнәрен вак һөнәрчеләр тексә, еллар үткәч, бу эш белән артельләр, сәүдә фирмалары шөгыльләнә башлый. XX гасыр башында Казанда һәм аның тирә-ягында меңнәрчә осталар түбәтәй теккәннәр һәм чиккәннәр.

Татар милли баш киемнәре соңгы йөз ел эчендә үзгәрсәләр дә, актуальлеген югалтмадылар. Татарстанда аларны бүген дә кияләр һәм киелә торган аерым очраклар да бар.

Баш киеме татар милли киеменең иң матур элементы булып тора. Аның буенча безнең бабаларыбыз әңгәмәдәшенең байлыгын гына түгел, аның җәмгыятьтә тоткан урынын да хатасыз билгели алганнар. Мәсәлән, мөселман башындагы кечкенә генә бәйләнгән башлык, ягъни, «түбәтәй», бу кешенең тыйнак һәм дини булуын күрсәткән. Түбәтәй татар ир-атлары кием-салымының иң аерылгысыз өлеше булган һәм хәзер дә шулай. Түбәтәй татар халкы өчен баш киеме генә түгел, ә милли символ.

Балаларга кечкенәдән үк әдәплелек, инсафлык, мәрхәмәтлек, толерантлылык тәрбияләү ата-аналарның, тәрбиячеләрнең аеруча җаваплы һәм изге бурычы. Шул ук вакытта, буыннардан буыннарга күчеп килә торган тәрбия чаралары искиткеч күп төрле. Мәсәлән, халыкның йола бәйрәмнәре, календарь бәйрәмнәре, кунакчылылык кагыйдәләре, әйтемнәр, мәкальләр, табышмаклар, җырлы-биюле уеннар, милли уеннар, һ.б.

Милли тәрбия бирү, халык тарихын өйрәнү, аның мәдәни байлыгы турында күзаллау булдыру, туган теленә, халкына карата соклану, горурлану хисе тәрбияләү, балаларда ул яшәгән республика, район, авыл тарихы турында мәгълүмат бирүдән башлана. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар телләгән чакта һәм аерым шөгыльләрдә, милли мәдәният почмакларындагы төрле милләт киемнәренә киенгән курчакларны кулга алып уйный, аларның милли киемнәре белән таныша алалар. Алар шул әйберләрнең исемен әйтә алалар, кайда кулланылганнарын беләләр. Шулай ук, бакчабызда оештырылган музейда татар халкының милли хәзинәләре белән танышалар. Бу барлык чаралар балаларда татар халкының үткәненә кызыксыну уяту, милли традицияләребезгә, милли кием тарихына хөрмәт тәрбияләү, милли хәзинәбезне саклау, алар белән горурлана белү сыйфатлары тәрбияли.

Балаларның яратып уйный торган «Түбәтәйле» уены:

1 нче вариант: Уртада 5-6 урындык тора, урындыкларга түбәтәйләр куела. Балалар урындыклар тирәли басалар, көй башлануга, җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, түбәтәйләрен кияләр, шул арада урындыкларга утырып өлгерергә тиешләр. Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уйнаганда, уртада өч урындык кала, уйнаучылар саны артыграк була. Соңга таба бер урындык калдыралар.  Шулай итеп, иң игътибарлы, җитез бала билгеләнә.

2 нче вариант: Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый түбәтәйне бер-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа «җәза» бирелә (бии, җырлый, шигырь сөйли, әтәч булып кычкыра һ.б.). Уен шулай дәвам итә.

*Түбәтәеңне кигәнсең,*
*Бик ераклардан килгәнсең,*
*Төскә матурлыгың белән*
*Шаккатырыйм, – дигәнсең.*

*Түп-түп-түбәтәй,*
*Түбәтәең укалы.*
*Чиккән матур түбәтәең*
*Менә кемдә тукталды.*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАСЫ

*(Уртанчылар, зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме өчен)*

*Минемуллина Райхана Нурулла кызы, тәрбияче,*
*Татарстан Республикасы Кукмара районы*
*«Киндер Күл авылы балалар бакчасы» МБМББУ*

**Максат:** Татар халыкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрне яңарту; балаларны татар халык традицияләрендә тәрбияләү, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре аша татар теленә мәхәббәт хисләре уяту; татар халык уеннарын һәм җырларын өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Әдәплеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олылырны хөрмәт итәргә өйрәтү.

**Җиһаз:** «Каз» йолкыр өчен тазлар, «Каз» түшкәләре, тастымаллар, каз каурыйлары, иләк, утыргычлар, көянтә, өстәл, самавыр, экранда – авыл өе, чишмә рәсеме.

**Актуальлелек:** милли бәйрәмнәрнең һәркайсында халкыбызнын күркәм гореф-гадәтләре, матур йолалары, җыр-бию, уен-көлке чагыла. Кеше әлеге бәйрәмнәрдә һөнәргә, батырлыкка, тапкырлыкка һәм зирәклеккә өйрәнә.

*Залга балалар белән тәрбияче керә, барысы да*
*татар милли киемнәрдән.*

**Тәрбияче:** Безнең татар халкының – әби-бабаларыбызның борынгы заманнарда бик күркәм йолалары, матур бәйрәмнәре күп булган. Сезнең кичке уеннарны, аулак өйләрне, «Нәүрүз», «Сөмбелә» бәйрәмнәрен күргәнегез бардыр. Тагын бер шундый күңелле йола – «Каз өмәсе». Сез беләсезме, ул нинди бәйрәм?

**Тәрбияче:** Каз өмәсе − көзге авылның иң яраткан йола-бәйрәмнәреннән берсе ул. Татар халкы − эшкә бик уңган халык. Элек-электән үк күпләп каз асраганнар. Көз җиткәч, һәр өйдә каз өмәләре гөрләгән. Кызлар, яшь киленнәр, шул өйгә җыелып, каз мамыгы йолкыганнар. Эш вакытында алар милли җырлар җырлаганнар, риваятьләр сөйләгәннәр. Мамыкны җыеп бетергәч, кызлар казларны көянтәләргә асып, су буена төшеп казларны салкын суда юганнар. Бу эштә егетләр дә кызларга булышкан. Эш тәмамлангач яшьләр матур җырлар җырлап, күңелле уеннар уйнаганнар. Каз өмәсе – авыл бизәге, алтын көзнең байлык, муллык, матурлык бәйрәме. Менә бездә бүген, балалар, Каз өмәсенә җыелдык. Әби безне кунакка чакырды. Без аңа эштә ярдәм итәчәкбез һәм шул ук вакытта күңел ачачакбыз да.

**Тәрбияче:** Әби-әбекәй, ач ишегеңе, без килдек, каршы ал. Әби керә.

**Әби:** Исәнмесез, исәнмесез, килдегезме? Әйдәгез, үтегез. Ай нинди матурлар.

**Тәрбияче:** Әбекәй, без сиңа булышырга килдек, казларың быел бик күп дип ишеттек.

**Әби:** И-и! Аллага шөкер! Бик яхшы килегез, миңа бик тә ярдәм кирәк. Әйдәгез, үтегез, килегез менә монда. Хәзер казларны кертәм.

**Әби:** Әйдәгез, эшкә тотыныйк алайса. Иң элек култык астыннан хәрам канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз. Хәзер калган канатларын йолкыйбыз. Кая әле, кызларым, һәр берегезгә каз бирәм, йолкый башлагыз.

**Тәрбияче:** Казларыгыз бигрәк матур, таза булып үскәннәр.

Ә йоннары, каурыйлары мамыкланып беткәннәр.

**Бала:** Кызлар, ә сез беләсезме? Каз ярата елганы.

Йөзә дә ул, чума да ул, су үстерә бит аны.

**Тәрбияче:** Көз көннәре бигрәк ямьле, өмәгә килгән кызлар.

Матур булсын каз өмәсе, әйдәгез, җырлыйк, балалар!

**Жыр «Каз канаты»** (т.х.к).

**Бала:** Миңа бигрәк зур, симез каз эләкте.

**Әби:** Әйе, быел бигрәк уңды шул, балаларым. Өй борынча каз. Балалар, казларның мамыгын аерым, каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле. Каз мамыгыннан гына торган мендәр бик йомшак була.

**Тәрбияче:** Без казларны йолкып бетердек, әйдәгез, казларны монда куйыйк. Казларның эчләрен тазартканчы уйнап-җырлап алыйк.

**Җыр «Дүдәк-дүдәк» (т.х.к).**

**Әби:** Бигрәкләр дә матур җырлыйсыз. Сандугачлар кебек сайрыйсыз. Әллә бер биеп тә күрсәтәсезме?

**Тәрбияче:** Биибез, әбекәй, биибез.

Каз өмәсе бик шәп бәйрәм, күңел ачаек әле.

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр бергә басаек әле.

**«Күмәк парлы бию».**

**Тәрбияче:** Әйдәгез, бергәләшеп уйнап алабыз.

Әй әйләнә, әйләнә, сихерледер бу тукмак.

Нинди җәза бирер икән, безнең каршыда туктап.

**Малайлар:** Карап карыйк әле чынлап та сихерлеме икән? Ә бит бу уенны яшь вакытларында безнең әниләребез дә бик яратып уйнаган.

**Уен: «Тукмак»** *(тукмак кемгә карап туктый аңа җәза бирелә).*

**Әби:** Бик матур уйнадыгыз! Ягез, балалар, казлар турында сөйләп китегез.

**Бала:** Каз өмәсе көз азагы, кыш башында, беренче суыклар үткәч үткәрелә. Хуҗа кеше җәй буе казларны тәрбияли. Ашата, су буенда каргалардан саклый. Хуҗаның уңганлыгы казларының санына һәм симезлегенә карап бәяләнә. Казлар иң кыйммәтле, затлы кошлардан санала. Алар ашларда өстәлнең күрке булып тора.

**Бала:** Миңа әбием, казларны тозлагач, суыткычка куймасаң да бозылмый, ди. Элек каз канатын карага манып, каләм итеп язганнар да.

**Бала:** Карагыз әле бу майлагычка. Аның белән коймак, кыстыбый, таба майлыйлар. Канатлар идән себерергә ярый. Элек канат белән мич алдындагы суынган көлне себергәннәр.

**Бала:** Каз канаты каурыйларын су буена төшкәндә, юл буена сибәргә кирәк. Шулай иткәндә, киләсе елга бу сукмакта казлар тагын да күбрәк булачак.

**Кызлар:** Әби, без су буена төшеп киттек. Көянтәгә казлар асып су буена ике кыз төшеп китә.

**Әби:** Кызлар казларны юып менгәнче, утырып каз канатын сыдырып алыгыз. Әйдәгез әле, кем остарак сыдырыр икән? (*Күңелле бию көе яңгырый*).

**Уен: «Канат сыдыру».**

**Бала:** Каурый сибәм су юлына, ишле булсын казыгыз.

Өмәләрдә эш күрсәтеп, җырлап-биеп алыгыз.

**Бию: «Каз канаты»** *(уртанчылар төркеме)*.

**Тәрбияче:** И әбекәй, безнең өмәчеләребез кайтып киләләр түгелме?

Әйдә, капканы ача тор.

**Бала:** Әбекәй, казларыңның эшен бетердек, чистарттык, бәкедә чайкадык.

**Әби:** Кайтып та җиттегезмени, балакайларым? Кая казларыгызны алып куйыйм әле. Бигрәк уңган балалар булдыгыз. Мин әле коймакларымны да пешереп бетермәдем.

**Тәрбияче:** Ярар, борчылма әбикәй, без уйнап алабыз.

**Уен «Наза»** (т.х.у), *(парлашып бер-бер артлы басалар, аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр, парсыз бала уенчылар каршысында).*

**Малай:** Әйдәгез, «Яшел яулык» уенын уйныйбыз». «Яшел яулык» – кызык уен. Ул сизгерлекне сорый.

**«Яшел яулык» уены** *(уен барышында балалар такмазалар сөйлиләр).*

**Җыр: «Төймә, төймә»** *(җырлап, түгәрәктә әйләнеп йөриләр).*

**Тәрбияче:** Каз өмәсе азагына да якынлашты. Казларыбыз күп булсын. Йортларыбызда бәрәкәт артсын. Бу бәйрәм күренеше сезнең күңелләргә дәрт өстәсен!

**Бала:** Гөрләп үтте, шаулап үтте авылда каз өмәсе.

Бу айларны, бу көннәрне көтеп ала һәммәсе.

**Бала:** Менә шулай каз өмәсен татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Тәрбияче:** Онытылган гореф-гадәтләрне яңартабыз хәзер көннән-көн.

Уен йолалары, җыр-биюе һәр киләчәк көнне бизәсен.

**Җыр «Каз өмәсе»** *(Э. Шәрифуллина сүзләре, З. Мөхәммәтдинов көе).*

**Әби:** Коймагым да пеште. Әйдәгез, балалар каз майларына манып коймак ашыйк, чәй эчик әле.

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Закирова К.В. – Казан: Мәгариф, 2005. – 175 б.

2. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Рәүфә Уразман. – Казан: Татар. кит. нәшр. Б 1992. – 96 бит.

3. Уйный-уйный үсәбез (Балалар бакчасында уеннар): Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.

## ИМПРЕССИОНИЗМ В МУЗЫКЕ И В ЖИВОПИСИ

*(Технологическая карта урока музыки в 5-м классе)*

*Мустафина Фарида Шамилевна, учитель,*
*МБОУ «Татарская гимназия № 1 им. Г. Тукая»*
*Вахитовского района г.Казани*

**Тип урока**: интегрированный урок.

**Цель:** познакомить с направлением в искусстве – импрессионизм, рассмотреть особенности проявления импрессионизма в музыке и живописи.

**Задачи:**

- дать начальные представления об импрессионизме, его истоках, развитии в различных видах искусства, авторах, работавших в данном направлении; проанализировать художественно-изобразительные особенности импрессионизма в живописи и музыке
- развивать музыкальные способности: вокальные данные, музыкальную память, музыкально-аналитическое мышление;
- воспитывать любовь и уважение к музыке.

**Планируемые результаты:**

**Предметные:**

- знать особенности импрессионизма, как художественного стиля, особенности творчества К. Дебюсси. Выразительность и изобразительность музыкальной интонации
- развитие художественного вкуса и интереса к музыкальной деятельности;
- расширение музыкального и общего культурного кругозора; воспитывать интерес к музыке своего народа и других народов мира

**Метапредметные:**

- умение организовывать учебное сотрудничество и совместную деятельность с учителем и сверстниками.
- взаимодействие со сверстниками при решении творческих задач;
- умение определять понятия, обобщать, рассуждать и делать выводы, овладение логическими действиями сравнения

**Личностные:**

- ответственное отношение к учению, готовность к саморазвитию
- развитие этических чувств доброжелательности и эмоционально-нравственной отзывчивости,
- реализация творческого потенциала в процессе коллективного или индивидуального музицирования.

**Оборудование:**

- фортепиано, компьютер, проектор, колонки, пульты для голосования

**Музыкальный материал:**

К. Дебюсси «Девушка с волосами цвета льна».

## Ход урока

| Этапы | Деятельность учителя |
|---|---|
| **Органи-зационный** | Организация учебной мотивации<br>Настраивание учащихся на деятельность.<br>«Музыкальное приветствие». |
| **Повторение пройденного материала** | Ребята, давайте вспомним, о чем мы говорили с вами на прошлых уроках. *(Учитель задает вопросы).* |
| **Актуализ. опорных знаний** | Сегодня мы с вами продолжим говорить о стилях в искусстве. Чтобы узнать тему нашего урока, необходимо будет правильно разгадать кроссворд. Я буду читать вопросы, а вы будете на них отвечать. Первая буква каждого слова, является ключом к разгадке. Играем в «Поле чудес». |

| **Деятельность учащихся** | **УУД** |
| --- | --- |
| Приветствие учителя | *Личностные:*<br>– мотивационная готовность;<br>– *Регулятивные:*<br>– Организовать свою деятельность. |
| Дети отвечают на вопросы учителя:<br>– Какие направления в искусстве вы знаете?<br>– Что такое симфония?<br>– Что такое миниатюра?<br>– Если в 18-м веке музыкальным центром Европы была Вена, то в 19-м веке становится Париж. Давайте вспомним Париж являтся столицей какой страны? (найти по карте)<br>– Какие достопримечательности Франции вы знаете? | *Познавательные:*<br>– формулируют ответы на вопросы;<br>*Коммуникативные:*<br>– умение выражать свое мнение. |
| Дети разгадывают кроссворд:<br>– Творческая деятельность, в результате которого появляется картина, скульптура, музыка.<br>Это…? (Искусство).<br>Используется для шитья? (Игла).<br>– Является главным в музыке. Чайковский говорил, что это душа музыки (мелодия).<br>– Сочиняет рассказы, повести, сказки, стихи… (Поэт, писатель).<br>– Король музыкальных инструментов. Похож на большой корабль, с тремя ножками (рояль).<br>– Хвойное дерево (ель).<br>– Струнно-смычковый инструмент (скрипка). | *Познавательные:*<br>– формулируют ответы на вопросы;<br>– самостоятельно формулируют тему урока.<br>– рассуждают и делают выводы;<br>– используют знания из других областей<br>– устанавливают причинно-следственные связи. |

| | |
|---|---|
| | Вы разгадали слово ИМПРЕССИОНИЗМ.<br>У вас наверняка уже возникли вопросы о том, что такое импрессионизм? |
| **Открытие и усвоение новых знаний** | Давайте обратимся к учебнику и найдем информацию (с.140).<br>Сообщение учителя. (работа с презентацией)<br>**Импрессионизм** – новое направление в искусстве, возникшее во Франции в 70-е годы 19 века. От французского слова «импрессион» означает «впечатление». В начале импрессионизм возник в творчестве художников, а позже в музыке, литературе, театре *(записывают в тетради).*<br>Художники, работая на открытом воздухе, старались отразить в своих картинах мимолетные впечатления от реально существующего мира, добиваясь ощущения растворенности предметов в сверкающем солнечном свете, вибрации воздуха. Все это порождало светлую, трепетную живопись.<br>У истоков создания этого направления стояли французские художники Клод Моне, Камиль Писсаро, Эдуард Мане, Пьер Огюст Ренуар, Эдгар Дега.<br>Художники-импрессионисты выходили с мольбертами из мастерских на воздух и могли рисовать одну и ту же картину по несколько раз. Например, Клод Моне написал один и тот же стог сена 15 раз. И каждый раз это была новая картина. (*демонстрация картин импрессионистов.*).<br>Музыкальный импрессионизм возник в конце 80 – начале 90-х гг. Основателем импрессионизма в музыке был французский композитор Клод Дебюсси (1862-1918) *(записывают в тетради).* К. Дебюсси занимался поиском необычайных звучаний в музыке. Музыка Дебюсси была наполнена игрой светотени, прозрачными, как бы невесомыми красками, которые создают ощущение звуковых пятен. Он создал новый пианистический стиль, который обогатил фортепианную музыку. Если раньше в классической музыке было принято играть строгими гармониями, то в аккордах Дебюсси появились гармонии из 6-7 нот, так |

| | |
|---|---|
| – Название цветка и конфеты (ирис)<br>– Музыкальный спектакль, где все герои поют (опера).<br>– В слове пишут буквы, а в музыке …? (ноты)<br>– Музыкальный? (инструмент)<br>– Чем укрываются от дождя (зонт)<br>– Нота в музыке (ми) | |
| Работа по учебнику (поиск определения слова «импрессионизм»).<br>Слушают учителя.<br>Записывают в тетрадях тему и определение.<br>Сравнивают картины<br>Отвечают на вопросы учителя. | *Личностные:*<br>– проявлять эмоциональную отзывчивость на музыкальное произведение.<br>*Познавательные:*<br>– сравнивать музыкальные и художественные образы, музыкальные фразы, аккомпанемент, штрихи музыки.<br>– извлекать необходимую информацию из прослушанного текста;<br>– проводить взаимосвязь между разными видами искусства. |

| | |
|---|---|
| | называемые кластеры. Благодаря этому приему гармония становилась красочней, богаче. Своим произведениям композитор давал необычные названия, созвучные названиям картин. Например, «Звуки и запахи реют в вечернем воздухе», «Лунный свет», «Девушка с волосами цвета льна», «Затонувший собор», «Шаги на снегу» и т.д.<br>Сегодня на уроке мы познакомимся с произведением композитора под названием «Девушка с волосами цвета льна». Но до прослушивания произведения давайте уточним некоторые моменты. Название произведения говорит нам о том, что в музыке речь пойдет о девушке. Значит, это будет картина, где изображен человек. Как называют жанр в изобразительном искусстве, где изображен человек?<br>В названии композитор подчеркивает цвет волос девушки. Цвет льна. Кто знает, какого цвета бывает лен? Как выглядит?<br>Пояснение:<br>Лен – однолетнее и многолетнее растение, представляет собой траву. Цветки льна ярко синего цвета, после созревания обретают золотисто-коричневый цвет. Изо льна изготавливают ценное масло, производят ткань, изготавливают лекарства.<br>Значит, слушая произведение «Девушка с волосами цвета льна», какой цвет волос мы представим?<br>Во время прослушивания попробуйте представить портрет девушки.<br><br>Прослушивание и анализ:<br>К. Дебюсси «Девушка с волосами цвета льна» (*учитель исполняет произведение на фортепиано*)<br>Дети отвечают на вопросы учителя. |

| | |
|---|---|
| Отвечают на вопрос учителя.<br>– Как называют жанр в изобразительном искусстве, где изображен человек?<br>– Кто знает, какого цвета бывает лен? Как выглядит?<br><br>– Какую картину вы представили, слушая произведение?<br>– Какой инструмент звучал?<br>– Если бы вы были художником, какие оттенки цветов вы бы выбрали для написания своей картины? масляные или акварельные? Какие бы тона, цвета использовали? | *Познавательные:*<br>– передавать свои впечатления об услышанной мелодии.<br>– *Личностные:*<br>– Выражать своё эмоциональное отношение к искусству и по окончанию исполнения произведения. *Коммуникативные:*<br>– уметь воспринимать различные точки зрения, формулировать свою точку зрения |

| | |
|---|---|
| **Рефлексия учебной деятельности** | – Физкультминутка<br>– Работа с дыханием<br>– Вокально-хоровая работа<br>– работа с произведением К.Дебюсси «Девушка с волосами цвета льна».<br>– (*пение по фразам, определение строения музыкального произведения*). |
| **Проверка домашнего задания** | Учитель слушает исполнение песни |
| **Обобщение и систематизация новых знаний** | Пришло время подвести итог нашего урока и закрепить знания. Сейчас на экране появятся вопросы. Я буду задавать вопросы, а вы будете отвечать на вопросы, используя пульты для голосования.<br><br>Сегодня мы узнали о направлении в искусстве, под названием импрессионизм. Мы убедились, что портрет могут рисовать не только художники, используя краски, но и композиторы, прибегая к своим средствам музыкальной выразительности, как мелодия, гармония, инструмент, лад… |
| **Домашнее задание** | Нарисовать иллюстрацию к музыкальному произведению К. Дебюсси «Девушка с волосами цвета льна».. |

| | |
|---|---|
| Выполняют зарядку<br>Выполняют разминку для дыхания, исполняют музыкальные упражнения для голоса<br>Слушают произведение еще раз. Определяют строение музыкального произведения, поют мелодию по фразам.<br>Ребята отвечают на вопросы:<br>– Я сегодня на уроке узнал…<br>– Меня сегодня удивило…<br>– Для меня было открытием то, что… | – *Регулятивные:*<br>– выполнять учебные действия, ставя задачи, определяя этапы выполнения заданий.<br>– выполнять учебные действия в качестве слушателя и исполнителя.<br>– *Личностные:*<br>– выражать эмоциональное отношение к искусству в процессе исполнения. |
| Исполнение песни «Гөлләрем»<br>(сл. М. Разов, муз. В. Агапов), оценивают друг друга. | *Регулятивные:*<br>– выполнять учебные действия в качестве слушателя и исполнителя. |
| Ребята отвечают на вопросы, используя ответы «да»/«нет»<br>1. Импрессионизм (от французского – *впечатление*) – направление в искусстве, возникшее в Италии<br>2. Слово «импрессион» означает «впечатление»<br>3. Импрессионизм, в начале появился в музыке<br>4. Клод Дебюсси – французский композитор<br>5. Клод Моне 12 раз нарисовал картину «Стог сена»<br>6. Мы прослушали произведение К. Дебюсси «Лунный свет»<br>7. В произведении «Девушка с волосами цвета льна» композитор рисует музыкальный портрет девушки. | *Познавательные:*<br>– формулируют ответы на вопросы;<br>*Регулятивные:*<br>– адекватно оценивать свои возможности самостоятельной деятельности. |
| | |

## Список источников:


1. Музыка: 5 класс: учеб. для общеобразоват. организаций / Г.П. Сергеева, Е.Д. Критская. – 4-е изд. – М.: Просвещение, 2015.
2. https://infor24.ru/Лён_обыкновенный
3. https://primanota.ru/claude-debussy/claude-debussy-klod-debyussi-devushka-s-volosami-cveta-lna.htm
4. https://www.belcanto.ru/impressionism.html


# ПАМЯТКА «ЗНАКИ ПРЕПИНАНИЯ»



*Мухаметшина Раиля Рустамовна,*
*учитель начальных классов,*
*МБОУ «Средняя общеобразовательная школа № 22 с углубленным изучением отдельных предметов – Центр образования» Советского района г. Казани*


Однородные члены предложения и знаки препинания в них – один из труднейших и важнейших разделов синтаксиса и пунктуации. Поэтому на уроках по теме «Однородные члены предложения» необходимо значительное внимание уделять вопросам интонации, особенно – интонации перечисления.

**<u>Правила постановки знаков препинания в предложениях с однородными членами:</u>**


- Если однородные члены предложения не соединены союзами, а только интонацией, то между ними ставится **<u>запятая</u>**

Мне подарили конфеты**,** шары**,** игрушки.




- Если однородные члены предложения соединены неповторяющимися противительными союзами **<u>(а, но, зато, однако</u>**), то между ними ставится **<u>запятая</u>**

*В саду росли не деревья**, а** кустарники. Он торопился**, зато** до темноты дошёл до деревни.*








*Хозяин удивился**, однако** промолчал. Ребята ходили за грибами в лес**, но** грибов не нашли.*



• Однородные члены предложения, соединённые повторяющимися союзами: запятая ставится перед повторяющимися союзами **<u>и...и, да...да, ни...ни, или...или, ли... ли, либо...либо, то...то и т.д.</u>**

*В этом магазине можно купить. Она или плачет, или смеется.*

*и тетради, и ручки, и книги.*

**и** ◯ **, и** ◯ **, и** ◯ **или** ◯ **, или** ◯

**Список источников:**


1. <u>https://yandex.ru/turbo/calc.ru/s/Znaki-Prepinaniya-Pri-Odnorodnykh-Chlenakh-Predlozheniya.html</u>

2. Иванов С.В., Кузнецова М.И., Петленко Л.В., Романова В.Ю. / Под ред. Иванова С.В. Русский язык (в 2 частях) 3 класс ООО Издательский центр ВЕНТАНА-ГРАФ».


## К ВОПРОСУ О ПРОБЛЕМАХ И ПЕРСПЕКТИВАХ ЦИФРОВИЗАЦИИ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЙ СРЕДЫ В ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЯХ


*Науметова Раиля Ринатовна,*
*научный сотрудник отдела подготовки научно-педагогических кадров ГАОУ ДПО ИРО РТ, г. Казань*



*В статье обоснована необходимость использования цифровых технологий в общеобразовательных организациях, проанализированы основные направления применения цифровизации в образовании, дана характеристика цифровой образовательной среды, выделены перспективы цифровизации образовательной среды.*


Образование, как один из фундаментальных и устойчивых институтов общества, должно отвечать вызовам времени. Создание новой образовательной среды, сочетающей в себе традиционную и цифровую форму взаимодействия педагога и ученика, внедрение цифровых образовательных технологий призвано обеспечить повышение качества образования и его доступность, усилить мотивацию обучающихся и развивать педагогическое мастерство преподавателей.

Цифровая образовательная среда образовательной организации (ЦОС ОО) предполагает набор инструмен-

тов информационно-коммуникативных технологий. Использование этих технологий должно носить системный порядок и соответствовать требованиям ФГОС к формированию условий реализации образования, способствовать достижению обучающимися планируемых личностных, метапредметных, предметных результатов обучения. Кроме того, цифровая образовательная среда образовательной организации должна стать единым пространством коммуникации для всех участников образовательных отношений, действенным инструментом управления качеством реализации образовательных программ.

В условиях реализации федерального проекта «Цифровая образовательная среда» в рамках национального проекта «Образование» (Федеральный проект «Цифровая образовательная среда» национального проекта «Образование», утвержденный президиумом Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам протоколом от 24 декабря 2018 г. №16) перед образовательными организациями ставится задача создания и внедрения в образовательных организациях цифровой образовательной среды, а также обеспечение реализации цифровой трансформации системы образования. Целью проекта выступает создание условий для внедрения к 2024 году современной и безопасной цифровой образовательной среды, обеспечивающей формирование ценности к саморазвитию и самообразованию у обучающихся образовательных организаций всех видов и уровней, путем обновления информационно-коммуникационной инфраструктуры, подготовки кадров, создания федеральной цифровой платформы. В рамках проекта ведется работа по оснащению организаций современным оборудованием и развитие цифровых сервисов и контента для образовательной деятельности. Срок реализации федеральной программы – 01.10.2018 г.-31.12.2024 г. За счет мероприятий проекта к концу 2024 года будут достигнуты следующие основные результаты и показатели:

- 29 586 образовательных организаций, оснащенных оборудованием для внедрения цифровой образовательной среды;
- 620 700 педагогов, подключенных к платформе цифровой образовательной среды;

– 340 центров цифрового образования детей «IT-КУБ»;

– 41 комплект верифицированного цифрового образовательного контента, соответствующего ФГОС общего образования;

– 40 % педагогов из не менее чем 30 % школ будут использовать сервисы федеральной информационно-сервисной платформы цифровой образовательной среды;

– 40 % образовательных организаций, из числа субъектов Российской Федерации, участвующих в эксперименте по модернизации начального общего, основного общего и среднего общего образования, будут оснащены компьютерным, мультимедийным, презентационным оборудованием и программным обеспечением [1].

Формирование цифровой образовательной среды в каждой образовательной организации – процесс уникальный и должен учитывать множество факторов. При формировании цифровой образовательной среды в образовательной организации следует принять во внимание ряд ключевых аспектов:

– уровень сформированности ИКТ-компетенции педагогов образовательной организации;

– возможности внедрения информационных и коммуникационных технологий в практику преподавания всех учебных предметов;

– возможности внедрения информационных и коммуникационных технологий в деятельность воспитательной службы образовательной организации и служб сопровождения;

– обеспеченность образовательной организации необходимым оборудованием;

– условия для практического применения компьютерной техники и иных цифровых инструментов всеми участниками образовательных отношений;

– возможность открытого доступа к информационным каналам локальной внутренней сети, глобальной сети Интернет и к ресурсам медиатек;

– непрерывность развития технической инфраструктуры цифровой образовательной среды.

Цифровая образовательная среда общеобразовательной организации позволяет:

– автоматизировать административные, управленческие и организационные процессы;

– обеспечить возможность организации электронного и дистанционного обучения;

– перевести отчетность образовательной организации в цифровой формат;

– проводить процедуры оценки качества образования;

– конструировать и реализовывать индивидуальные учебные планы (программы), в том числе с зачетом результатов обучения по онлайн курсам при прохождении аттестационных мероприятий.

Критерии успеха ЦОС – это снижение интенсивности документооборота, рост трафика добровольного использования ЦОС, прежде всего учениками. Важным критерием при формировании ЦОС является доступ ко всем сервисам через браузер и мультиплатформенность используемых инструментов, что обеспечивает гибкость настройки, мобильность и удобство в работы для всех участников образовательного процесса.

Перспективы реализации модели ЦОС:

– Увеличение числа образовательных учреждений, использующих модель ЦОС;

– Увеличение числа образовательных организаций, использующих электронное обучение;

– Увеличение числа педагогов, использующих электронное обучение в учебной деятельности;

– Продолжение сетевого сотрудничества: создание сетевых уроков, обмен технологиями, разработками уроков, методическим материалом;

– Привлечение новых участников, развитие сетевого взаимодействия через вебинары, семинары, оффлайн и онлайн встречи, организации секций на конференциях, образовательных форумах, пр.

Формами реализации цифровая образовательной среды в общеобразовательных организациях выступают: урок, внеурочное занятие, воспитательное мероприятие с использованием ЭОР; образовательные программные обеспечения (авторские разработки); образовательные компьютерные игры; образовательный сайт; сетевые педагогические сообщества, видеолекции и видеоуроки; развивающие мультфильмы; создание познавательно-образовательных фильмов; виртуальная экскурсия; виртуальный методический кабинет; электронные медиауроки; медиа-презентации и т.д.

В заключении можно сделать вывод, что использование цифровой образовательной среды в процессе воспитания и обучения является перспективным направлением развития образования.

**Список источников:**

1. Министерство просвещения Российской Федерации: официальный сайт. – Москва – URL: https://edu.gov.ru/national-project/projects/cos/ (дата обращения 06.04.2023).

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ «ӘЙЛӘНГӘН СЫЙНЫФ» МЕТОДИКАСЫ АША УКУЧЫЛАРНЫҢ КРЕАТИВ ФИКЕРЛӘВЕН ҮСТЕРҮ

*Рамазанова Гүзәл Тәлгать кызы,*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Әгерҗе шәһәренең муниципаль бюджет гомуми белем бирү*
*учреждениясе Таҗи Гыйззәт исемендәге*
*3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе*

*Методиканың төп идеясе, укучы теоретик материалны өйдә мөстәкыйль рәвештә үзләштерә (видеолекцияләр, аудиолекцияләр, интерактив материаллар һ.б.), ә дәрес практик формада (күнегүләр, ситуацияләр, сөйләм үсеше, укучыларның бер-берсе һәм укытучы белән үзара хезмәттәшлеге) уздырыла. Нәтиҗәдә, укучылар традицион булмаган биремнәрне үтиләр, бу креатив фикерләүгә уңай нигез бирә. Бу метод барлык укытучыларга да укучыларның креатив фикерләвен үстерүдә файдалы булырга мөмкин.*

Гадәттә, тәнәфес вакытында укучылар сыйныфны баштанаяк әйләндерергә әзер. Әмма монда сүз чит илләрнең күп кенә мәктәпләрендә кулланыла торган методика турында барачак. «Әйләнгән сыйныф» (flipped classroom) моделенең баш җитәкчеләре дип ике укытучы санала – Джонатан Бергман (Jonathan Bergman) һәм Аарон Сэмс (Aaron Sams). Алар 2007 елда башта еш кына дәресләрне калдыра торган спортчыларны үзләренең лекцияләре белән ничек тәэмин итүне уйлап тапканнар, ә аннары бу идеяне яңа белем бирү юнәлешенә үстергәннәр. Алар кыска видеолар төзи башлыйлар, аларны укучылар өйдә карарга тиеш була. Укычылар аңламаган очракларны язып бара, шул өлешләрне инде дәрестә укытучыдан сорый. Дәресләр инде лаборатор эшләргә, материалны практик яктан беркетүгә, шулай ук укучыларның сорауларына җавап бирүгә багышлана. Бу метод дәрестә үткән мәгълүматны аңлап бетермәгәндә яки авырып калганда бик кулай.

Методның өстенлекләре:

– Укучы белемне дәрес кысаларында түгел, ә аңа уңайлы вакытта карый ала. Бу – смартфонга яки планшетка йөкләнгән видео карау, яки аудиолекция тыңлау.

– Укучы материалны үз темпында үзләштерә, видеоны яки аудионы күпме кирәк дип саный, шул кадәр карый һәм тыңлый ала, конспект ясау яки яңа мәгълүматны аңлау өчен пауза ясый ала.

– Укытучы белән индивидуаль консультацияләр форматы балаларга яңа материалны аңламый калмаска ярдәм итә. Бу шулай ук, укытучыга укычының прогрессын күрергә һәм һәр укучының аңлау дәрәҗәсен белергә ярдәм итә.

– Дәрес вакыты яңа материалны аңлатырга сарыф ителми, шуңа күрә алган белемнәрне куллану өчен күбрәк мөмкинлекләр тудырыла.

– Методика махсус кыйммәтле техник җайланмалар таләп итми. «Әйләнгән сыйныф» кысаларында эшне гамәлгә ашыру өчен тавыш яздыру җайланмасы (диктофон, микрофон), камера яки вебкамера, стандарт программалы компьютер кирәк булырга мөмкин.

– Укучылар мөстәкыйль әзерләгәндә өстәмә чыганаклардан күбрәк файдалана ала: интернет, өйдәге китаплар, сүзлекләр һ.б.

Әйләнгән сыйныфны еш кына дистанцион белем алу белән бутыйлар. Аерма – сыйныф эше вакыты үзгәрешсез кала, аның эчтәлеге генә принципиаль үзгәрә.

Бу алымны мин ничек татар теле һәм әдәбияты укытканда кулланам?!

1. Дәрестә үткәннәрне кабатлау буларак яки инде дәрестә булмаган балаларга өйрәнү өчен видеолар ясыйм (мәсәлән, видео «Казан Кремле»). Бу видео яңа сүзләр өйрәнгәндә һәм туган якны өйрәнгәндә кирәкле алым. Икенче дәрестә видеода булган сүзләр кабатлана һәм алар белән күнегүләр эшлибез. Икенче өй эше итеп, «Казан Кремле» рәсемен ясарга бирәм, яки «Мин Казан Кремле гиды» темасына чыгыш ясарга тәкъдим ителә.

2. Грамматик материалны аңлап бетермәгәндә, видеолар кулланам (мәсәлән, видео «Кушымчалар»). Бала видеоны өйдә карый һәм мәгълүматны аңламаган өлешенә генә өндәү ясап, дәрестә сораулар бирә. Икенче өй эше итеп, укучыларга үзләренә тест ясарга кушам.

3. Татар телендә аралашу компетенциясен үзләштерү, өйрәнә торган телдә аралашмыйча, бик катлаулы эш. Шуңа күрә

укытучының мөһим бурычы – татар теле дәресендә аралашуның реаль һәм хыялый ситуацияләрен булдыру, моның өчен аудиолар куллану уңайлы алым. «Әйләнгән сыйныф» методикасында аудиолар да кулланам (мәсәлән, аудио «Буш вакыт»). Укучы өйрәнә, тыңлый, аңламаган очракларын тәрҗемә итә. Икенче өй эше итеп, буш вакыт турында буклет ясарга бирәм.

4. Уку яки әдәбият дәресләрендә мультфильмнарга таянып эш итәм. Мәсәлән, өй эше: сылтама буенча күчеп, мульфильм карарга һәм Идел буе Болгар дәүләтенең килеп чыгуын аңлатырга. Балалар мульфильмны өйдә карыйлар. Аңламаса, тагын кабатлап карый, шул рәвешле балалар кирәкле мәгълүматныөйдә аңлап киләләр. Аңламаган өлешләрен язып баралар һәм дәрестә сорау бирәләр. Икенче өй эше итеп, мультфильмның өзекләренә комикс ясарга бирәм, дәрестә балаларның рәсемнәрен җыеп, гомуми бер комикс ясыйбыз.

Нәтиҗәдә, укучылар традицион булмаган биремнәр башкара, бу иҗади фикерләү өчен уңай нигез булып тора. Хәзерге җәмгыятьтә җайлашу һәм гел үзгәреп торучы информациянең зур агымын юнәлтү өчен, мөстәкыйль, критик, иҗади уйларга кирәк, һәм балаларга моны өйрәтергә кирәк. Мәктәп укучыларын укыту һәм үстерү таләпләре сизелерлек үзгәрде, бу Федераль дәүләт мәгариф стандартында чагылыш таба, анда логик фикерләү, стандарт булмаган проблемаларны чишү сәләтенә аеруча зур игътибар бирелә. Иҗади фикерләү – яңа нәрсә булдыру яки ачу. Барлык балаларның да диярлек иҗади потенциалы бар, алар системалы күнегүләр белән эффектив үсә. Иҗади фикерләү сәләтен үстерү өчен сыйныфта алган сәләтләр, күнекмәләр балалар тарафыннан көндәлек тормышта мәктәп предметларына эффектив күчерелә, аларның иҗади үсеш алмаган яшьтәшләренә караганда күпкә зуррак уңышларга ирешәләр. Артык тәнкыйть, эчке цензура, шунда ук җавап табу теләге, катгыйлык (иске белемнәрне кулланырга теләү) һәм конформатизм (аерылып тору һәм башкалар алдында көлкегә калудан курку) иҗади фикерләү үсешенә комачаулый ала. Шуңа күрә дә, мәктәп укучыларында билгеле бер проблеманы чишүдә иҗади эш формасы педагогик процессны баета, аны мәгънәлерәк итә, иҗади шәхес буларак баланың үсешенә тәэсир итә. Иҗат – балаларны укытуда һәм тәрбияләүдә яңа предмет, ул укучыларын креатив фикерләү, иҗади шәхеснең уңай сыйфатларын тәрбияләүне күздә тота. Шаблоннарны

җиңеп чыгу, күзәтү, чагыштыру, анализлау, критик бәяләү һәм гомумиләштерү, максатларны сайлап алу, хәл итүнең рациональ юлларын табу, сөйләмне үстерү өчен «Әйләнгән сыйныф» методикасын тәкъдим итәм. Дәрестә видео яки мульфильм карау урынына башка мәгълүмат алу, башка күнегүләр һәм эш гамәлләре үткәрергә вакыт барлыкка килә. Минем уйлавым буенча, укучыларның креатив фикерләвен үстерүдә бу алым максатка ярашлы булып тора.

Француз язучысы Дени Дидро «Кешеләр укудан туктасалар, фикерләүдән туктыйлар» дигән, ә укытучы яңалыкны өйрәнүдән туктаса, укытучы булудан туктый, дип уйлыйм. Шуңа күрә дә мин даими рәвештә һөнәри белемемне өзлексез күтәрү өстендә эшлим. «Әйләнгән сыйныф» методикасын үзегезнең эшчәнлегегездә дә кулланырга чакырам.

**Чыганаклар исемлеге:**

1. Википедия. Перевёрнутый класс. [Электронный ресурс]. https://ru.m.wikipedia.org/wiki/%D0%9F%D0%B5%D1%80%D0%B5%D0%B2%D1%91%D1%80%D0%BD%D1%83%D1%82%D1%8B%D0%B9_%D0%BA%D0%BB%D0%B0%D1%81%D1%81

2. EduClab. Образовательный онлайн-журнал. Три ответа: методика «перевернутого класса». [Электронный ресурс]. https://web.archive.org/web/20140630065407/http://educlub.com.ua/tri-otveta-metodika-perevernutogo-klassa/

# МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ ШАРТЛАРЫНДА БАЛАЛАРНЫ ТАТАР (ТУГАН) ТЕЛЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ ЗАМАНЧА ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

*Сабирова Айгөл Марсель кызы,*
*Мингалиева Ләйсән Миннулла кызы,*
*тәрбиячеләр,*
*Казан шәһәре Совет районының 211 нче балалар бакчасы*

Без сезгә УМК комплексын кулланып эшләнелгән «Акыллы тартма» интерактив өстәл уенын тәкъдим итәбез.

**Әлеге уенның төп максаты:** балаларның татарча аралашу сәләтен үстерү, хәтердә татар сүзләрен ныгыту, диалогик сөйләм тәрбияләү, хәтерне яхшырту, бер-берсен тыңлый белергә өйрәтү булып тора. Әлеге уен 4-7 яшьлек балалар өчен каралган. Уен үз

эченә берничә тема һәм уен күнегүләрен туплаган. Барлыгы 16 төрле уен уйнарга мөмкин. Уеннар «Акыллы тартма» да өске өлештә, аскы һәм ян өлешләрдә урнашкан. Һәр уен билгеле бер номер белән билгеләнгән. Һәрбер тема өчен аерым карточкалар кулланыла. Алар махсус тартмачыкларда саклана. Шулай ук бала тиз генә тапсын өчен, аларда да уен номерлары язылган була. Уенны бала үзе генә дә, парлап та, кечкенә төркемнәргә бүленеп тә уйный ала. Шулай ук тәрбияче биргән сорауларга җавап биреп тә уйнап була.

*Уртанчылар төркеме өчен уеннар:* «Минем өем», «Сыйла», «Уенчык бүләк ит», «Чиста-пычрак», «Гаилә» бармак уены, «Парын тап!», «Бу кем?», «Нәрсә яшерелгән», «Сана, ничә алма?» уеннары урнашкан.

*Зурлар төркеме өчен:* «Яңа кием сайла», «Савыт-саба тәкъдим ит», «Кем нәрсә эшли?», «Минем команданы үтә» уеннары тупланган.

*Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары* өчен Пиктограммалар ясалган. Барлык уеннарның да ничек уйналганын аерым язып тормыйбыз. Qr-код буенча үтеп видеоязманы карасагыз барысы да аңлашыла. «Акыллы тартма» интерактив өстәл уенын балалар бик яратып уйныйлар. Шушы уенны кулланып, инде бер төркем балаларны мәктәпкә озаттык. Хәзер яңа төркем балалары белән дә бу уенны бик яратып, уйнап үсәбез. Тәрбиячеләр өчен дә кулланырга бик кирәкле һәм уңайлы уен булып тора.

## БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ КУЛЛАНУ

*Садыкова Сиринә Илсур кызы,*
*татар теле һәм әдәбият укытучысы,*
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының*
*«32 нче гимназия» МБГББУ*

Бүгенге көндә укучыларның сәламәтлеген саклый торган төп мохит булып гаиләдән кала мәктәп тора. Белем бирү оешмасын һәм укытучыга, аерым алганда, укучыларның сәламәтлеген кайгырту кебек аларга хас булмаган мәсьәләләрне йөкләүнең берничә мөһим сәбәбе бар. Беренчедән, балалар үз вакытларының

иң күп өлешен нәкъ менә мәктәптә укытучылар күзәтчелеге астында уздыралар, шуңа күрә аларның сәламәтлекләрен кайгыртмау укытучылар тарафыннан рәхимсезлек булыр иде. Икенчедән, бала сәламәтлегенә күпчелек тәэсир итү – теләпме, теләмичәме – укытучылар тарафыннан мәктәп кысаларында башкарыла. Өченчедән, хәзерге медицина сәламәтлек өчен түгел, авырулар белән көрәшә, ягъни авыруларны кисәтү белән түгел, дәвалау белән шөгыльләнә. Гомуми белем бирү оешмасының вазыйфасы башка – ул үз тәрбияләнүчеләрненең сәламәтлеген саклау, яки авыруларны кисәтү. Димәк ки, сәламәтлекне саклауга юнәлдерелгән технологияләрне куллану – балаларның сәламәтлекләрен саклау XXI гасыр укытучысының төп бурычы. Сәламәтлек – шәхес үсешенең нигезе, исәнлек булмаса, ирешелгән уңышларның әһәмияте юк.

Туган (татар) тел дәресләрендә сәламәтлек саклау технологиясен куллану буенча системалы эшне планлаштырганчы, әлбәттә, башта балаларны ныклап өйрәнү таләп ителә. Мәктәп документлары укучы турында бик күп мәгълүмат бирә ала. Медицина карточкаларыннан алынган мәгълүматлар сәламәтлек саклау буенча тәрбия эшләрен планлаштыруга, профилактик чаралар үткәрүгә, уку вакытында туган проблемаларның сәбәпләренә төшенүгә ярдәм итә.

Башлангыч сыйныфларда туган тел дәресләрендә сәламәтлек темасына караган текстлар отышлы. Мисал өчен, сыйфат темасын үзләштергәндә Ш. Галиевның «Витаминнар» шигырен файдалану үзен аклый: «А дигән витамин бар, Түм-түгәрәк, вак-ваклар, В дигән витамин бар, Әйтерсең лә борчаклар <...>».

Шигырьне укыганнан соң, укытучы укучылар белән диалог оештыра: *Бу шигырь нәрсә турында? Нәрсә ул витамин? Аның турында нәрсәләр беләсез? Шигырьдән нинди?* соравына җавап биргән сүзләрне табыгыз. Витаминнар ни өчен кирәк? Витаминнар турында тагын нинди шигырьләр беләсез? Шул рәвешле укучылар грамматик материал белән беррәттән, витаминнар турындагы белемнәрен дә баеталар.

Башлангыч сыйныф укучыларын орфография нигезләренә өйрәткәндә, лингвистик компетенция белән генә коралланып калмыйлар, ә *сәламәт* сүзенең эчтәлеге турында да фикер алышалар. Башлап, укучыларның игътибары сыйныфтагы элмә тактага юнәлдерелә. Алга таба укытучы бу сүзнең язылышы һәм әйтелешендәге аермага басым ясый. Аннары исә диалог рәвешендә түбәндәге сорауларны куяр: *Нәрсә ул сәламәтлек?*

*Сәламәтлек сүзен ничек аңлыйсыз? Нинди кеше сәламәт кеше дип атала? Сәламәт булу өчен нәрсә эшләргә кирәк? Сәламәт яшәү рәвеше турында нәрсәләр беләсез?*

Башлангыч сыйныфларда туган тел дәресләрендә фонетика турында гомуми төшенчә булдырганнан соң, укучыларга авазлар, аерым алганда тартык һәм сузык авазлар турында мәгълүмат бирелә. Бу татар телен укытуда дәвамчанлык һәм эзлеклелек принцибына нигезләнеп башкарыла. Алга таба авазларны төркемләү өйрәнелә. Сузык авазларның классификациясе, алга таба тартыклар классификациясе турында мәгълүмат китерелә. Актуальләштерү этабында төрле биремнәр, күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин. Мәсәлән, интерактив такта ярдәмендә әйтелеш белән язылыш арасындагы аермалыкларны табарга тәкъдим итеп була: *Сәламәтлек – җәүһәр, ләкин тиз югала; Бурычын яшергән бөлгән, авыруын яшергән үлгән.*

Башта җөмләләрнең мәгънәләре аңлатыла. Аннары сүзләр транскрипциядә күрсәтелә. Шул ук вакытта сүзләрнең орфоэпиясе аңлатыла. *Сәламәтлек, җәүһәр, авыру* сүзләренең язылышын истә калдыру кирәклеге әйтелә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, башлангыч сыйныфларда туган теле дәресләрендә укучылар лингвистик компетенциягә генә ия булып калмыйча, сәламәт яшәү рәвеше турында да белем һәм күнекмәләр алырга тиеш. Бу максатка ирешү өчен, татар халык авыз иҗаты әсәрләрен, язучыларның әсәрләреннән өзекләрне кулланырга кирәк дип саныйбыз.

## БАЛАЛАРДА ТУГАН ҖИРГӘ КАРАТА ЯРАТУ ХИСЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ

*Саматова Фәридә Тимергали кызы, тәрбияче,*
*«Кукмара шәһәре тугызынчы номерлы*
*«Миләшкәй» балалар бакчасы» МБМБУ*

**Актуальлек.** Балаларда туган җиргә карата патриотик, ярату хисләре тәрбияләү иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу тәрбиянең нигезендә баланың әхлакый хисен үстерү ята. Эшне мәктәпкәчә яшьтәге балалардан башларга кирәк. Нәкъ шушы вакытта баланың шәхес буларак формалашуының мөһим чоры. Бу яшьтә үзләштерелгән мәгълүмат, белем, осталык һәм алган тәэсирләр бик нык була. Алар баланың алга таба үсешенә нигез салалар.

Туган җир ул әти-әнидән, гаиләдән, туган йорттан, якын тирәлектән башлана.

**Максат:** балаларда туган як тарихы һәм мәдәнияте турында системалы белемнәр формалаштыру, кече Ватанга карата ярату, горурлану хисләре тәрбияләү.

Шушы максаттан чыгып, бурычлар куйдым:

1. Балаларда гаиләсенә, туган йортына, урамына, балалар бакчасына, яшәгән шәһәренә карата ярату хисләре тәрбияләү.
2. Әйләнә-тирәгә карата сакчыл караш формалаштыру.
3. Дәүләт символлары белән таныштыру. (герб, флаг, гимн).
4. Туган иленең казанышлары белән горурлану хисләре тәрбияләү.
5. Башка милләт вәкилләренә, аларның гореф-гадәтләренә карата хөрмәт тәрбияләү.

Бу максат, бурычлар балаларның барлык эшчәнлек төрләрендә үтәлә: шөгыльләрдә, уеннарда, хезмәт эшчәнлегендә, көнкүрештә – чөнки алар балада патриотик хисләр тәрбияләү белән бергә аның өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләрен дә формалаштыралар.

Алда әйтеп үтелгәнчә, туган якны ярату ул әти-әнине яратудан башлана. Моның буенча бик күп эшләр башкарылды. Балалар белән әниләренең портретларын ясадык һәм күргәзмә оештырдык. Балалар бакчасында «Әниләр көне» үткәрдек. Үткәрелгән чара бик кызыклы һәм тирән эчтәлекле булды. Мондый бәйрәмнең максаты – әниләргә карата хөрмәт һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү. Балаларны бишек җырлары, әкиятләр белән таныштырам. Гаиләгә, туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә; әйләнә-тирәгә сакчыл караш тәрбияләүдә халык әкиятләренең роле зур. Әкият белән танышканнан соң, кайберләрен балалар белән сәхнәләштерәбез. Балаларда патриотик хис тәрбияләү максатыннан Әфганчылар көне уңаеннан Әфганстанда хезмәт иткән этине очрашуга чакырдык. Бу чара балаларда Ватаныбыз белән горурлану хисләре формаштыруда зур әһәмияткә ия булды.

Үткәнен белмәгәннен киләчәге юк дигән әйтемне истә тотып, әти-әниләр белән берлектә нәсел шәҗәрәләре ясадык. Бу эш нәтиҗәсендә балалар да, әти-әниләр дә үзләренең нәселләре белән горурлану хисләре кичерделәр. Балалар гаиләдә үзләренең нәсел җебен өйрәнү бик мөһим икәненә төшенделәр. Аеруча Нурислам белән Фәритнен эшләрен билгеләп үтәсе килә. Нурисламның нәсел шәҗәрәсе бик үзенчәлекле итеп

ясалган иде. Фәрит этисе һәм әнисе ягыннан 9 буын бабасының исемен яттан белә. Бу үзенә күрә бала өчен бер рекорд. Билгеле, монда әти-әнинең тырышлыгы да бик зур. Фәрит районда «Ак калфак» оешмасы тарафыннан үткәрелгән «Татар малае 2022» конкурсында катнашып, диплом да алды әле.

Балаларда туган як белән горурлану хисләре формалаштыру буенча да күпкырлы эшләр башкарылды. Һәрдаим Кукмарадан чыккан данлыклы шәхесләр белән таныштырам. «Минем шәһәрем», «Кукмарам – туган ягым», «Татарстан», «Нәрсә ул Ватан?», «Казан – минем башкалам», «Россия» дигән темаларга әңгәмәләр үткәрдем. Туган илебез, туган ягыбыз турында альбом һәм фотографияләр, презентацияләр карыйбыз. Туган поселогыбыз турында тирәнтен белү, туган ягыбыз белән горурлану хисләре уяту максатыннан поселогыбыз музеена, китапханәгә, янгын сүндерү частена экскурсиягә бардык. Аннан без истә калырлык тирән хис – кичерешләр белән кайттык.

Дәүләт символлары: Татарстаның һәм Россиянең гербы һәм әләме белән таныштык. Аудиоязмадан гимн тыңладык. Шулай ук балаларны үзебез ясаган Казан, Мәскәү һәм башка илебезнең шәһәрләре турында альбом җыентыклары белән таныштырдым.

Балаларны халык уеннары белән таныштырам. Безнең балалар бакчасында милли бәйрәмнәр бик яхшы оештырылган төстә уза. (Мәсәлән, «Нәүрүз», «Сабантуй», «Сөмбелә» ). Башка халыкларга, аларның мәдәниятенә карата хөрмәт тәрбияләү өстендә дә эш алып барыла. Зурлар төркемендә «Халык уеннары бәйрәме» үткәрдек. Бу чара ярдәмендә балалар татар, рус, удмурд халыкларының милли ризыклары, уеннары, җырлары белән таныштылар. Ел саен бакчабызда «Халыклар дуслыгы» бәйрәме үткәрелә. Бу бәйрәмгә районыбызның авылларыннан балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр дә чакырыла. Бәйрәмдә районыбыздагы милләт вәкилләренең традицияләре, мәдәнияте чагыла.

Балачак – ул уен чоры. Мин эшемдә уенның төрле формаларын кулланам. Уен-инсценировка, уен-шөгыль, сюжетлы-рольле уен, дидактик уеннар. Мәсәлән, дидактик уеннар: «Калфакны бизә», «Читекне бизә», «Алъяпкычны бизә», «Кулъяулыкны бизә» «Домино». Презентация формасында дидактик уеннар да оештырам («Айсылуны киендер»).

Гаилә – баланың иң төп тәрбиячесе. Мин балаларның әти-әниләре белән тыгыз элемтәдә торам. Әти-әниләр һәм балалар бакчасында бирелә торган тәрбия һәрвакыт бер юнәлештә

булырга тиеш. Мин балаларга туган якка мәхәббәт тәрбияләүдә әти-әниләрне дә җәлеп итәргә тырышам. Балаларда үз гаиләсенә карата мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбиялим. Әти-әниләр җыелышында «Тылсымлы сүзләр», «Балалар яхшы күңелле булып үссен өчен», Әкият белән тәрбияләү» дигән темаларга чыгыш ясадым. Балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияли торган китаплар белән таныштырам. Әти-әниләр белән бергә үткәрелгән чараларның да файдасы бик зур. Ел саен «Әти-әни, мин – спорт гаиләсе» дигән спартакиада үткәрәбез. Өлкән буынга хөрмәт тәрбияләү максатыннан «Әбием, әбекәем» дигән бәйрәмен үткәрдек. Бу бәйрәм балаларда үз нәселең белән горурлану хисләре тудыруда зур роль уйнады.

Шушы тема буенча эзләнүне, мәглүмат туплауны дәвам итәм, шулай ук үземнән дә зур өлеш кертергә тырышам. Районда үткәрелгән патриотик җыр конкурсында хорда катнаштым. Кукмара турында «Туган ягым Кукмарам» дигән шигырь яздым. Болар барысы да балаларны туган якның һәм үз халкының тарихына тарта, туган илгә мәхәббәт тәрбияли.

## ИҢ ТАТЛЫ ТЕЛ – ТУГАН ТЕЛ

*(Халыкара туган тел көненә багышланган бәйрәм конспекты)*

*Сәйфетдинова Дамира Гаязетдин кызы,*
*югары категорияле тәрбияче,*
*Шәймәрданова Гөлия Камил кызы,*
*беренче категорияле физик культура инструкторы,*
*Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының*
*«Кукмара шәһәре унынчы номерлы*
*«Ромашка» һәрьяктан үстерешле балалар бакчасы» МБМББУ*

**Максат.** Балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру, төрле милләт халыкларының гореф-гадәтләренә мәхәббәт, ярату, кызыксыну тәрбияләү.

**Бурычлар.**

1. Балаларда туган телебезгә, туган илебезгә, халкыбызның рухи хәзинәләренәмәхәббәт тәрбияләү.

2. Төрле милләт халыкларының җырлы-биюле уеннары аша балаларның сүз байлыкларын арттыру, фикер йөртү сәләтен, игътибарлылык һәм хәтердә калу күнекмәләрен үстерү.

3. Туган телнең матурлыгын һәм аһәңен тоя белергә өйрәтү, шигырьләрне сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

**Җиһазлар һәм техник чаралар.** Проектор, ноутбук, магнитофон, презентация, яулыклар, милли костюмнар, уеннарга атрибутлар.

**Алып баручы.** Хәерле көн, балалар, хөрмәтле тәрбиячеләр, килгән кунаклар! Без бүген сезнең белән Халыкара Туган тел көнен бәйрәм итәргә җыелдык. Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе – тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу – безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашу теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез. Балалар, безнең республикабыз күп милләтле. Анда татар, рус, удмурт, чуваш, мари һ.б. милләт халыклары яши. Ә безнең бакчага нинди милләт балалары йөри соң?

**Балалар җавабы:** татар, рус, удмурт.

**Алып баручы.** Бик дөрес. Без бүген бәйрәмдә татар, рус, удмурт телләрендә шигырьләр тыңларбыз, уеннар уйнарбыз.

Татар, рус, удмурт балалары үз туган телләрендә шигырьләр сөйлиләр.

**Бала.** Мы в любимом Татарстане дружно, весело живем. По-татарски, по-удмуртски и по-русски мы танцуем и поем. Веселиться вместе с нами всех друзей к себе зовем.

**Алып баручы.** Ә хәзер бергә күңел ачып төрле халык уеннарын уйнап алыйк әле.

1. Татар халык уены: «Яшел яулык».
2. Удмурт халык уены: «Сукыр така» («Слепой баран»).
3. Рус халык уены: «Гори, гори ясно».

**Удмурт биюе «Ялыке».**

**Алып баручы.** Ә хәзер безнең балалар тел турында шигырьләр сөйләп үтәрләр:

1. Газинур Морат. «Туган тел», «Физкультура».
2. Энҗе Мөэминова. «Туган телем».
3. Хакимҗан Халиков. «Сөйләшәләр безнеңчә».
4. Шәйхи Маннур. «Яхшы бел».
5. Александр Шибаев. «В день солнечный июльский».
6. Александр Яшин. «Русский язык».

*Под задорную русскую мелодию в зале появляется Петрушка.*

**Алып баручы.** Балалар, безгә кем кунакка килгән?

**Балалар.** Петрушка!

**Петрушка**. Здравствуйте, гости дорогие!

Я, Петрушка – молодец, на макушке – бубенец! Хорошо пляшу, всех ребяток рассмешу!

**Петрушка**. Ой, а что это у вас за праздник такой сегодня? День рождение у кого то?

**Дети**. Сегодня день родного языка!

**Петрушка.** День родного языка! А я тоже знаю стихотворение на родном языке. (Петрушка рассказывает стихотворение «И родной тел»).

1. И родной тел, и красивый,
Мамам, папамның теле.
Мог я узнать күп нәрсәне
Син родной тел аркылы.

2. Бу языкта коляскада
Мамам сказка көйләгән.
А затем төннәр буена
Бабуля рассказ сөйләгән.

**Алып баручы.** Балалар, Петрушка безгә нинди телдә шигырь сөйләде?

**Балалар:** русча һәм татарча.

**Алып баручы.** Балалар, Петрушка татар теле белән рус телен буташтырып сөйләгәч, шигырь матур тоелдымы?

**Балалар:** юк.

**Алып баручы.** Петрушка, син үзеңнең ялгышыңны аңладыңмы?

**Петрушка.** Да, понял! Нельзя говорить сразу на двух языках. Нужно говорить на своем родном языке. И, конечно, изучать и знать языки и других народов.

**Алып баручы.** Бик дөрес, Петрушка. Балалар, әйдәгез әле, Петрушка белән бергә.

«Милли киемнәрне дөрес итеп әйт» интерактив уенын уйнап алыйк әле. (Петрушка белән уен).

**Интерактив уен «Милли киемнәрне дөрес итеп әйт»**

Балалар интерактив такта янына чыгып, экраннан татар, рус, удмурт, мари, чуваш милли киемнәрен дөрес итеп аерып күрсәтергә тиеш.

**Алып баручы.** Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе, шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы аһәңлеге өчен барыбыз да армый-талмый көрәшергә, эшләргә тиеш. Безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Сез төрле телләрдә

уеннар уйнадыгыз, биедегез, җырладыгыз, матур итеп шигырьләр сөйләдегез. Туган телегезне онытмагыз, һәр милләт халыкларының гореф-гадәтләрен хөрмәт итегез.

Телебезне күңел гөле итеп,
Саф көенчә саклыйк гомергә.
Рухи дөньяң булсын халкың моңы,
Туган телең йөрсен синең белән бергә.

Ә хәзер бергәләп Г. Тукайның «Туган тел» җырын җырлыйк.

## ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ

*Сәлимҗанова Алсу Илдар кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*«Адымнар-Әлмәт» күптелле гимназиясе*

**Дәреснең максатлары:** Белем бирү максаты. «Татар халык ашлары» темасы буенча яңа сүзләр белән таныштыру һәм грамматик яктан дөрес төзелгән сөйләм телен үстерү. Яңа сүзләрне сөйләмгә кертү, укучыларның диалогик сөйләм телләрен үстерү. Үстереш максаты. Үз фикереңне дәлилле белергә өйрәтү. Ишетеп аңлау күнегүләре аша игътибарлылыкны үстерү. Тәрбия максаты. Татар милли ризыкларына кызыксыну уяту, толерант шәхес тәрбияләү.

**Предмет:** Татар халык ашлары (татар халкының милли ризыклары) белән танышу; Метапредмет: Бәйләнешле сөйләм телен үстерү; сүзлек байлыкларын арттыру; Шәхси: Татар милли ризыкларына карата ярату, хөрмәт хисләре, әдәплелек сыйфатлары тәрбияләү, укучыларның логик фикерләү сәләтен,иҗади активлыкларын үстерү, татар милли ризыкларына кызыксыну уяту. Предмет нәтиҗәләре: Татар халык ашлары исемнәрен әйтә белү, истә калдыру.

**Метапредмет нәтиҗәләр:** укытучы ярдәме белән бурычларны билгели белү, укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү, фикерләрне логик чылбырга салу, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:** әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү, аралашу күнекмәләрен формалаштыру.

**Җиһазлау:** экран; презентация, дидактик материаллар

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.**

– Исәнмесез, укучылар.
– Хәерле көн миңа, Слайд 1
Хәерле көн сиңа,
Хәерле көн безгә!
Хәерле көн сезгә,
Укучылар, хәлләрегез ничек?
– Әйбәт! Бик яхшы.
– Ә хәзер дәресебезне башлыйбыз.

**II. Актуальләштерү өлеше.**

– Укучылар, мин сезгә шигырь укыйм. Игьтибар белән тыңлагыз.

Җирдә миңа ни кирәк? Слайд 2
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк.

– Укучылар, шигырьне аңладыгызмы? Шигырь нәрсә турында? *(Гаилә турында).*
– Укучылар, гаиләдә кемнәр бар?
– Укучылар, сезнең өстәлләрегездә сары төстә конвертлар.
Конверттагы рәсемнәрне алып өйгә урнаштырыйк әле. *(Өйдә кемнәр барын атап чыгабыз).* Әти, әни, әби, бабай, бала.
– Укучылар,сезнең өчен нәрсә ул гаилә? *(Туган йорт, мәхәббәт, кайнар ризык...)*
– Сезнең гаиләдә нинди тардицияләр бар?
– Сез кунакларны ничек каршы аласыз?
Бәйрәмгә нинди ризыклар әзерлисез? Слайд 3
Мисалга, кавказ халкы хинкали белән каршы ала, үзбәкләр исә пылау белән, рус халкында икмәк һәм тоз белән каршы алу традицияләре бар. Ә татарлар ничек каршы ала икән?
– Укучылар, Рамина үскәч блогер булырга хыяллана. Кунакларны нинди ризык белән каршы алырга кирәген әнисеннән дә яхшырак беләм ди. Әйдәгез, бергәләп тыңлыйк әле. Ни әзерләде икән безгә. *(Раминаның чыгышы. Рамина кунаклар килүенә бәлеш пешерергә уйлаган. Ничек ясавын, бәлешкә ниләр салуын сөйли).*
– Укучылар, Рамина кемнәрне көтә.
– Ул кунаклар килүенә нәрсә әзерли?
– Рамина кунаклар килүенә бәлеш әзерләгән.
– Бәлеш – ул татар халык ризыгы. Без татар телендә сөйләшәбез, аралашабыз. Ризыкларыбыз да татар халык ашлары дип атала.

Слайд 4

Димәк, безнең бүгенге дәреснең темасы – ***Татар халык ашлары.***

**III. Яңа тема**

– Укучылар, экранда яңа сүзләр бирелгән.

– Әйдәгез, бергәләп сүзләрне хор белән укыйбыз.

Слайд 5

Өчпочмак – треугольник

Чәкчәк – чакчак

Бәлеш – балиш

Кыстыбый – кыстыбый

Гөбәдия – губадия

Бавырсак – бавырсак

– Укучылар,сезнең өстәлдә яшел конвертлар бар. Алар эчендә рәсемнәр. Экранда булган сүзләрне уң якка тезәбез, булмаганнарын сул якка. *(Һәр укучы үз өстәлендәге конвертны алып, карточкалар белән эшли)*.

– Укучылар, ә хәзер бу сүзләр белән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзик.

– Афәрин, укучылар. Булдырдыгыз.

**IV. Ныгыту.**


– Укучылар, кызыл конверттагы биремне карыйбыз.

Рәсемнәр урынына сүзләр куеп (язабыз) әйтәбез.

Слайд 6

1. Кичә безгә кунаклар килде.

Без өстәл әзерләдек.

Өстәлгә  ,  куйдык.

Кунаклар безгә  алып килделәр.

 ,  бик тәмле булды.

*Җөмләләрне берничә укучыдан укыту. Сүзләрне кабатлыйбыз.*

Физминутка.

– Укучылар, хәзер ял итеп алабыз.

Слайд 7

Безнең бүген бәйрәм көн
Без чакырдык кунаклар
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.

Коймакларга карасаң
Менә шулай кабарган
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган
Коймакларны майлап ал,
Теләгәнеңне сайлап ал.

– Булды укучылар, ял итеп алдык.

**V. Ныгыту.**

– Укучылар, хәзер аш-су осталары роленә керәбез. Сезнең өстәлләрдә ак конвертлар бар. Аларның эчләрендә пазллар. Бу пазлларны җыярга кирәк. Нинди ризыклар килеп чыгар икән? Башладык.

– Укучылар, нинди ризыклар әзерләдек? Слайдка карап тикшерәбез.

– Укучылар, ә хәзер әйдәгез Рамина белән әнисе кунаклар килүенә нәрсәләр әзерләде икән, карыйк әле. (Видео).

Менә без бүген кунаклар килүенә өстәл әзерләргә өйрәндек.

– Укучылар, бу ризыкларны барыгызда өйдә әзерлисезме?

– Димәк, татарлар да, руслар да һәм башка милләт вәкилләре дә татар халык ашларын бик яратып әзерли икән.

Татарстанда милләтләр дус-тату яшиләр.

**VI. Рефлексия:**

(Кулларны әзерләдек. Бармакларны йодрыктан ачып барабыз).

1. Без бүген дәрестә яңа сүзләр өйрәндекме?
2. Җөмләләр төзедекме?
3. Уеннар уйнадыкмы?
4. Пазллар җыйдыкмы?
5. Дәрес ошадымы?

– Укучылар, өстәлләрдә смайликлар бар. Барлык биремнәрне дә эшләп чыга алдык дип уйласагыз елмайган, ә юк икән күңеле төшкән смайликны күрсәтегез.

– Өйдә яраткан татар халык ризыгын рәсем итеп ясап карагыз әле.

# ҮСКӘЧ МИН КЕМ БУЛЫРМЫН?
# НИНДИҺӨНӘР САЙЛАРМЫН?

*(2-4 сыйныфлар өчен профориентация буенча программа)*

*Ситдикова Эльвира Илдус кызы,*
*Хафизова Лилия Герасим кызы,*
*югары һәм I категорияле*
*башлангыч сыйныфлар укытучылары,*
*Татарстан Республикасы Балтач районы*
*Сосна төп гомуми белем мәктәбе*

## I. Аңлатма язуы

Программа башлангыч белем бирүнең төп программасы Федераль дәүләт белем стандарты нигезендә предметлар арасындагы һәм предмет эчендәге бәйләнешләрне, уку процессы логикасын, кече яштәге мәктәп укучысында белем алу осталыгы формалаштыру мәсьәләләрен исәпкә алып төзелде.

Бүген, икенче буын стандартларына күчү чорында, укучыны төрле яклап үстерүдә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә төрле инновацион технологияләр кулланыла. Балаларда ватанпәрварлык, үз илләрен яратучы көчле рухлы шәхесләр итеп тәрбияләү өчен дәресләр белән беррәттән дәрестән тыш эшчәнлекнең дә роле бик зур. «Үскәч мин кем булырмын? Нинди һөнәр сайлармын? программасы 3 елга исәпләнеп (2015-2018 нче еллар), һәр сыйныфка аерым темалар белән атнага якынча бер сәгать исәбеннән төзелде.

## II. Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру:

**Танып белү УУГ:** – төрле чыганаклардан мәгълүмат алу, – алынган мәгълүматлар белән эшләү;

– материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү.

**Регулятив УУГ:** – укытучының күрсәтмәләрен истә тотып гамәлләр кылу;

– гамәлләрне таләп ителгән, вакытта башлау һәм тәгәлләү, – тормыш тәҗрибәсен куллану, – эшләгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы УУГ:** – мәгънәви төшенчә барлыкка китерү («минем өчен моның кирәге бармы?») дигән сорауны үзүзеңә кую;

– гаиләң, туган илең, аның халкы һәм тарихы белән горурлану хисләре тәрбияләү, һөнәрләр дөньясы белән танышырга,

кешеләр арасында, мәктәптә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен булдыру;

– гүзәллекне күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштыру.

**Коммуникатив УУГ:**

– партадашың белән хезмәттәшлек итү;

– тормыш тәҗрибәсен куллану;

– укытучы, туганнар, әти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру.

## III. Программаның эчтәлеге

### III. 1. Программаның бүлекләре һәм юнәлешләре.

1. **Татар балалар фольклорын өйрәнү. Милләтебез бәйрәмнәре, йолалары, милли традицияләре турында белү**:

2. а) Рухи хәзинәләребезне саклап калу;

3. б) Гореф-гадәтләрне, йолаларыбызны барлау, балаларга өйрәтү.

**2. Туган авыл, туган нигез тарихы. Әби-бабаларыбызның үткәне. Нәсел агачын төзү:**

а) эшчәнлек һәм аның исеменең асылына төшендерү юлларын эзләү;

б) кече яшьтәге укучыларга яшәүнең мәгънәсен, кыйммәтен аңлату;

в) «Мин – шәхес» дигән төшенчәне аңлауга ирешү;

г) бердәмлек хисләре, хезмәт сөючәнлек һәм укуга аңлы караш тәрбияләү;

д) туган ягыбыз табигатенең байлыкларын барлау: фотолар җыю, тарихи документлар, күренекле кешеләрнең тормыш юллары чагылдырган язмалар туплау.

**3. Әби-бабайларның эшләгән эшләрен өйрәнү:**

а) әбиләребез чиккән, тукылган, тегелгән сөлге, тастымал, алъяпкыч, намазлык, мендәр тышы, тәрәзә челтәрләре белән танышу, аларны җыйнау;

б) бабайларыбызның оста куллары аша үткән төрле-төрле туку, сугу, эрләү җайланмалары, агач һәм тимердән эшләнгән савыт-сабаларны җыю;

в) бизәнү әйберләре ясау һөнәре турында өйрәнү.

## IV. Программаның бүленеше.

| № | Тема | 2 класс | 3 класс | 4 класс |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Туган авылның тарихы. Әби-бабаларыбызның үткәне. Нәсел шәҗәрәсен төзү. | 13 сәг. | 14 сәг. | 18 сәг. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Әби-бабайларның эшләгән эшләрен өйрәнү. | 4 сәг. | 5 сәг. | 6 сәг |
| 3 | Милләтебезнең балалар фольклорын өйрәнү. Милләтебез бәйрәмнәре, йолалары, милли гореф-гадәтләре турында белү. | 5 сәг. | 6 сәг. | 5 сәг. |
| | Барлыгы | 22 сәг. | 25 сәг. | 29 сәг. |

## V. Тәрбия чараларының тематик бүленеше.

| № | Тема | Эш төре | Сәг. саны | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Туган авылның тарихы. Туган төбәгем китабы. | Балтачның истәлекле урыннарына сәяхәт ясау (читтән торып). | 1 | Дәрес-пр-ция |
| 2 | Туган җирлекнең һөнәрләре турында материаллар җыйнау. | Кульъязмалар, фотографияләр, истәлекләр, газета-журналлар материаллары. | 1 | Экс-ия Эзләнү |
| 3 | «Гасырлар үткән буын» | Бөек Ватан, Афган, Чечен сугышында катнашучы авылдаш-солдатлар язмышы, тыл ветераннары, сугыш чоры балалары турында, аларның һөнәрләре турында эзләнүләр, материаллар туплау. Әби-бабайларга шефлык итү (дәвам итү). | 1 | Эзләнү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Шушы тарафтан, шушы яктан без. | Авылдан чыккан күренекле шәхесләр турында өйрәнүне дәвам итү. | 1 | Әңгәмә |
| 5 | Беркайчан да китмәгез сез балачактан! | Мәктәп тарихын, кемнәр укыткан, мәктәптән укып чыккан укучыларның сайлаган һөнәрләре турында өйрәнү (хронология төзү). | 1 | Очрашу |
| 6 | Гаиләм – ныклы терәгем | Нәселдәге һөнәрләрдән шәҗәрә төзү. | 1 | Бәйрәм |
| 7 | Балтач районы тарихы. | Балтач районы Чепья авылы музеена сәяхәт. | 1 | Экс-сия |
| 8 | «Хезмәт» газетасы тарихы (журналистика). | Типографиядә булу. | 1 | Экс-сия |
| 9 | Балтачыбызның иҗатка гашыйк кешеләре – алтын каләм тибрәтүчеләре (журналистика). | Райондаш язучылар һәм шагыйрьләр белән танышу. Балалар газета-журналлары язмалары белән даими танышып бару. | 1 | Әңгәмә |
| 10 | Балтач язучылары. (Журналистика) | Балтач районыннан чыккан язучылар иҗаты белән танышуны дәвам итү. | 1 | Әңгәмә пр-ция. |
| 11 | Балтач ягы күренекле кешеләре. | Балтач районыннан чыккан артистлар, фән эшлеклеләре, хезмәтләре белән зур хөрмәткә лаеклылар турында өйрәнү | 1 | Әңгәмә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | «Күңелләрдә син, Балтач» (журналистика). | Укучыларның белән тестлар эшләү, хикәя язу, кроссворд чишү. | 1 | Гамәли эзләнү. |
| 13 | «Балтачым минем» (музыкант). | Туган төбәк турындагы җырларны өйрәнү. | 1 | Әңгәмә ж-б уен |
| 14 | «Балтачым – газиз туган ягым» (журналистика, рәссам). | Хикәяләр язу һәм рәсемнәр ясау конкурсы | 1 | Рәсем Күргәз. |
| 15 | Челтер – челтер ага Сосна чишмәләре (эколог). | Чишмәләргә экскурсия ясау. Чишмәләрнең килеп чыгу тарихын өйрәнү, аларны саклау һәм чистарту. | 1 | Сәяхәт |
| 16 | Туган төбәгемә кошлар кайта (зоотехник). | «Рәхим итегез. Хуш киләсез, кошкайлар!» (сыерчык оялары ясау, урнаштыру) | 1 | |
| 17 | Мәктәбем – синдә үтте балачагым. Син – горурлыгым, йөз аклыгым. | Сосна мәктәбеннән чыккан шәхесләр һәм аларның һөнәрләре | 1 | Әңгәмә |
| 18 | Без авылның киләчәге. | Күзәтүләрдән чыгып, брошюра төзү. | 1 | Әңгәмә |
| 19 | Әби-бабайларның эшләгән эшләрен өйрәнү. Халкыбызның милли җәүһәрләре. | Күлмәк, калфак, бәйләнгән тәрәзә челтәрләрен, туплау, алар турында өйрәнү. | 1 | През-ция |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20 | Зәркән (бизәнү әйберләре) сәнгате. | Элеккегедән килгән милли бизәнү әйберләре турында өйрәнү. | 1 | Эзләнү пр-ция |
| 21 | Кулдан ясалган җиһазлар. | Бабаларыбыз нәрсәләр ясаганнар һәм аларны ничек һәм кайларда кулланганнар? | 1 | Әңгәмә эзләнү |
| 22 | Остаханә – алтын куллар иле (столярлык). | Агач эшенең серләренә төшенү. | 1 | Проект |
| 23 | Күркәмлек – туган нигездән башлана (тимерче). | Хәзерге заман ысуллары белән ясалган бизәү әйберләрен өйрәнү, ясау. | 1 | Күргәзмә |
| 24 | «Ярминкәгә рәхим итегез!» (сәүдәгәрлек). | Тырышлык, сәүдә эшенә хирыслык, һөнәрчелек турында өйрәнү. | 1 | Ярминкә |
| 25 | Милләтебезнең балалар фольклорын өйрәнү. Милләтебез бәйрәмнәре, йолалары, милли традицияләре турында белү. Халык иҗаты әсәрләре. | Мәзәкләр, балалар сөйләшләре, сынамышлар һ.б.туплау. Китапчык итеп әзерләү. | 1 | Эзләнү |
| 26 | Татар халкының бәйрәмнәре. Нардуган. | Нардуган бәйрәме тарихын өйрәнү. | 1 | Әңгәмә |
